www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 28 (1393) 22 июль 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

2

Бөтендөнья татар конгрессы ничек оешты һәм милләтебез аңа нинди өметләр баглаган иде?

12

Гражданнар сугышы кайнап торган мәхшәр чорында Зәки Вәлидинең мөстәкыйль республика төзеп куюы – үзе бер могҗиза!

16

Сәкинә һәм Рамил Минхановлар тормышта да, сәхнәдә дә бергә, спектакльдә икесенә дә роль булмаса, хәтта анда уйнаудан баш тарталар.

Бер җилләнеп җырлап биик әле Челтер-челтер чишмә көенә!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин парламент эшенең беренче яртыеллыгы нәтиҗәләренә багышланган матбугат очрашуында республика Конституциясенә төзәтмәләр мәсьәләсе 2022 ел азагына кадәр каралачагын раслады.

● Татар телен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә, сәләтле балаларны ачыклауны күздә тоткан «Мин булдырам» дигән яңа проект башлап җибәрелде.

● Ростов-Дон шәһәрендә Татарстанның Яшел Үзән районы ярдәме белән Көньяк Сабан туе узды.

● Казанның 131 нче лицееен тәмамлаган Галия Шәрәфетдинова Халыкара математика олимпиадасында алтын медаль алган.

● Чиләбе өлкәсендәге Троицк каласында Габдулла Тукайның шәһәргә килүенә 110 ел тулуга багышланган «Тукай Троицкта» дип аталган Бөтенроссия арт-пленэры оештырылды.

● Алмаз Нургалиевнең «Җиде утрау арасында» документаль фильмы «Тамашачы мәхәббәте» номинациясендә «Алтын тәлинкә» төбәкара кинопремиясенә ия булды.

● МОҢ театр мәйданчыгы курку турында балалар спектакле өчен кастинг уздыра.

● Саба районының Курсабаш авылында Әмирхан Еники әсәрләренә нигезләнеп, «823 километр» дип аталган тулы метражлы нәфис фильм төшерелә башлады.

● Балтач районы Бөрбаш авылында зурлап XV Россиякүләм мөселман балалар Сабан туе узды.

● Казанда Россия Язучылар берлегенең Татарстан Республикасы бүлеге рәсми рәвештә теркәлгән.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ, язучы:

«Бүген заманалар бүтән. Калын китаплар – киштә өчен. Болар («Казан утлары» журналы чыгара торган китаплар сериясе) кесәгә, кул сумкасына сыя. Хәзер бердәнбер буш вакыт – юлда, кеше транспортта барганда укый. Бу форматның киләчәге зур булыр дип уйлыйм. Дөньяның күп кенә цивилизацияле илләрендә яхшы роман бармак калынлык кына булырга тиеш, диләр. Ә без кайвакыт кирпечкә кызыгабыз, шуның белән ялгышабыз».

СЫНАМЫШЛАР

25 июльдә төшкән чык сихәтле санала.
Бу көнгә кадәр печәнне киптереп бетермәсәң, чери ● 26 июльдә яңгыр яумаса, көз коры килә ● Бер урыннан бер урынга күчеп күк күкрәсә, боз явар ● Иртән кояшны томан каплаcа, аяз булыр ● Кояш баеганда яңгыр ява башласа, тиз туктар ● Яңгыр җиргә тиз сеңсә, көннәр яңгырлы булыр.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 30 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 08 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **16 сәгать 38 минут**. Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **24 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **29 июльдә 16 сәгать 14 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

24 июль – биюче, хореограф, Татарстанның халык артисты Чулпан Ринат кызы Закировага 45 яшь (1977).

26 июль – әдәбият галиме, тәнкыйтьче, профессор Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәтинең (Нигъмәтуллин) тууына 125 ел (1897–1941);

– актёр, Татарстанның халык артисты Рөстәм Хан улы Муллинның тууына 75 ел (1947–2019).

27 июль – татар хатын-кызларыннан беренче математик-галим Сара Касыймхан кызы Шакулованың тууына 135 ел (1887–1964).

28 июль – Россиядә беренче төрки-татар басмасы – Петр I нең 1722 елгы манифесты – дөнья күрүгә 300 ел (1722);

– язучы, пилот, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рәшит Габдрахман улы Ибраһимовка 95 яшь (1927);

– педагогика фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәктәп укытучысы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтовка 70 яшь (1952).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июльнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 22 июль.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(20-28 июль)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 майдан 27 июльгә кадәр** йөрәк һәм нечкә эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген зөлхиҗҗә аеның 23 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Фәүзия БӘЙРӘМОВА

Татар конгрессының оешу тарихы

Туксанынчы еллар үрен күз алдына китерик. Бу чор – йөз елга бер килә торган геополитик үзгәрешләрнең, зур тетрәнүләрнең башы иде. Бер илләр, бер система-режимнар җимерелеп, яңалары туган тарихи күчеш чоры. Һәм гасырлар дәверендә зур югалтулар кичереп, шушы чорга кадәр килеп җитә алган, иреккә сусаган татар халкының күтәрелү, уяну чоры да иде ул...

Егерменче гасырда гына да татар халкы өч тапкыр бәйсезлеккә омтылып карады – 1905 елгы инкыйлабтан соң милли уяну, 1917 елгы февраль революциясеннән соң рухи-сәяси күтәрелеш һәм 1990 еллардагы дәүләти омтылыш. Гасырлар буе милли азатлыкка омтылган татар халкы, аның зыялылары, сәяси элита тарих биргән бер генә форсатны да кулыннан ычкындырмады, үз максатларын тормышка ашырырга тырышты.

Туксанынчы елларда да шулай булды. Ул елларда вакыт безгә эшләде, без исә, бердәм булып, милләткә эшләдек. СССРда, беренчеләрдән булып, милли күтәрелеш Балтыйк буе илләрендә башланды, аннан бу хәрәкәт Кавказга таралды, Урта Азия республикаларына исә бу уяну соңрак килеп җитте. Без, татарлар, Балтыйк буе халыклары белән бергә аякка бастык, милли көрәштә алар тәҗрибәсен өйрәндек, аны үзебездә файдаландык. Шулай ук Әзәрбайҗандагы рухи күтәрелеш, алар алып барган милли сәясәт тә безнең өчен үрнәк булды. Шушы нигездә, 1988 елда ук Татар иҗтимагый үзәге* оешты, 1989 елда аның беренче съезды, 1991 елда икенчесе булды. Төп максат – Татарстанның сәяси статусын, аны союздаш республика дәрәҗәсенә күтәрү, шул рәвешле, татар милләтен саклап калу, аның рухи-икътисади һәм мәдәни үсешенә ирешү иде. Татар иҗтимагый үзәге* милли рухтагы зыялыларны берләштерде.

Башлангыч чорда Татарстан җитәкчелеге милли хәрәкәткә каршы килмәде, киресенчә, кайбер эшләрне килешеп тә башкардылар, чөнки республиканың дәүләти статусын күтәрү аларның үзләренә дә кирәк иде. Милли хәрәкәтнең эшчәнлеге мәйданнарда, җыеннарда гына түгел, республика парламентында да дәвам итте, чөнки 1990 елгы демократик сайлауларда күп кенә татар зыялылары, милли хәрәкәт җитәкчеләре депутатлыкка үтте. Халык депутатлары арасында Марат Мөлеков, Фәүзия Бәйрәмова, Тәлгать Абдуллин, Фәндәс Сафиуллин, Җәмил Сафиуллин, Дамир Сираҗиев, Раиф Галиев, Азат Зыятдинов, Рүзәл Юсупов, Мөнир Әһлиуллин, Фрил Әхмәтов, Наил Мансуров, Мөдәррис Шәйхиев, язучылар Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Ренат Харис һ.б. бар иде. Тиз арада милли рухлы бу депутатлардан «Татарстан» төркеме төзелде һәм республика өчен, милләт өчен иң мөһим карарларны һәм кануннарны алар әзерләде, парламентта кабул иттерүгә иреште.

Татар иҗтимагый үзәгеннән* тыш, ул чорда тагын берничә милли оешма – «Суверенитет» комитеты, «Азатлык» татар яшьләре берлеге, «Иттифак» партиясе, бераз соңрак Милли Мәҗлес барлыкка килде, алар инде тагын да кискенрәк максатлар һәм зуррак бурычлар куйды. 1990 елда «Иттифак» татар милли бәйсезлек партиясе төзелде, 1991 елның 13-14 апрелендә аның беренче корылтае булды. «Иттифак» фиркасе үзенең төп максаты итеп Татарстанның дәүләт бәйсезлеге һәм татар халкының милли бәйсезлеге өчен көрәшне билгеләде. Аның программа документларында шулай ук Татарстанда демократия һәм гаделлек өчен көрәш, Татарстаннан читтә яшәүче татарларның хокукларын яклау, татар халкының хак тарихын торгызу, милләтнең асыл сыйфатларына кире кайту, ислам динен үстерү һәм тарату бурычлары да чагылыш тапкан иде. Татар иҗтимагый үзәгеннән* аермалы буларак, «Иттифак» партиясе Татарстанның дәүләт бәйсезлеге өчен көрәшәчәген, бу максатка сайлауларда актив катнашып, парламент юлы белән ирешергә омтылуын игълан итте. Фирканең программасында хакимияттәге гаделсезлеккә фаш итү бурычы да чагылыш тапкан иде. Бу исә «Иттифак» татар милли бәйсезлек партиясенең, Татар иҗтимагый үзәгеннән* аермалы буларак, сәяси таләпләр куюын һәм демократик юл белән хакимияткә килергә дәгъва кылуын аңлата иде.

1992 елның 1-2 февралендә Казан шәһәрендә татар халкының мең кешелек җыены булды, анда Милли Мәҗлес, ягъни, милли парламент сайлап куелды. Бер караганда, инде югарыда санап киткән милли оешмалар тулы куәтенә эшләп килә, тагын бер яңа оешма – Милли Мәҗлес нигә кирәк булды соң? Моның да җитди сәбәпләре бар иде. Билгеле булганча, 1991 ел Татарстан өчен дә, Россия, хәтта СССРның үзе өчен дә бик катлаулы ел булды һәм соңгысының юкка чыгуы белән тәмамланды. Бу давыллы елга Татарстан Президентын сайлау, милләтпәрвәрләрнең Казан уртасында сәяси ачлык игълан итеп, республикада Россия Президентын сайлатмавы, ГКЧП вакыйгасы һәм Татарстан җитәкчеләренең аны яклавы, халыкның бәйсезлек даулавы һәм 15 октябрьдә Ирек мәйданындагы канлы бәрелешләр дә туры килә...

Әйе, Россия белән СССР арасындагы көрәш, аларның лидерлары каршылыгы Татарстанга да нык тәэсир итте, ул ике арада калды. 1990 елның 30 августында Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул иткәннән соң, республиканың статусын күтәрү буенча кайбер омтылышлар ясалса да, алар әлләни нәтиҗә бирмәде, Мәскәүдә аңлау һәм яклау тапмады. Бу хәлләр татар милли хәрәкәтендә зур ризасызлык тудырды, Татарстанның дәүләт суверенитетына куркыныч янавын аңлап, алар республика җитәкчеләреннән бу юнәлештә катгый адымнар ясавын таләп итте. Милли хәрәкәтнең көчле басымы астында, 1991 елның 24 октябрендә Татарстан Югары Советы «Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеге турында Акт» кабул итте.

«Об Акте государственной независимости Республики Татарстан»

Постановление Верховного Совета Татарской ССР

Основываясь на Декларации о государственном суверенитете Татарской ССР, принимая во внимание создавшуюся ситуацию, при которой Республика Татарстан лишена квоты в Верховном Совете СССР и Права участия в подписании Договора об экономическом сообществе независимых государств, Верховный Совет Татарской ССР **постановляет:**

1. Верховный Совет Республики Татарстан подтверждает свою приверженность принципам Декларации о государственном суверенитете Татарской ССР, не подлежащим какой-либо ревизии. Реализация этих принципов, реальное наполнение суверенитета является обязанностью всех органов государственной власти и управления.

2. Республика Татарстан, как суверенное государство, выражает волю и решимость иметь полноправное непосредственное представительство в Верховном Совете СССР, других государственных и межреспубликанских органах Союза ССР, их структурах, а также заявляет о своем праве участвовать в подготовке и заключении соглашений между республиками, затрагивающих интересы Республики Татарстан.

3. Учитывая чрезвычайную важность Акта о государственной независимости Татарстана, сознавая ответственность, которая возлагается в связи с этим на высшие органы власти республики, на ее многонациональный народ, поручить Кабинету Министров в месячный срок представить на рассмотрение Верховного Совета ТССР анализ-прогноз изменения политико-правового, социально-экономического положения Республики Татарстан в результате принятия Акта о государственной независимости.

4. На основе рассмотрения представленных материалов Верховному Совету подготовить и провести всенародное голосование (референдум) граждан Республики Татарстан по вопросу о государственном статусе Республики Татарстан.

Председатель Верховного Совета ТССР
Ф. МУХАМЕТШИН.

Казань, 24 октября 1991 г.»

(Республика Татарстан: Новейшая история. События. Комментарии. Оценки. /авторы-составители Ф.Х.Мухаметшин и Л.В.Агеева. – Казань, 2000, стр.265.)

(Дәвамы 5 нче биттә).

Мең җидегән: вакыйгалар, хәбәрләр, яңалыклар

ИМАН НЫКЛЫГЫНА ИЛАҺИ СЫНАУ

Адәм баласы бүген аның күңеленә хуш килә торган яңалыкларга, киләчәккә өмет чаткылары уятырдай хәбәр вә үзгәрешләргә мохтаҗ. Тормыш исә аларның гел хәтәрләрен өстәп тора. Көн туды исә - яңа фаҗига, яңа бәла-казалар һәм яңа чикләүләр... Моның очы-кырые күренми һәм кайгы-хәсрәткә дә чик булмас кебек. Тик, өметсез – шайтан, ди. Үзгәрешләр, әлбәттә, булачак. Алар, глобаль дәрәҗәдә генә түгел, ә һәр кыйтга, һәр ил, һәр халык һәм һәр кешегә дә кагылачак. Кайсы якка һәм ничек кискен – монысы инде бәндәләрнең үзләренә, аларның акыл, иман һәм иҗтимагый аң дәрәҗәсенә бәйле булачак. Әйе, адәми затны бүген глобаль дәрәҗәдә сынау бара. Чөнки үзенең азынуында ул инде чик-чаманы да югалта башлады кебек: яхшыны – яманнан, акны карадан аера алмаслык халәткә житте, әдәп вә әхлак югалды, иман какшавы да отыры хәтәр колач алды... Шул ук вакытта, берсеннән-берсе дәһшәтлерәк сугыш кораллары җитештерү, ясалма интеллектка ирешү кебек бидгать гамәлләр белән масаю нормага керде, фән исә, илаһият кануннары буенча яшәүгә түгел, ә иблис вәсвәсәсенә хезмәткә күчте. Кыйммәтләр шкаласында да, рухи кыйммәтләргә караганда, өстенлекне матди якка бирү гадәткә керде. Бәгъзеләрдә хәтта, илаһи яшәештән читләшү нәтиҗәсендә җәелгән кризистан ясалма интеллект һәм җиденче технологик уклад ярдәмендә генә дә чыгып була, дигән иллюзия барлыкка килде.

Әмма иҗтимагый яшәештә илаһият кануннары югары әхлакка корылган. Чөнки аннан башка Җирдә төрле халыклар, диннәр һәм цивилизацияләр арасында гармониягә ирешү мөмкин түгел. Димәк, глобаль кризистан чыгу өчен дә җиденче технологик уклад кына җитми, ә иң элек рухи яшәешне җайга салу, ягъни Җирдә Күкләрнең җиденче катыннан иңгән рухи уклад урнаштырылуы лязем. Ә иблис коткысына бирелгән кеше, илаһи яшәештән тайпылып кына калмый, үзе дә аның кулында сәясәт коралына әверелә. Бүгенге фаҗигале чынбарлык – шуның ачык мисалы. Ә адәми зат өчен хакыйкать мизгеле җитте: йә илаһият кануннары буенча яшәүгә күчеп, Аллаһ ихтыярын һәм үзеңнең Җирдәге миссияңне җиренә җиткереп үтисең, йә җәһәннәмгә олагасың. Аның өчен инде башка сайлау мөмкинлеге калмады. Яшәешнең барлык өлкәләрен дә биләп алган глобаль кризисны исә Хак Тәгаләнең инсаннарны иман ныклыгына сынавы, дип карарга кирәктер. Нинди диндә булуына карамастан, ул барлык кешеләргә (хәтта атеистларга да) кагыла.

Ә инде татарга килгәндә, илаһи миссияле милләт буларак, аның өчен төп бурыч бүген адашканнарга хакыйкатьне аңлатуда һәм хак юлны күрсәтүдә, илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүдә үрнәк һәм әйдәп баручы көч булуда чагыла. Моның өчен аның Аллаһтан бирелгән бөтен мөмкинлекләре вә сыйфатлары да (иман ныклыгы, югары әхлак, гаделлек, тырышлык, күркәм холык, илаһи исламның иҗтиһади-тәүхиди асылын тоемлау сәләте һ.б.) бар. Ул бай һәм тирән эчтәлекле дәүләтчелек тарихына ия, Хак Тәгаләнең илаһи миссиягә әзерлек сынавын дәүләтсезлек шартларында да уңышлы үтте һәм үзенең асыл сыйфатларын саклап кала алды. Миссияле милләт буларак, Аллаһ ихтыяры белән, Урталык җирләрендә һәм Җир шарының барлык кыйтгаларында да таралып урнашкан. Бүгенге глобаль кризис шартларында ул, аннан чыгуның илаһи асылын аңлаган һәм шул юнәлештә метасәясәт (илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү сәясәте) югарылыгында да эш итәргә әзер милләт, Җирдә Күкләр ихтыярын гамәлгә ашыра торган илче булып тора.

Әлбәттә, иблис токымы моның белән килешә алмый. Ул татарның тарихын бозып күрсәтә, төрле юллар белән аны эчтән җимерергә омтыла, яла яга, мәкерле провокацияләр дә оештыра. Ләкин андый яла вә гаепләүләр инде татарга ябышмый. Чөнки ул метасәяси иммунитетка ия. Дөнья тотучы кавемнән аермалы буларак (ә ул геосәяси иммунитетка, Икенче бөтендөнья сугышы нәтиҗәләре буенча, шикле шартларда иреште), метасәяси иммунитет Аллаһ тарафыннан, изге юлда иҗтиһат кылганнарга бирелә. Чөнки илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүдә үрнәк һәм әйдәп баручы көч булган милләтне ниндидер гөнаһларда үзе иблис токымыннан булганнар гына гаепли ала. Ә татар бүген – киләчәкне ышанычлы итү өчен изге көрәш юлында. Аның уй-ниятләре – саф һәм ихлас, яшәү рәвеше – гадел. Андыйлар өчен иҗтиһат капкалары һәрчак ачык һәм аларны алда зур эшләр көтә.

Фоат УРАЗАЙ.

Утарда аюлар күбәйде

Башкортстан Республикасы Туймазы районының Төмәнәк авылы янында урнашкан «Бабай утары» тарихи-мәдәни комплексында чираттагы агач сыннар фестивале тәмамланды.

Фестивальдә Оренбург, Яр Чаллы шәһәрләреннән һәм Башкортстанның төрле төбәкләреннән килгән 11 сынчы көч сынашты. Тамашачыларга татар әкиятләре һәм бәет персонажларыннан торган агач сыннар тәкъдим ителде. Гран-svigә Туймазы районы Сөбханголавылы егете Марсель Шәймөхәмmәтов лаек табылды.

18 еллык хезмәт

Совет чорындагы ислам турында 18 ел элек төшерә башлаган документаль фильм быел сентябрьдә чыгачак. Апанай мәдрәсәсендә «Татар дин галимнәренең тарихи фәннәр үсешенә керткән өлеше» темасына узган фәнни-гамәли конференциядә фильмның трейлеры тәкъдим ителде. Конференция ун ел элек фаҗигале рәвештә һәлак булган Вәлиулла хәзрәт Якуповны искә алу максатында оештырылды.

«Совет чорында динне рәсми булмаган имамнар, абыстайлар саклаган. Бу фильмда без шундый шәхесләр турында сөйләргә уйладык», - диде Казанның Апанай мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров.

Документаль фильмның режиссеры Әмир Гатауллин әзер продуктның телевизион форматта 24 минутлык итеп әзерләнүен әйтте һәм «ТНВ», «Россия», «Культура» телеканалларның берсендә күрсәтелүенә өметен белдерде. Фильм татар, рус, төрек телләрендә чыгачак. Режиссер үзенең иҗат җимешен Төркиядә оештырылачак халыкара кинофестивальләрнең берсенә тапшырырга җыена.

«Совет чорында ислам дине турында документаль фильм төшерергә мин күптән хыяллана идем. 2004 елда үземнең идеяне Вәлиулла хәзрәт Якуповка әйттем дә, ул моны күтәреп алды, үзенең киңәшләрен бирде. Аның хәер-фатыйхасы белән без фильмны төшерә башладык. Коммерцияле проект булмагач, материал туплау унсигез елга сузылды. Төрле эпизодларда чагылган кайбер имамнар бакыйлыкка күчте инде. Аның каруы, эчтәлек ягыннан ул бик бай һәм кадерле булачак», - диде Ә.Гатауллин.

Шушы көннәрдә Әтнә районында фильмның соңгы эпизодлары төшерелә. Аларда балага исем кушу, яшьләргә никах уку, мәеткә җеназа уку чагылачак. Элегрәк материаллар Казанда, Самара өлкәсендә, Аксубай районының Иске һәм Яңа Ибрай авылларында, Нурлат районының Иске Әлмәт авылында төшерелгән.

Әмир Гатауллин проектны ахырга кадәр җиткерергә ярдәм иткәннәре өчен Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевка, Апанай мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабировка һәм Апанай мәдрәсәсенең җитәкчесе Әхмәт хәзрәт Сабировка рәхмәтен белдерде.

Заллары бар, киносы гына булсын

Татарстанда ике кинозал Кино фонды хисабына җиһазландырылачак. Сүз Алабуга һәм Арча шәһәрләрендәге кинозаллар турында бара.

Кино фондының рәсми сайтында Россия Федерациясенең торак пунктларында милли кино күрсәтү өчен шартлар тудыру максатыннан акча биреләчәк оешмалар исемлеге урнаштырылган. Исемлектә Россиянең 49 субъектыннан 103 кинозал бар. Әлеге заллар заманча цифрлы кино күрсәтү җайланмалары белән җиһазландырылачак.

Россия Мәдәният министрлыгы хәбәр итүенчә, кино залларын модернизацияләү программасы эшли башлаганнан бирле илнең 81 регионында 1175 кино залы ачылган, 200 меңнән артык яңа тамашачы урыны барлыкка килгән. 20 миллионнан артык кеше өчен заманча цифрлы кино карау мөмкинлеге булдырылган.

Быелдан башлап бер кино залын җиһазлау өчен 9 млн сум акча бирелә.

Әлеге исемлектә Чувашиядән – 2, Удмуртиядән – 3, Мордовиядән – 3, Марий Элдән 4 кино залы бар. Иң күп кино залы Башкортстанда җиһазланачак. Исемлектә 10 торак пункты күрсәтелгән.

Каһарманнар аллеясы

Башкортстанның Иглин районы Олы Теләк авылында Бөек Ватан сугышында катнашкан төрле милләттәге тугандаш халыкларның геройлары аллеясы ачылды. Аллея «Россия Дан аллеясы» проекты кысаларында булдырылган.

Якташларына һәм кунакларга сәламләү сүзе белән Башкортстан Республикасы Хөкүмәте премьер-министры урынбасары Ирек Сәгыйтов, Иглин районы башлыгы Гүзәл Насырова мөрәҗәгать итте. Шулай ук геройларның нәсел дәвамчылары, республика ведомстволары вәкилләре, Татарстан Республикасының Башкортстандагы даими вәкиле Юсуп Якубов чыгыш ясады.

«Дөньяда тынычлык булдыруга бәяләп бетергесез өлеш керткән төрле милләт каһарманнарына 20 һәйкәл куелган. Алар Бөек Җиңүгә дөньяның барлык халыклары керткән өлешнең бәясен искә төшереп торачак. Бүгенге көндә мондый идеология белән эшләнгән аллея дөньяның бер илендә дә юк», – диде тантанада И.Сәгыйтов.

Аллея булдыруны тәкъдим итүче һәм ясаучысы – биредәге крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы Хәсән Идиятуллин.

Һәйкәлләргә чәчәкләр салу тантанасыннан соң каһарманнарны бер минут тынлык белән искә алдылар. Шул ук көнне районда Сабан туе, шулай ук Sky Fest парашют спорты фестивале узды. Анда дөнья, Мәскәү, Санкт-Петербург һәм башка шәһәрләрнең чемпионнары катнашты. Шулай ук кече авиация тамашачылар өчен авиашоу оештырды.

1 нче биттә – Мамадыш районы Кече Сон авылында яңа сквер ачу уңаеннан чишмә янында күрсәтелгән фольклор күренешләре. С. Кашапова фотосы.

Грантлар файдалы проектларга юл ачты

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстанның Президент каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов «Татмедиа» АҖ Сабан туенда массакүләм мәгълүмат чаралары баш мөхәррирләре белән очрашты.

Марат Әхмәтов игътибарына грант акчалары хисабына район редакцияләрендә гамәлгә ашырылган проектлар тәкъдим ителде. «Зур рәхмәт презентацияләргә. Президентның ярдәме бушка гына китмәде, файдалы итәргә тырыштык диюегез булгандыр. Матур юнәлешләр сайлаганнар, тарихка кайту да, матурлыкны эзләү дә дөрес», - дип бәяләде.

Парламент вице-спикеры Кукмарадан Василий исемле блогерны мактап телгә алды. «Авыл тормышын соры, гайрәт чигергеч, кешене биздерә торган язмыш дип карыйлар. Василий аны блогерларча матур итеп тарата белгән. Чын журналист, булдыра бу егет дип әйтер идем», - диде М.Әхмәтов.

«Адәм баласын бертөрле тормыш туйдыра. Тормыш алга барсын өчен нииндидер эзләнү, үзгәреш кирәк. Сезнең эзләнү бу очракта бик мөһим. Журналист һөнәрен мин үзем тынгысыз, даими эзләнүләр булырга тиешле һөнәр дип саныйм. Бер генә сәгатькә дә тормыштан артта калырга ярамый. Юкса, соңга каласың, ул мәгълүматны укучы бүтән җирдән сайлап укыган, тыңлаган була, чөнки чыганаклар бихисап, – дип искәртте ул. – Сез ярышка чыккан ат кебек. Туктап калдың - төшеп калдың. Сез укучыга нәрсә кирәклеген дә таный, ишетә белергә тиеш. Укучы белән сез – бер-берегезгә кирәкле субъектлар. Яздың да, котылдың кебек, ләкин икенче уйлаганда, «укы әле» дип укырга да өйрәтергә туры киләчәк. Ике субъект аерым яшәргә тиеш түгелләр».

Дәүләт Советы Рәисе урынбасары укучыларны саклау өчен алар белән бергә булырга кирәклеген искәртте.

«Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков очрашуда былтыр Марат Әхмәтовның Болгарда семинарда катнашканын хәтергә төшерде. «Шунда безгә бүләк ясалган иде, финанслата ярдәм грантлар рәвешендә газеталарга таратылды, 66 төрле проект барлыкка килде», – диде ул.

Шамил Садыйков республикадагы гаммәви мәгълүмат чаралары редакцияләренә бирелгән грантларның район журналистына ярдәм дә булуын, файдалы проектлар да тудыруын ассызыклады: «Һәр редакция үз грантын сайлады. Грант басма матбугатны, социаль челтәрне, видеоформатны колачларга тиеш иде. Һәр филиал үз темасын сайлады. Каядыр кешеләр тарихын, каядыр югалган авыллар темасын сайладылар».

Чибәр, затлы ханым иде



Татар театры дөньясы бик зур югалту кичерде. Камал театрының танылган актрисасы, Татарстанның халык артисты Раушания Юкачева вафат булды.

Раушания Хөснетдин кызы 1959 елның 18 февралендә Татарстанның Питрәч районы Күн авылында туа. 1981 елда Казан театр училищесын тәмамлый һәм Әлмәт театрында эшли башлый. 1983 елдан – Татар академия театрында. Иң билгеле рольләре: Зарима – «Китәм инде» (Р.Хәмид); Гайни – «Бәхетсез егет» (Г.Камал); Айшә – «Без китәбез, сез каласыз», Тәмлетамак – «Авыл эте Акбай», Саҗидә – «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т.Миңнуллин); Фирдәвес – «Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», Руфия – «Бичура» (М.Гыйләҗев); Нина – «Тол ханымда тукталыш» (Э.Лабиш); Мәрфуга – «Саташкан сандугач» (Р.Зәйдулла); Танай – «Җирән чичән һәм Карачәч сылу», Бәди – «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт); Саҗидә – «Килә ява, килә ява...», «Ява карлар, ява карлар...» (З.Хәким) h.б.

Актрисаны соңгы юлга Камал театры фойесыннан озаттылар. «Раушания Юкачева – милли сәхнәбезнең якты йолдызларының берсе. Кабатланмас үзенчәлекле табигый таланты, киң сәхнә диапазоны, нечкә сиземләве һәм шәхси сыйфатлары аңа гаҗәеп тормышчан образлар иҗат итәргә мөмкинлек бирде. Раушания апа иҗади эшчәнлек белән берлектә администрация эшчәнлегендә дә күп хезмәт куйды. Ул хезмәттәшләренә ышанычлы, киң күңелле дус, яшь буын өчен кайгыртучан ярдәмчел остаз булды. Халкыбызның сөекле артисты Раушания Юкачеваның якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр», – диде хушлашу чыгышында Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин.

Якыннары, хезмәттәшләре, чордашлары Р. Юкачеваның матур, чибәр, затлы, мәрхәмәтле, көчле рухлы ханым булуын, сәхнә өчен янып йөргән искә алдылар.

Артист ханымның җәсәде туганягы – Питрәч районы Күн авылы зиратында җир куенына иңдерелде.

Әдәби калалар

Алабугада Борис Березовскийның халыкара музыкаль фестивале сәхнәсендә Россия язучылар берлеге рәисе Николай Иванов Алабуга шәһәре мэры Рөстәм Нуриевка «Россиянең әдәби шәһәре» дипломы һәм вымпелын тапшырды.

Иртәгәсен шундый ук диплом һәм вымпелны Чистай шәһәре җитәкчелеге кабул итеп алды. Тантанада Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин һәм Чистай районы башлыгы Дмитрий Иванов катнашты.

«Татарстан шәһәрләре мондый статуска беренче мәртәбә ия булды. Республиканың берьюлы ике шәһәренә мондый исем бирелү горурлык уята», – дип хәбәр итә Татарстан Мәдәният министрлыгы.

«Россиянең әдәби шәһәре» мактаулы исеме Россия язучылар берлеге идарәсе карары буенча тапшырыла. Бу исем әдәби мирасны саклауда, рус әдәбиятында сәнгати сүзне һәм классик традицияләрне пропагандалауда, әдәби процессны оештырудагы казанышлар өчен бирелә.

Почетлы исем тапшыруга нигез булып Бөтенроссия әдәби чаралар үткәрү, әдәби берләшмәләрнең активлыгы, әдәби музейлар булуы, әдәби ядкәрләрнең саклануы, шәһәр хакимиятенең әдәбиятчылар проблемасына игътибарлы булуы, альманахлар, журналлар, әдәби газеталар чыгуы, китапханәләрнең язучылар белән очрашулары актив үткәрүе тора.

«Россиянең әдәби шәһәре» исеменә Төмән өлкәсенең Ишим, Омск өлкәсенең Тара, Брянск өлкәсенең Трубчевск, Калуга өлкәсенең Таруса, Краснодар краеның Анапа, Тамбов өлкәсенең Мичуринск калалары ия булган.

Хор сәфәре

Казан федераль университетының Татар халык хоры Бурятия Республикасында татарча концерт программасын тәкъдим итте. 55 еллык тарихы булган коллектив Бурятиянең Максимиха авылында һәм Улан-Удэ шәһәрендә татар, грузин, инглиз, рус һәм итальян телендә җырлар башкарды.

«Улан-Удэ шәһәрендә җирле татарлар, бурятлар Татар милли-мәдәни автономиясе әгъзалары белән очраштык. Безнең килүгә бик сөенделәр, чөнки татар көйләренә бик сусаганнар», – диде хорның алыштыргысыз җитәкчесе Ирнис Рәхимуллин.

Улан-Удэдагы концерт Бурятиянең Татар милли-мәдәни автономиясенең 25 еллыгы һәм Татар халык хорының 55 еллыгына багышланды.

«Мин Татар халык хорының зур җанатары. Казанда булганда аның концертын исем китеп тыңладым. Шулчак: «Безнең якларга – Байкал күленә дә килегез! Сезнең тавышлар анда да яңгырарга тиеш», – дип чакырган идем. Уй-теләкләр чынга ашты, килгәнегез өчен рәхмәт», – диде Бурятиянең Татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Саҗидә Батталова.

Бурятиянең «Россия әрмәннәр берлеге» төбәк бүлекчәсе рәисе Марсель Арутюнян Татар халык хоры зур залларда чыгыш ясарга лаек дип саный. «Россия төбәкләре буйлап үз милләтеңнең гореф-гадәтләрен, җырларын күрсәтеп йөрү зур бәхет. Концертлар белән безгә ешрак килсәгез иде», – диде ул.

«Миңа тиздән 88 яшь тула, 40 яшькә яшәргәндәй булдым. Без Казаннан бик еракта яшибез, ватаныбызны сагынабыз. Безне татар җыр-моң дөньясында йөздердегез», – диде Бурятиянең аксакаллар советы рәисе Руфия Мирзаева концерттан соң.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

● Уинстон Черчилль әрмән коньягы яраткан һәм көн саен бер шешә 50 градуслы «Двин» эчкән. Әмма бервакыт ул коньякның тәме начарлануны сизгән һәм бу хакта Сталинга әйткән. Аны ясаучы оста Маргар Седракян кулга алынып, Себергә сөрелгән икән. Сталин фәрманы белән аны иреккә чыгарганнар, кире партиягә алганнар. Черчилль кабат тәмле коньяк эчә башлаган, ә Седракянга Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелгән.

Татар конгрессының оешу тарихы

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Дөрес, бу әле дәүләт бәйсезлеге турында Акт үзе түгел, ә аны әзерләү буенча карар гына иде, әмма ул тормышка ашырылмады. Югыйсә, Советлар Союзы җимерелеп барган, алдагысы билгесез булган бу катлаулы чорда күп кенә союздаш республикалар дәүләт бәйсезлеге турында актлар кабул итеп куйды, Татарстан бу мөһим эшне ярты юлда калдырды. Ул гына да түгел, Татарстанның Россия белән төрле өлкәләрдә килешүләр төзү буенча сөйләшүләр алып баруы ачыкланды. Моның нәтиҗәсендә суверенитетка куркыныч янавын аңлаган татар милли-азатлык хәрәкәте ашыгыч рәвештә корылтай җыярга һәм Милли Мәҗлес сайларга, дигән карарга килә. Аны оештыру эшләрендә «Иттифак» партиясе, «Суверенитет» комитеты, «Азатлык» татар яшьләре берлеге, «Мәрҗани» җәмгыяте, Татар иҗтимагый үзәгенең* Чаллы һәм кайбер бүлекләре катнаша. Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең* төп оешмасы Милли Мәҗлесне оештыру эшләрендә катнашмый, безгә билгеле булганча, алар хакимият белән берләшеп, үз Милли Мәҗлесләрен төзәргә уйлаганнар, соңыннан бу проект Бөтендөнья татар конгрессын оештыруда чагылыш таба.

Әйе, ул чорда СССРның ил буларак юкка чыгуы, миллионлаган татарның читтә аерылып калуы, Татарстан җитәкчеләренең үз милләтенә карата битарафлыгы, зур авырлыклар белән яулап алган бәйсезлекнең юкка чыга баруы татар милләтчеләрен Халык Парламенты – Милли Мәҗлес төзүгә этәрде. Мондый катлаулы сәяси шартларда татар халкының язмышын үз кулына алырлык экстерриториаль милли идарә органы кирәк иде, һәм Милли Мәҗлес шул эшкә алынды. Корылтай, беренче эше итеп, үзенең вәкаләтләре турында Декларация кабул итте, 6 пункттан торган бу документта корылтай татар халкының мәнфәгатьләрен чагылдыручы бердәнбер орган, дип игълан ителде, аңа татар халкы исеменнән үзбилгеләнергә вәкаләт бирелде, шулай ук корылтайга татар халкы исеменнән дәүләт оешмаларына мөрәҗәгать итәргә хокук бирелде, корылтай араларында эшләргә Милли Мәҗлес сайларга рөхсәт ителде.

Татар халкының беренче милли корылтае утызга якын мөһим документ кабул итте, шулар арасында «Милли Мәҗлес турында закон», «Халык җыеннары һәм Милли Мәҗлеснең җирле үзидарә органнары турында закон», «Татар халкының Милли Нәзарәте турында закон», «Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеге турында закон», шулай ук Берләшкән Милләтләр Оешмасына, Ислам Конференциясенә, дөнья илләренә һәм халыкларына Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеген тануны сорап кабул ителгән мөрәҗәгатьләрне әйтергә була.

Корылтай шулай ук Милли Мәҗлескә 100 депутат сайлап куйды, Мәҗлеснең беренче рәисе итеп Татарстан Югары Советы депутаты Тәлгать Абдуллин сайланды. Мәҗлес депутатлары арасында Татарстан Югары Советы депутатлары да шактый иде, шулардан Фәүзия Бәйрәмова, Җәмил Сафиуллин, Раиф Галиев, Тәлгать Шиһабиев, Мөдәррис Шәйхиев һ.б. Милли Мәҗлеснең беренче сессиясендә үк, Башкарма орган буларак, Милли Нәзарәт төзелде, аның рәисе итеп Илгиз Бариев билгеләнде. Мәҗлес каршында милли мәдәният, милли мәгариф, халыкара эшләр, хокук, милли икътисад, дин, экология буенча комиссияләр төзелде, шундый ук комитетлар Милли Нәзарәт каршында да эшли башлады.

Әмма Татарстан җитәкчеләре, хокук саклау органнары Милли Мәҗлес төзелүне тыныч кына кабул итмәде. Иртәгә корылтай буласы, дигән көнне, 31 гыйнварда Татарстан президенты М.Шәймиев иҗтимагый оешмаларга каршы указ чыгарды, аларны дәүләт эшләренә тыкшынсалар, җәза көтәсен кисәтте. Ә инде корылтай узып, Милли Мәҗлес төзелгәч, бу мәсьәлә хәтта 7 февраль көнне Татарстан Югары Советы сессиясендә дә каралды, «федералист» рус депутатлары Милли Мәҗлесне дәүләткә каршы оешма дип гаепләп чыкты. Нәтиҗәдә, Югары Совет Милли Мәҗлеснең корылтайда кабул иткән карарларын законсыз, дип тапты һәм үз карарын кабул итте. Тарих өчен әһәмиятле булганга, бу карарны укучыларга да тәкъдим итәбез:

«**Из постановления Верховного Совета РТ:**

На состоявшемся в городе Казани 1-2 февраля 1992 года курултае представителей части татарского народа образован Милли меджлис (Национальное собрание) Татарстана и приняты ряд актов, не имеющих юридической силы.

Учитывая, что в соответствии с Законом РТ «Об основах народовластия Республики Татарстан» ни одна партия, ни одна общественная организация не могут присвоить себе право на осуществление государственной власти в РТ, Верховный Совет РТ **постановляет:**

1. Признать недопустимыми попытки решения кем бы то ни было неконституционным путем вопросов национально-государственного, экономического и социального развития многонационального народа РТ.

Ф.Мухаметшин,
Председатель Верховного Совета Республики Татарстан.
7 февраля 1992 года.»

Күрәсез, Татарстан җитәкчеләре Милли Мәҗлеснең хакимияткә килүеннән уттан курыккан кебек курыккан, аңа каршы хәтта дәүләт дәрәҗәсендә карар кабул иткән. Әйе, Милли Мәҗлес дәүләтчелек һәм милли мәсьәләләрдә Татарстан җитәкчеләренә көчле басым ясады, чигенүләр булса, Югары Советны үзләре белән алыштырасыларын белдерде. Милли хәрәкәтнең шушы көчле басымы астында, Югары Совет Татарстанда бәйсезлек буенча референдум үткәрү турында 20 февральдә карар кабул итте, ул референдум 21 март көнне үтте һәм Татарстан файдасына булды. Шулай ук Милли Мәҗлеснең, Татарстан Югары Советындагы милләтче депутатларның көчле басымы астында, 1992 елның 6 ноябрендә Татарстанның яңа Конституциясе кабул ителде. Болар – татар милли хәрәкәтенең һәм Татарстан хакимиятенең уртак башкарган соңгы зур эшләре иде, моннан соң алар бер-берләренә каршы оппозициягә басты. Мондый шартларда Татарстан җитәкчелегенә, хакимияткә, ихтыяҗ чыкканда таяну өчен яңа милли оешма кирәк иде, Бөтендөнья татар конгрессы менә шундый вәзгыятьтә барлыкка килде. Милли Мәҗлес астан, халык арасыннан үсеп чыкса, татар конгрессы Татарстан Президенты фәрманы белән туды, югарыдан оештырылды. Инде күпләр таныганча, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Мәҗлескә алмашка, альтернатива буларак оешты.

Шушы аермалыкларга һәм каршылыкларга карамастан, Милли Мәҗлес һәм Бөтендөнья татар конгрессы чирек гасырга якын янәшә барды, чөнки милләт бер иде. Бу елларда Милли Мәҗлес эчке сәясәт өчен «Татар Кануны», «Гаилә кодексы», «Милли мәгариф концепциясе», «Милли мәхәллә һәм җирле үзидарә программасы» кабул итте, аны халыкка таратты, шулай ук тышкы сәясәттә Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларациясен тануны сорап, Берләшкән Милләтләр Оешмасына, Халыкара хокук яклау оешмаларына, дөнья парламентларына мөрәҗәгать итте. Бөтендөнья татар конгрессы урыннарда үзенең структураларын, бүлекчәләрен барлыкка китерде, алар барысы да диярлек татар милли хәрәкәтенең элеккеге оешмалары иде. Һәм төбәкләрдәге күпчелек милли лидерлар Бөтендөнья татар конгрессы эшендә дә катнашып китте. Асылда татар конгрессы зур сәясәткә катнашмады, нигездә мәдәни юнәлештә эшләде, төрле тармаклар буенча комитетлар төзеп, аларны зур форум-җыеннар дәрәҗәсенә хәтле үстерә алды. Иң мөһиме, Бөтендөнья татар конгрессының милләт алдында иң зур эше – ул төрле өлкәдәге белгечләрне барлый һәм берләштерә алды.

Безнең Бөтендөнья татар конгрессын милләтнең хокук яклаучысы итеп күрәсе, Татарстанның дәүләт суверенитетын, татар телен, милли мәктәпләрне, хаксызга рәнҗетелгән милләттәшләребезне яклап, үз сүзен әйтүен ишетәсебез килде. Әмма татар конгрессы хакимият куйган чикләрдән үтә алмады, чөнки ул ирекле, мөстәкыйль оешма түгел иде.

Кызганычка, бүген элеккеге милли хәрәкәт юк инде – туктаусыз хөкем ителеп, ул бастырылды, туздырылды, таркатылды, вакыт та үзенекен эшләде. Әмма алар күтәргән идеяләр, милләтнең бәйсезлеккә омтылуы – үлемсез, алар хыялланган гадел тормыш – җәмгыятьнең нигезе, һәм яңа буын үз вакыты җиткәч бу идеяләрне тормышка ашырачак әле, иншаллаһ! Һәм Татарстанның, милләтнең бу утыз еллык үзгәрешләр чорына нәкъ менә татар милли-азатлык хәрәкәте гамәлләренә карап бәя биреләчәк. Ә Бөтендөнья татар конгрессы – мондый болганчык чорда, милләт бөтенләй юкка чыкмасын, тәпкә китмәсен өчен бер таяныч-мәйдан булып тора. Аның язмышы Татарстан язмышы белән бик нык бәйләнгән, алга таба Бөтендөнья татар конгрессы Татарстан булганда гына яши алачак. Шуңа күрә татар конгрессы берничек тә сәясәттән читтә кала алмый, ул Татарстанның дәүләт суверенитетын күкрәген куеп якларга тиеш булачак, чөнки башка оешмалар калмады. Һәм татар конгрессы татар тормышына, милләт яшәешенә тагын да якынаерга тиеш, югыйсә ул моңа кадәр иҗтимагый-икътисади мәсьәләләр белән шөгыльләнмәде, җәмгыятьтән шактый ерак торды. Татар конгрессы һәр татар өчен ачык булганда гына ул милләт тормышына үтеп керә алачак. Татар конгрессы йөзендә милләт үзенең яклаучысын таба икән, ул аның артыннан китәчәк, Татарстанның дәүләтчелеген саклап, тагын мәйданнарга чыгачак, көрәшкә күтәреләчәк. Татар язмышы үзенең милли азатлыгы өчен туктаусыз көрәштән гыйбарәт, ул тарих бүген дә языла... Бөтендөнья татар конгрессы өстендә менә шундый олы җаваплылык: милләтебез һәм дәүләтчелек өчен гасырларга сузылган көрәшне дәвам итү. Дөнья яңадан бүленеп ятканда, Бөтендөнья татар конгрессының төп стратегиясе шул.

*Экстремистлык эшчәнлеге өчен оешманың эше суд тарафыннан туктатылды.

Горурлык һәм сызлану

Эльмира Шәрифуллинаның «Каюм коесы» поэмасы – К.Насыйри эшчәнлегенә шагыйрә тарафыннан салынган шигъри һәйкәл ул. Автор бик уңышлы чагыштыру куллана: галим туып-үскән нигездә аның үз кулы белән казыган коесы сакланган икән. Ул коедан халык әле дә файдалана, су ала. Шул суны шагыйрә «гыйлем суы» дип атый; халкыбыз ул коедан гыйлем суы ала, үзен белем белән сугара. Чөнки Каюм ул белемне, мәкальдә әйтелгәнчә, «энә белән кое казып» булдырган һәм хәзер шуны туган халкына кайтара, бүләк итә.

Поэмада галимнең энциклопедик эшчәнлеге поэтик чаралар белән яктыртыла: әсәр җиде бүлеккә бүленгән; аларга эпиграф итеп К.Насыйридан алынган сүзләр китерелә. Менә ул Каюм коесыннан алына торган су – хәзинә! Бу бүлекләрдә шагыйрә К.Насыйриның нәсел-нәсәбен, аның эшчәнлеген – татар балаларын алга җибәрү өчен рус теленнән дәресләр бирүен, ана телен фән теле дәрәҗәсенә күтәрү өчен янып йөрүен, авыз иҗаты әсәрләрен җыеп бастыруын, халыкка табигать нигъмәтләре турында белем бирүен һ.б. – сәнгать чаралары кулланып тасвирлый. Автор үзенең шушы бөек галимнең милләттәше, якташы булуы белән горурлана һәм әсәрне ихлас, әмма тыйнак теләгән әйтеп тәмамлый:

И Туган җир!
Каюм коесында
Шул бер тамчы
Саф су булсамчы!

Җыентык «Без – Тукайлы халык!» поэмасы белән ачыла. Аны язу алдыннан Эльмира Тукайның дөньяга күзе ачылган Кушлавыч авылында була, Апуш уйнап үскән табигать белән таныша. Тукайны хәтерләткән һәрнәрсә, һәр урын шагыйрә өчен чиксез кадерле һәм изге. Бу сәяхәт аның хис-тойгыларын тагын да баета.

Әсәрдә шагыйрә «чирек гасыр гомер» яшәгән Тукайның тормыш юлын күздән кичерә; «бер карасаң, сабый бала кебек», «бер карасаң, аксакалдай өлкән» Тукай иҗаты белән илһамлануын, аңардан үрнәк, тәҗрибә алуын белдерә. Тукай шәхесе аны сокландыра, иҗади биеклекләргә өнди. Шагыйрә туган халкының дөньяга шундый бөек шәхес бирүе белән горурлана:

Җыры барның җирдә даны булыр,
Бәйрәмнәре булыр мәңгегә.
Без – бәхетле,
Без – шагыйрьле халык,
Без – Тукайлы халык мәңгегә!..

Эльмираның бу җыентыгында аның тагын дүрт поэмасы урын алган. Менә «Бер кычкырды кәккүк» әсәре. Ул Эльмираның җаны кебек күргән, өзелеп яраткан ире Фаил Шәфигуллинның фаҗигале үлеменә багышланган. Бу фаҗига шагыйрә күңелендә көчле давыл кузгата, аның тормышын актарып ташлый. Шуңа күрә күңеленең дулкын-дулкын булып сызлануын шагыйрә «Мин аңымда», «Кай арада», «Эзлим», «Әкиятләргә китәм», «Күзләреңә чумган гына идем», «Алып кайтмас үксү үткәннәргә», «Сызлану», «Безнең күңел» кебек бүлекчәләр аша тасвирлый.

«Мин аңымда» дигән бүлекчәдә автор әсәргә кәккүк образын кертә. Кәккүк, әйтерсең шагыйрәгә киләчәктә иң якын кешесен югалтачагын юрый; автор кәккүкнең соңгы кычкыруы белән үзенең моңа кадәрге тормышының кинәт юкка чыгуы арасында параллельлек үткәрә:

Бер кычкырды кәккүк,
Һәлакәт күк –
Бер хәбәр күк
Килер кайгыма.
Бер кычкырды кәккүк,
Тынып калды,
Салдылармы элмәк муенына?..

«Эзлим» бүлегендә автор үзенең юксынуын болай сурәтли:

Шәүләң йөри көн дә, төн дә,
Күз алдымда буй-сының.
Йомшак җилләрнең исүе
Гүя сулышың, тының...

Әмма шагыйрә, сызланса, бәргәләнсә дә, авырлыктан сыгылып төшми, лирик геройның сызлануы аның рухи көчсезлеге түгел:

Очты китте хыялларым,
Очтылар чиксезлеккә.
Кубарылып сызлый күңел, –
Юрама көчсезлеккә...

«Тәмуг кисәве» поэмасында Э.Шәрифуллинаның таланты тагын да тирәнрәк ачыла. Аны укыгач, һәр кеше күңелендә безнең тормышка кереп тамыр җәйгән каты бәгырьлелек, рәхимсезлеккә каршы нәфрәт туа. Әсәр балалары тарафыннан картлар йортына илтеп ташланган бер татар әбиенең эчке монологы рәвешендә иҗат ителгән. Бу әбинең тормышын шагыйрә:

Ул бу йортта өч ел җан асрады,
Ул бу йортта өч төн яшәде, – ди.

Автор «җан асрады» ди, чөнки картлар йортындагы гомер ул яшәү түгел инде: андагы тормышта бернинди ямь дә, яктылык та юк, ул караңгылык белән тулган тоташ кара төн кебек кенә. Андагы хәятның һәр елы, һәр көне төн кебек караңгы, төн кебек салкын:

Шул йортларда җан асрый алар,
Кирәклеген тоймый һичкемгә.
Кунак көткән кебек әҗәл көтә,
Ятлар җирли сине
Ят җиргә... – ди шагыйрә.

Төзелеше ягыннан бу поэма шактый катлаулы; ул берничә бүлеккә бүленгән: «Кыйсса башы», «Беренче төн», «Икенче төн», «Өченче төн», «Кыйсса ахыры». Һәр бүлек үз эчендә тагын бүлекчәләрдән тора: әсәрдә аларның һәрберсенең үз вазифасы бар. Бу яктан караганда поэма катлаулы композицияле романны хәтерләтә.

Әсәр кешеләр күңелендәге кешелеклелек, иманлылык сыйфатлары урынын каты күңеллелек басып алуына рәнҗү белән сугарылган. Әйе, чынлап та, бездә була торган күренешләр – яшь ананың әле генә тудырган баласын чүп савытына ташлап китүе, яшьләрнең инде җегәре беткән әти-әнисен картлар йортына илтеп куюлар да – барысы да каты бәгырьлелеккә барып тоташа бит. Поэманың «Кыйсса башы» бүлегендә әби болай ди:

Яшел сандыгымны кузгаттым да
Картлар йортына дип... юл алдым.

Әмма картлар йортында әбинең бу сандыгына да урын табылмый. Аңа әйберләрен «шырпы кабы кебек тартмага» – тумбочкага бушатырга кушалар. Әби төне буе, тормышының хатирәләрен яңартып, сандыгыннан «еллар буе кул тимәгән» әйберләрен бушата. Кулга алган һәр әйбере – тулы бер истәлек, аеры бер хатирә! Менә «сабые киеп үскән такыясы», менә «ак күбәләк төшкән, бала итәкле ал күлмәге», менә «зыр-зыр әйләнә торган орчыгы», менә туй күлмәге... Ә соңыннан сандыкның язмышы аяныч булы бетә: әби ахырда, әрнеп, «Утын келәтендә ауный әнә / Яшел сандык – яшьлек җиһазым» дип әйтергә мәҗбүр була.

Ахырда Э.Шәрифуллина әбинең картлар йортыннан качуын тасвирлый:

Качып кайттым бүген
Мәче булып,
Елый-елый тырныйм нигезне...

«Кем болгатты газиз бу җиремне / Телемне һәм денне корытты?» – дип оран сала әби. Әмма ул, ана буларак, үзен картлар йортына илтеп куйган балаларына карата рәнҗешен дә кире ала:

Рәнҗешемне кире алам, Аллам!
Үз баламны каһәр сукмасын...

Игътибар итик: никадәр гуманлылык, әрнеш һәм күңел сафлыгы!..

«Каюм коесы» китабына кергән тагын ике поэма да шундый ук осталык белән иҗат ителгән. «Мордар» поэмасында үз-үзенә кул салып, бу дөньядан киткән кешеләргә карата нәфрәт, аларның үз гаиләсенә китергән әрнеш-рәнҗешләре тасвирлана; мордар китүнең бер сәбәбе эчүчелектә булуы тәнкыйтьләнә. «Инша» әсәрендә бүгенге көндә гаиләләрдә татулык, әтиләрнең роле тасвирлана. Соңгы әсәр «Ир белән хатын бер-берсенә тиң булганда гына матур гаилә корыла ала», дигән фикер белән тәмамлана.

Э.Шәрифуллина поэмаларында тормышның бик актуаль мәсьәләләре күтәрелә. Бу әсәрләрдән укучылар кешелеклелек, гуманлылык дәресе ала. Китаптагы әсәрләр укучыларда рәхим-шәфкатьлелек, игелеклелек, сафлык, кешегә хөрмәт, изгелек кебек сыйфатлар тәрбияләүгә өлеш кертә. Бүгенге вәхшиятьтә – кеше җанын, күңелен ялап алу өчен рәхимсез көрәш алып барылган бер заманда – татар укучысына нәкъ менә «Каюм коесы» кебек сәнгати югарылыкта язылган китаплар кирәк тә инде.

Әнвәр ШӘРИПОВ,
филология фәннәре докторы.

КҮКТӘН ЯКЛАУ ЭЗЛӘДЕМ МИН

Мин күкләргә гашыйк идем бугай,
Һаман үргә таба омтылдым.
Чабаталы ятим балачагым
Кимсенүле мөһер тоттырды.

Мәрхәмәтле күккә якынаеп,
Мин үземә яклау эзләдем.
Биеклектән чынбарлыкка төшкәч,
Канап бетте шәрә тезләрем.

Ялантәпи аша җегәр керткән
Якынрак бугай Җир-анам.
Эшләп яшәү мөмкинлеген бирде,
Бәла-казалардан аралап.

Авыр чакта күз яшьләрем белән
Түтәлемдә гөлләр сугардым.
Алар барыбер җете чәчәк атты,
Яшел чирәм иде юлларым!

Аяк терәп җиргә баскан чакта,
Булсын әйдә, хыял биектә.
Җилкенүле, ашкынулы яшьлек
Рухны барыбер көчле итә.

Фәридә ШАКИРОВА

Рух саулыгы кителгәнен тоям,
Фәкать шуңа сызлый йөрәгем.

Бурычларны түләп бетермәдем,
Әҗәтләрне җыя белмәдем.
Әллә гөнаһ, әллә савап басар
Ходаемның гадел бизмәнен.

АЧЫ ҖИМЕШНЕ ДӘ ЙОТ СИН

Һәр начарлык тигәнәк күк әрсез була,
Иң әүвәле йомшакларны басып ала.
Ихтыяр көчен сындырып, мәкер белән
Колы итәр начар гадәт, син чамала.

Дым җитмәгән агачларның җимеше ачы,
Наз җитмәгән балалар да дорфа булыр.
Сугыш уйнап, экраннарга багынганнар
Табар микән игелекле гамәл юлын.

Ачы җимешне дә йот син ара-тирә,
Дәва өчен файдасы бар, икеләнмә.
Гел бер төрле сүрән тормыш шомлы бит ул,
Балан, миләш үстер әле өй тирәңдә.

Безнең гомерләр искән җил икән,
Күпме кичереш йөрәктән үткән.
Әле елатып, әле җырлатып,
Хәләл ярларны назлап сөйдерткән.

Безнең гомерләр биек тау икән,
Ашкынып менү онытылган күптән.
Аска төшкәндә һич җиңел түгел,
Йөрәк таушалган, җегәрләр беткән.

Безнең гомерләр бер яфрак икән,
Язмышлар аны чайкап селкеткән.
Бәхет өлешен калдырыр кешең
Булган тәкъдирдә яшәү уң икән.

Безнең гомерләр яуган кар икән,
Ташулар белән аккан да киткән.
Өметнең инде соңгы чырасы,
Дәрман тапмасаң, сүнәргә җиткән.

Безнең гомерләр тере ут икән,
Сүнмәс куәте җанга береккән.
Әле соң түгел, тормыш мәгънәсен
Бизмәнгә салыр вакытлар җиткән.

Безнең гомерләр бердәнбер икән,
Шөкер итәргә акыллар җиткән,

Бурычларны түләп бетермәдем, Әҗәтләрне җыя белмәдем...

СЫТЫЛЫП БЕТТЕ НЕЧКӘ ХИСЛӘРЕМ

Мал һәм дан өчен нәфес күпертеп
Кеше хакына кулым сузмадым.
Терәгем алдан әйдәп тормагач,
Түмгәкле булды барыр юлларым.

Кеше башына килгән сынауга
«Шул кирәк» – диеп, йөрмә сөенеп.
Утта яндырып, суга агыздым,
Җилгә очырдым хәсрәт төенен.

Бер дә хатасыз фәрештә – күктә,
Каралтма кемне, үзең ак булгач,
Дөнья үзгәрә, язмыш аяусыз,
Үкенү туа, казан дөм тулгач.

Утта мең пешеп, суда чайкалып,
Чыныгып каткан тимер-чуен күк,
Нечкә хисләрем сытылып бетте,
Күз яшем кипте, кизәнмә берүк!

Йөз суы түгеп, төчеләнмәдем,
Туры сүз сөйләр хакым булганга.
Бәгырем кисеп ямаулар салдым,
Аяк очына тарткан юрганга.

Ирешкән малым хәләл көч белән,
Михнәт күп күрдем, диеп офтанмам.
Таш асып мендем гел югарыга,
Төшеп киләмен текә таулардан.

Җирдә яклаучым санаулы гына,
Терәгем булган фәрештәм уяу;
Дошманыма да җәбер салмадым,
Мин һаман да әле сабый бугай.

Иманга бәйле садә бер сафлык
Яктыртыр төсле бөтен дөньяны.
Игелек кылырга тормыш юлында
Барыбызга да гомер бар әле!

КУЛЛАРЫМ

Сөяллләнгән җәрәхәтле кулларымда
Балачактан сеңеп калган әрем исе.
Гел эш белән йөдәп беткәч, кайчагында
Калмас кебек кашык күтәрергә көче.
Ә соң сиңа әзер тәгам кем китергән –
Чыда, кулым, әле хезмәт итәсең күп.
Инде күптән бурычларың түләнгәндер –
Дога кылып утырсаң да булыр бик хуп,

Дип уйлый да вәсвәсәле нечкә күңел,
Игелекле кулым кабат каләм ала.
Һәрбер юлы мәгънә белән сугарылган
Шигырь туса, бөтен борчу артта кала.
Чыдам куллар хәрәкәттә булган чакта,
Орлык шытып чәчәк ата, нуры тама.
Шөкер итәргә вакыттыр игелекле
Куллар аша чиксез муллык тудырганга.

* * *

Вак хата булышыр барыбер
Яшәүнең мәгънәсен табарга.
Ашыгып утларга кергәнче,
Кирәктер гел өреп кабарга.

БУРЫЧ

Илең каршындагы бурычыңны
Үтә, диеп кемнәр өндәде?
Үтәдем, тик шәфкать көтми генә,
Үз тормышым үзем көйләдем.

Анам хакындагы бурычларны
Һичкайчан да онытып йөрмәдем.
Михнәт баскан толлык аркасында
Елмайганын сирәк күргәнмен.

Әтиемнең җирдә яшәгәнен
Фәкать ишетеп кенә белгәнмен,
Ихлас догаларым барып җитеп,
Җылытса иде салкын гүрләрен.

Ир каршында булган бурычымны
Тормыш йөген тартып үтәдем.
Аңа яшәү рәхәт булсын, дидем,
Үзем хыянәткә кермәдем.

Бала алдындагы бурычларны
Һич тә авырсынмый күтәрдем.
Таләпчәнлек катыш мәхәббәтне
Күңел күзе аша үткәрдем.

Халкымны һәм илне, эшне сөйдем,
Үз-үземне башук сөймәдем.
Кадер-хөрмәтләрдән мәхрүм итеп,
Чи тиредәй җанны иләдем.

Бурычларым кала күрмәсен дип,
Хәләл көчем белән түләдем.
Кылган игелек әҗеренә торган
Яхшылыклар көтеп йөрмәдем.

Аллаһ каршындагы бурычымны
Читкә куеп гамьсез йөргәнмен.

Һәркемнең дә күркәм ягы бар эзләсәң,
Ашыкма син начар диеп бәяләргә.
Бер хатасыз кеше булмас Җир йөзендә,
Нигә һаман ышкылырга сөяләнә?

УЙЛАНУ

Якынайды, артык якынайды
Гөнаһ белән савап арасы.
Фәнис Яруллин

Яшьлектә ул хата күп китәдер,
Яшәр өчен акыл, көч кирәк.
Үз биеклегенә менә алыр бөркет,
Ашкындырса кайнар дәрт, йөрәк.

Тик шулай да ялгыз гына очып,
Уңышларның тәме сизелмәс.
Бер-берсенә терәк булса әгәр,
Сынауларда дуслар җиңелмәс.

Әнә, кошлар, ерак очар өчен
Берләшәләр бердәм төркемгә.
Хәзер исә кеше бик үзгәрде,
Беркем кирәк түгел беркемгә.

Ярдәм сорап син ялварып кара,
Кемнәр сузар икән уң кулын?
Атасыннан калыр малны көтәр
Игелексез, денсез үз улы.

Хыянәткә ымсындырган заман
Ишек ватып уза түрләргә.
Бозыклыкның әллә ничә төре
Тартып тора кара гүрләргә.

Якынайды, артык якынайды
Гөнаһ белән савап арасы.
Сират күперләрен кичкән чакта
Ничек мәтәлмичә каласы?..

Әллә, бәлки, иман байлыгына
Туплангандыр саклау чарасы.
Ана догасы да коткарадыр,
Ялгышканда газиз баласы.

ГОМЕРЛӘР УЗА ИКӘН

Безнең гомерләр аккан су икән,
Хәтта елгалар саеккан, кипкән.
Чишмәдәй ургып яшәү сәләте
Көрәшеп яшәр өчен йөгерткән.

Безнең эзләрдә үлән яңарган,
Безнең эзләргә энҗе кар сипкән.
Кояш нурында җаны җылынып
Бирешми торган ул гел без икән!!!

ШАГЫЙРЬГӘ

Нечкә хисләр белән җаның сыкранганда
Ак кәгазьгә моң сеңдереп бик күп яздың.
Күңелеңне чистарттың да бар таплардан,
Яшәү өчен иҗатыңнан дәрман алдың.

Бу шау-шулы тормышлардан аргансыңдыр.
Вокзал кебек ыгы-зыгы алҗыта бит.
Вак борчудан өстен булып кала алсаң,
Илһам нуры тудырырга табигать киң.

Уйланырга, гамьләнергә, моңаерга,
Тансык күңел назы белән сызланырга
Әле ярый искитмәле табигать бар,
Хозурлыкта иҗатыңа дәрман туар.

Киң мәйданда көрәшчеләр бил алыша,
Дан өчен дә, мал өчен дә адарынып.
Тере шагыйрь мескен булып йөрмәсен ул,
Кемдер яннан узып китсә кабарынып.

Башкаеңны туры тот син, зиһенле зат,
Илһам нурын сиңа төбәп күктән иңгән.
Маллар китәр, даннар узар, гомер кимер,
Тукай кебек даһиларны тарих белер!

Масайма да, үртәлмә дә, кыланма да,
Халкыңа илт бәрәкәтле кайнар сулыш.
Хак сүзеңне әйтер өчен батыр бул син,
Җан дәвасы көткәннәргә ихлас булыш!

Йөрәгеңнең кайнар хисе таш эретсен,
Милләт гамен һәр күңелгә илтеп җиткер.
Ходай сиңа ныклык бирер, чигенмәсәң,
Гаделлеккә көрәш юлы булыр читен.

Иҗат дигән татлы газап кичергәндә,
Шагыйрь үзе тере килеш дөрләп яна.
Ә аларның безнең җанга уеп салган
Хак фикере, тапкыр сүзе исән кала!

Балтач.

Тинчурин театры чираттагы сезонын «Умай» опера лабораториясе эскизларыннан төзелгән өч пәрдәлек опера спектакле белән япты. Театрга килеп керүгә операда башкарылачак текстларны – либреттоны укырга тәкъдим иттеләр. Спектакльдән соң фикер алышулар булачагын да искәрттеләр. Кайткач уку нияте белән, либреттоны сумкама шудырдым да залга уздым. Зал тулы иде, әмма тамашачының төп өлеше Тинчурин театрының традицион тамашачысы булмавы күренеп тора, күбесе шәхсән Туфанның тугрылыклы тамашачысы.

УҢАЙМЫ «УМАЙ»,

Белешмә. «Ал яулык, зәңгәр шәл» өч пәрдәле операсы – Тинчурин театрының «Умай» опера лабораториясе эшчәнлеге нәтиҗәсе. Бу татар театры тарихындагы беренче феминистик лаборатория. Аның кысаларында татар телендә өч кыска камера операсы язылган. Опер়алар татар хатын-кызларының татар мәгърифәтенә һәм тарихи үзгәртеп коруларга керткән өлешенә багышлана, татар мәдәниятендә хатын-кызның тоткан ролен һәм аның дөньяга карашын чагылдыра. Беренче операның сюжеты – татар мифологиясеннән, икенчесе – узган гасыр башындагы, ягъни җәдитчелек чорындагы татарларның тормыш-көнкүрешеннән, өченче операда исә хәзерге заманның көрәшче хатын-кызларының язмышы чагыла.

Өч өлештән торган опера спектакле 1 сәгать 20 минут чамасы барды. Дөресен әйткәндә, татар драма артистлары хәзер яхшы вокал белән мактана алмый. Тинчурин театры да шул исәптән. Бу труппада көчле вокаллы егет – Илнур Байназаров. Зөлфия Вәлиева һәм Лилия Мәхмүтова опера сәхнәсенә дәгъва итәрлек булмаса да, драма артистлары өчен җырлау сәләте яхшы дәрәҗәдә, Ренат Шәмсетдинов ритмны тоюы һәм харизмасы белән үзенә карата.

Операларга бәя бирергә алынмыйм. Беренчедән, бу бернича айда иҗат ителеп, сәхнәләштерелгән лаборатория эше, монда операның югары ноктасы, ниндидер сәнгати югарылык турында сүз бармый. Бөтен команда да зур акчаларга түгел, идея өчен эшләгәндер. Чөнки операның нинди кыйммәтле сәнгать төре икәнен дә, опера язучыларның, куючыларның, башкаручыларның нинди акчалар белән эш итүен дә беләбез.

Әлеге опера спектакле татар хатыны турында. Татар хатыны ул күптөрле – укыганы, укымаганы, наданы, акыллысы, кыйналганы, кыйналмаганы, шаһиннәсе, эт типкесендә йөрүчесе бар. Иҗат кешесе аларның барысын да күрсәтә ала.

Лабораториянең драматурглары, либреттистлары һәм композиторлары – хатын-кызлар. Алар бер-берсенә бәйләнмәгән өч тема сайлап өч опера әсәре тудырган. Сценограф та хатын-кыз. Ул өч әсәрне бер стильгә берләштереп декорация, костюмнар ясаган. Бер-берсенә бәйле булмаган өч сюжеттан дүрт режиссер 20 шәр минутлык опера спектакльләре куйган. Соңыннан әлеге өч әсәр берләштерелеп, аларны тоташтыра торган текст эшләнгән һәм гомуми исем бирелгән – «Ал яулык, зәңгәр шәл».

Операда рольләрне Лилия Мәхмүтова, Зөлфия Вәлиева, Артем Пискунов, Резедә Сәләхова, Айсылу Мөсәлләмова, Илнур Байназаров, Ренат Шәмсетдинов, Венера Низамова башкара. Хорда Альбина Гашигуллина, Альбина Сираева, Юлия Выборнова, Алинә Мөхлисова, Илзирә Алиәкбәрова, Эльвина Кәримова, Зәринә Сафина, Әдилә Хәсәнова катнаша.

Композиторлар – Алсу Сөнгатуллина, Анастасия Костюкова һәм Алинә Кәримова. Режиссерлар – Булат Минкин, Камил Гатауллин, Рамил Камалов, Илнур Гарифуллин. Спектакльнең музыкаль җитәкчесе – Ильяс Камал. Хореограф – Марсель Нуриев. Рәссам – Лилия Имаметдинова.

Сорау: ни өчен без композиторларның, режиссерларның һәм сценографның исемен белдек – алар пресс-релизга язылган. Ни өчен драматурглар һәм либреттистлар үз исемнәрен чыгарудан баш тарткан? Бәлки, оештыручыларга төрле сәбәпләр белән авторлыгын күрсәтергә теләмәгән ханым-туташларны проекттан чыгарырга кирәк булгандыр? Ярар, проект быелга өлгермәс иде, аның каруы һәр автор үзенең һәр язган җөмләсе өчен җавап бирер иде. Әгәр син иҗатың өчен символик суммада булса да гонорар алгансың икән, дәүләт акчасы синең хисабыңа дәүләт театры бухгалтериясеннән рәсми юл белән күчерелгән икән, ни өчен исем әйтелмәскә тиеш?

• Шагыйрә Гөлүсә Батталованың бер сүзе искә төшә: «Мин үз шигырьләремнең һәр юлы өчен көрәшергә әзер», дигән иде ул. Ә сез нишләп көрәшмисез, шагыйрәләр һәм драматурглар?

«Мин беренче әсәрнең либреттисты», дип тамашачы алдына кыю чыгып баскан Миләүшә Гафуровага рәхмәт. Өченче операның режиссеры Илнур Гарифуллинга рәхмәтләрем. Ул да тамашачы алдына чыгып үз карашы турында сөйләде. Югыйсә, исемсез телеграм-каналлар заманы китте, исемсез журналистлар яза. Җайлы бит ул «билгеле эченнән йодрык күрсәтеп» батыраеп йөрү.

Әлеге өч операга килсәк, алар арасыннан миңа аның өченчесе нык тәэсир итте. Тема – милли мәгариф. Сюжетның герое – куылган укытучы урынына килгән яңа мөгаллимә. Ә алдагы укытучы «Өлкән ак яулыклы ханым, ак нур белән яктыртылган ханым» белән очрашу ясаган өчен куылган. Яңа мөгаллимә - Зөлфия Вәлиева башкаруындагы Укытучы башка юлны сайлаган: «...сөйлисеңме-юкмы – үзең сайла. Мин сайладым һәм мин дәшмим генә», – ди.

Әлеге опера – милләт анасы булган «ак нур белән яктыртылган ханымны» ялалардан яклау, аклау, аңа соклану, аны зурлау – мин шулай аңладым. Беренче операда туган бала өченчесендә милләт анасы булып җитешә – кем нәрсә күрсә дә күргәндер, мин шуны күрдем, мин шуны тойдым. Шушыны яза алган хаттта исемсез авторларга да рәхмәт.

Өченче операдагы образ – бүгенге көнебез. Исемсез авторлар да бүгенге көнебез. Әлеге образны башкарган Зөлфия Вәлиева мең кат хөрмәткә лаек. Зөлфия Вәлиева – туксанынчы еллар азагында театрның йолдызы иде. Әмма ниндидер сәбәпләр аркасында ул бераз күләгәдә калды һәм үзен эстрадада табарга тырышты. Ниһаять, ул шушы экспериментал әсәр аша булса да, театрда кем йолдыз икәнен күрсәтә алды. Аның тавышында гражданлык позициясе дә бар иде.

Мондый кыю темага алынган лабораториягә, аның кураторларына, аерым алганда, әлеге лабораториянең идея авторы Энҗе Дусаевага һәм барысы өчен дә – начары өчен дә, яхшысы өчен дә – җаваплы булачак Туфан Имаметдиновка рәхмәт.

* * *

Иң кызыгы опера тәмамлангач башланды. Фикер алышу дип аталган импровизацион спектакль иде ул. Импровизацион спектакль - Туфан Имаметдиновның яраткан жанры. Фикер алышуны Нурбәкнең башлап җибәрүе әлеге импровизацион спектакль Туфан тарафыннан махсус корылган дигән уйлар тудыра. Әйе, башта аның үзенә дә уңайсыз булганын тойдым. Ләкин ул шушы кадәр шау-шу тудыра алуыннан, пар чыгарта алуыннан эчке бер канәгатьлек хисе алды бугай.

Кыскасы, Тинчурин театры сезонын яңача япты – башта опера эскизлары, аннары импровизацион спектакль. Ә спектакльнең йолдызы Миләүшә ханым Хәбетдинова иде. Әлеге импровизацион тамашаны күзаллау өчен мин аның бераз кыскартылган версиясен редакцияләнгән һәм русча әйтелгәннәрен татарчалаштырылган стенограмма рәвешендә бирәм.

Хореограф, «Алтын битлек» лауреаты Нурбәк Батулла: – Безнең республикада Опера һәм балет театры бар. Ул үзен какшамас бер сарай кебек тәкъдим итәргә тырыша. Аларга күп кенә акчалар бирелә. Алар эшләгәнне бер театр да эшли алмый дигәнрәк фикер хөкем сөрә. Бүген сез алай түгел икәнен күрсәттегез. Сез аны бик йомшак һәм уңай юл белән күрсәтә алдыгыз. Җимерү юлы белән түгел, үз мисалыгызда төзү, тудыру юлы белән күрсәттегез. Афәрин!

Опера жанры, минемчә, безнең милләткә бик туры киләдер кебек, миңа ят бер организм кебек тоелмады. Сез шушы саф жанр аша, акционизмга, эпатажга мөрәҗәгать итмичә, саф формада актуаль теманы күтәрдегез. Бу бик кыйммәт. Акционизм һәм эпатаж аша актуаль темаларны күтәрү, бәлки, җиңелрәктер дә.

Татарстанның халык артисты, педагог Миңгол Галиев: – Актуаль тема дигәнне ачыклап бир әле халыкка. Нәрсә турында ул? Эчтәлеге ничек аның?

Нурбәк Батулла: – Нәрсә күрсәтергә теләгәннәрен – аларның күңелендәгесен әйтә алмыйм. Актуаль тема – хатын-кыз темасы.

Миңгол Галиев: Юк монда хатын-кыз темасы. Бернинди тема юк монда. Милләтнең йөзе дә юк монда.

Миләүшә Хәбетдинова: – «Ал яулык, зәңгәр шәл» дигән исем куелган бер әсәр булырга тиеш. Әйдәгез, беренче өлештән башлыйк әле. Сезне растерзаниегә калдырасыбыз килми. Автор чыксын безгә! Беренче әсәрнең исеме ничек? Кайда беренче әсәрнең режиссеры?

Миләүшә Гафурова: Хәерле кич! Минем исемем – Миләүшә Гафурова. Беренче өлешен мин яздым. Ул «Тәнем» дип атала.

Миләүшә Хәбетдинова: Максатыгыз нинди иде?

Миләүшә Гафурова: Беренче өлешне язганда алга куелган максат – хатын-кызның тәненә куелган табулар һәм таләпләр. Ул тугач ук, әле малайдан берничек тә аерылмаганда, аңа ниндидер таләпләр куела, җәмгыять аңа нәрсәләрдер тага.

Миләүшә Хәбетдинова: Бәлки сезгә башта табу дигән әйберләрне аңларга кирәктер. Сез,

Әллә...

Миләүшә җаным, мондый темага таянып, 30 ел таптанасыз! Безнең мәдәният таптана. Европадан безгә килгән өч тема инде ул. Табыгыз әле залда ире кул күтәргән хатын-кызны. Мин үземне бик бәхетле хатын-кыз дип саныйм. Кул күтәрсә, торып чыгып китәр идем. Мине шулай тәрбияләделәр. Бу тема безнең җирлектә актуаль түгел. Табу дисез, бәлки, бу сезнең комплекслардан килгәндер. Ир кешеләрнең дә үз кагыйдәләре бар...

Миләүшә Хәбетдинова: – Монда сез хатын-кызга нинди киртәләр күрәсез?

Миләүшә Гафурова: Киртәләр булмаганга ул исем булып алынды бит инде. Нигә без исем итеп киртәләрне алырга тиеш?!

Миләүшә Хәбетдинова: Сез киртәләрне үзегез сайладыгыз һәм шул читлектә бәргәләнәсез. Безнең киртәләр юк, ә сез читлектә утырасыз! Хәзер аңлатып бирәм мин сезгә: Умай бик матур зат ул. Әби-бабайлар аны безгә бүләк иткән. Ак Умай һәм кара Умай булган. «Снежная королева»ны күз алдына китерегез! Аның коронасы - ул безнең Умай хатынның коронасы. Аның өч лентасы булган, сез аны кечкенә генә кызыл кендеккә әйләндергәнсез. Ак Умай җан бүләк иткән. Төркиягә баргач таш бабалар күргән булсагыз, аның тәлинкәсе бар һәм анда ана сөтендә - җаннар. Бала булгач, Ак Умай өйгә килә дә, балага җан бүләк итә. Баланың кендеге киселгән, әбиләр аны матча астына кыстырып куйганнар һәм Умай ул баланы кырык көн саклаган. Кара Умай җанны тартып алган. Татар хатын-кызының концепциясендә бернинди чикләр юк. Сез Европа әдәбиятына таянып бөтен татар әдәбиятын челпәрәмә китермәгез! Мәкальләрне ачыгыз да безнең читлек булмаганны аңлагыз! Кем безнең баш? Ир заты! Муен кем? Хатын-кыз! Әле татар дөньясы татар хатыны белән исән. Улицкая бригадасы безгә «Зөләйха күзләрен ача» романын язып бирде. Аларның бик тә татар хатынының күзен йомдырасы килә. Тән турында әйтсәк, татар хатыны образында сафлык. Өченче операгызны карасак, бүген сезгә белем алырга кем комачаулый?

Режиссер һәм актер Илнур Гарифуллин: Гафу итегез, миңа да китәргә кирәк. Мәскәүгә очам. Сорау булса... Сез мине «ашарсыз» инде, ләкин мин русча әйтермен. Чөнки минем татар театрына килүемә бер ел да юк. Татар телен өйрәнәм.

Миңгол Галиев: Татарча өйрәнерсең анысы... Энем, татарча белмәгәч, син ничек куйдың һәм безгә нәрсә күрсәтергә теләдең?

Илнур Гарифуллин: Мин һәр сүзне аңлап җитү өчен 33 тапкыр тәрҗемә иттердем. Өченче операда күргәнегез – мин аңлаганнардан. Мин бүгенге мәгариф һәм аның кая алып баруын күрсәттем. Мин – татар малае. Балалар бакчасында мин бары тик татарча гына сөйләшкәнмен. Аннары мине рус классына ыргытканнар һәм мин менә сезнең белән русча сөйләшәм. Хәзер барысын да кире кайтарырга азапланам. Өйрәнәм. Сез миңа татарча әйтсәгез, мин аңлыйм, әмма русча җавап бирәчәкмен.

Миләүшә Хәбетдинова: Сез бу бик катлаулы милли мәгариф темасына ничек алындыгыз? Сезнең алда рус бистәсендә үскән, белеме буенча рус теле укытучысы булган кеше басып тора. Әмма IV курста борылып татар мәдәнияте белән шөгыльләнә башладым. Сез татар мәдәниятенә акча эшләү өчен әйләнеп кайттыгызмы? Өйрәнү өченме? Мәгариф темасына алынгансыз инде, сезнең өчен татар мәгариф системасында нәрсә эталон булып тора?

Илнур Гарифуллин: Мин бирегә килгәнче акчаны ике тапкыр күбрәк эшли идем - монысы беренче сорауга җавап. Мәгарифтә балага уйлау мөмкинлеге бирелми. ЕГЭ, тестлар... Әйе яки юк – уйларга кирәкми, тәгәл җаваплардан дөресен генә сайлап алырга кирәк. Татарча белем бирү дә кешеләрне татарча өйрәнергә мәҗбүр итәргә тырышудан тора иде. Шуннан курку туа...

Ләйсән Мәхмүтова: Мин микрофонсыз гына әйтим әле. Артистларга зур рәхмәт! Зур хезмәт кылынган. Музыка да өйрәнгәннәр. Ваннага да сыйганнар. Артистның сайлану хокукы юк: режиссёр кушканны эшли. Нишләп режиссёрлар фантазияне эшләтмиләр? Шушы декорация 20 минут торды һәм бернәрсә дә үзгәрмәде. Декорацияне 20 минут бертөрле торганда әзрәк халык турында уйларга кирәк. Икенчедән, динамика дигән әйбер булырга тиештер бит?! Чит илдә, карагыз, опералар ничек ясыйлар! Анда йөгерәләр дә, очалар да! Өченче өлештә генә нинди динамика булды.

Туфан Имаметдинов: Рәссамның образына килгәндә, перфорация дигән төшенчә бар. Сез сәхнәдә перфорация күрдегез. Хатын-кыз тормышы перфорация кебек: бер үк әйбернең кабатлануы – иртән тору, балаларны торгызу, юындыру... Моннан беркая да китә алмыйсың. Син бала табарга әзер икәнсең, бер үк гамәлләрне кабатлап торырга тиеш буласың. Рәссамның образы: шул ук әйбернең кабатлануы. Икенчедән, операны мюзикл белән бутамагыз – анда люстралар да оча. Опера – статик жанр. Анда солист чыга да җырлый, тирәлегендә хәрәкәт бар, ләкин ул җырдан игътибарны читкә юнәлтмәслек кенә дәрәҗәдә. Аңлагыз: бу мюзикл түгел. Опера - ул статик декорацияләр. Опера тарихында бернәрсә дә үзгәрмәде. Пәрдә ябыла да декорацияләр алышына, без дә шул тәртиптә эшләдек. Классик структурасы шундый.

Миләүшә Хәбетдинова: – Менә без фикер алышуга калдык. Сораулар бирәбез. Миңа бик кызык. Тән темасы булды, ваннагыз очып китте. Сезнең максатыгыз – татар операсын тудыру. Утызынчы копияне түгел! Үзебезнең татар нигезендә башка мәдәниятләрдән аерылган яңа сүз әйткән иҗат! Монда бер опера лабораториясе булды. (2019 елда Данияр Соколов инициативасы белән оештырылган KazanOperaLab лабораториясе турында сүз бара. Хәзер Данияр Камал театры оркестрының баш дирижеры. – **Авт.**). Без өч көн спектакль карарга килдек. Такташка багышлап чыгардылар, Свияжскиныкы шәп булды – туристларга күрсәтеп була иде. Без монда татар операсы тудырабыз дип акча алабыз. Ә рәссам татар образлары эзләми, режиссерлар Европа үрнәгендә сепарат сөте ясап бирәләр дә, аңламагач безне надан, диләр. Без моны беләбез, «железный занавес» юк. Минем сорау: ни өчен сез Умай образын алдыгыз... Ал яулык дип әйтеп безне алдыйсыз. Умай – ул хан кызы. Кояш образы ул, җәмәгать! Без монда ал яулык түгел, матрешка күрдек. Сез төрки хронотопны өйрәнмәгәнсез. Сезгә кем комачаулый? Цензура дисезме? Мин ирекле яшим, сүземне әйтәм. Беркем миңа комачауламый. Мин – татар хатын-кызы. Ирем миңа «Богиня» дип эндәшә. Сез хатын-кызны кыйныйлар дисез. Хатын-кыз үзен-үзе шәхес итеп тәрбияләргә тиеш. Түзә икән, бу аның үз проблемасы. Сез татар хатын-кызына тап төшерәсез! Без моны үттек инде. Галимҗан Ибраһимов ХХ гасыр башына керде дә, Островскийдан «Гроза»ны алды да, «Татар хатыны ниләр күрми?» дип әсәр язды да, 70 ел инде татар хатынын чукып, «Сез шундый», дип безне өйрәттеләр. «Умай» дип язылган бит исеме...

Миңгол Галиев: Киләчәк турында уйлаганда, безгә Европага, Америкага охшарга тырышырга кирәкми, «Үзгәреш җиле» моның нәрсә икәнен күрсәтте инде. Аның милли йөзе юк.

Алсу Сөнгатуллина: Мин композитор. Ачуланмагыз инде. Минемчә, бу бик эксперименталь проект. Дөресен әйткәндә, бу бик опера да түгел, синтетик жанр. Театрда вокалистлар юк. Алар драма артистлары. Шуңа без аларга икенче төрлерәк язарга булдык. Башта сүзләрен дә аңлап бетерә алмадым. Мин хатын-кызның тууы турында яздым. Музыканы милли дә, заманча да булсын дип язарга тырыштым. Актерлар шундый тырышып өйрәнгәннәр. Ачуланмагыз, без чыннан да бик тырыштык.

Миләүшә Хәбетдинова: Барысы да аһәңнән башлана. Мин беренче лаборатория вакытында да бу сорауны биргән идем. Хәзер дә бирәм. Татар музыкасы рус музыкасыннан нәрсә белән аерылуын аңларга кирәк. Татар этәче ничек кычкыра? Нәрсәгә көләсез? «Кикрикүк», дип кычкыра. Рус этәче ничек кычкыра? «Кукареку», ди. Авазларны аерасызмы? Һәр халыкның үз аһәңе бар. Шуны аермасаң, милли әсәр яза алмыйсың. Кабатлап әйтәм: мин монда чиркәү хоры тойдым. Сез шул форматка утыргансыз, католик хорына борылып төшәсез. Бу – Эльмир Низамов модасы. Ул Софья Гобәйдуллина артыннан бара. Ләкин бу – минем дәүләтем һәм мин аңа салым түлим. Сезгә акча бүлеп биргәндә, татар музыкасына таянып, татар операсы тудыру турында сүз бара. Әйдәгез, борылып үз нигезебезне өйрәник әле!

Миләүшә Хәбетдинова: Тинчурин театры артистларына рәхмәт! Сез үз театрыгызны саклап каласыз! Бүген минем бәхетле көнем – Миңнеханов Якутиягә барып милли мәдәният төзелгәнне күргән һәм безгә диагноз чыгарган: Сабан туебызны бетергәнсез икән, дигән. Якутларга барып театр төзергә өйрәник. Аларның саха театры борынгы төрки театр формаларын күтәрә. Нинди көчле театр төзеделәр! Аларның милли бәйрәмнәрен өйрәнеп, безгә мастер-класслар үткәрергә кирәк. Питердан бригадалар, чит илдән белгечләр чакырып мәдәниятебезне төпкә утырттык инде!

Әлфия Хәсәнова: Җәмәгать, безне башка көннәрдә гади тамашачы килеп караячак. Ул шушы спектакльне аңлый алырмы икән соң? Монда нинди бәхәс купты! Монда гади халык бәхәсләшми. Шушыны күреп күпмедер аңы булган осталар бәхәсләшә. Гади халык бу спектакль турында нәрсә әйтергә мөмкин?! Көзгә Тинчуринның тууына 135 еллыгы. 135 еллыкка кирәкме бу спектакль? Ел ярымнан театрның 90 еллыгы. Без аны шушы «Умай» белән каршыларбызмы? Сезонны Камал театры «Зәңгәр шәл» белән яба. Без «Умай»ны күрсәтеп, сезон белән саубуллашабыз. Нигә без сезонны Тинчурин белән ачмыйбыз һәм япмыйбыз? Бүгенге тамашачы мактады – әйе, ләкин болар чакырылган кешеләр. Ә сез килеп гади тамашачыны карагыз! Сез моның унынчы, унбишенче тапкыр куелганда ярты залның чыгып киткәнен күрерсез.

Миләүшә Хәбетдинова: Тинчурин театрын колхоз театры дип әйттеләр, ләкин колхоз спектакле аны ашатты, халык залны тутырып йөрде. Сез хәзер тамашачыны югалтасыз. Шабашник режиссерлар килә дә куеп китә... Спектакль театрны ашатырга тиеш. Реформа ясалган өч ел эчендә мин Тинчурин театрында бер спектакль күрдем – «Карурман» булды ул. Мин анда театр труппасының йөзен, артистларның бәхетен күрдем. Бүген сезне шаккатып тыңлыйм. Тинчурин театры сезонын япмаган идемени? Бу лабораториянең сезгә нинди катнашы бар? Бу – грант. Бу – эксперимент. Режиссер бер ел эшләгән икән, үзе куйган әсәр белән ябарга тиеш. Ильяс (Камал – театр оркестрының сәнгать җитәкчесе. - **Авт.**), мин сине бик хөрмәт итәм. Без татар операсы төзибез дип сәхнәдә чиркәү хоры җырлатасыз. Сезгә кем комачаулый татар операсы төзергә? Министр сезгә акча бирә...

Ильяс Камал: Бик зур рәхмәт артистларга! Алар таныш булмаган рамкаларда бик тырышып эшләделәр һәм булдырып чыктылар. Бу лаборатория иде. Безнең композиторлар тартыла башлады. Алсу 100 процент татар моңы белән иҗат иткән – анда, ишеткән булсагыз, мөнәҗәт авазлары да бар. Азагында бераз клуб музыкасы булды, диско стиле... Анда эзләнүләр сизелә. Ә татар моңы канында булмаган кешенең кызыксына башлавы начармыни? Бу бит татарга хөрмәт...

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Атнаның сәяси мизгелләре

Чираттан тыш серле утырыш

Узган атнада Дәүләт Думасының чираттан тыш пленар утырышы үтте. Анда Россия икътисадын (авиация, суднолар төзү һ.б. төп тармакларны) яклауга, социаль өлкәгә кагылышлы мәсьәләләр каралган. Депутатлар шулай ук РФ хөкүмәте рәисе урынбасары вазифасына Денис Мантуров кандидатурасын хуплаган, кадрлар буенча башка үзгәрешләр дә булган (Д.Рогозин «Роскосмос» башлыгы вазифасыннан алынган, аның урынына моңа кадәр вице-премьер булып торган Ю.Борисов билгеләнгән). Әмма депутатларны моның өчен генә җәйге каникулдан ашыгыч төстә чакыртып алу һәм утырыш үткәрү бик сәер булыр иде. Аның алдыннан атна дәвамында оештырылган ажиотаж да бик үк аңлашылып бетми. Ә анда чираттан тыш утырышның максаты турында нинди генә версияләр фараз кылынмады. Әмма болар һәммәсе дә буш сүз генә булып чыкты. Әйтүләренә караганда, утырыш гадәти мәшәкатьләр белән үткән.

Кайбер экспертлар әлеге хәлне Россиягә каршы кертелгән санкцияләрнең икътисад өчен ни дәрәҗәдә куркыныч тудыруын, ниһаять, Кремльдә дә аңлый башлаулары белән дә аңлата. Алар әйтүенчә, икътисадның басылуы, сәнәгатьтәге деструктив күренешләр һәм тормышта да деградация башлануы бер мизгелдә генә килеп чыкмый. Шуңа күрә мондый хәл ашыгыч чаралар күрелүен таләп итә. Чираттан тыш утырыш тирәсендәге ажиотаж чынбарлыктагы хәлләргә халыкның күзен ачуны максат иткән, дигән фикер дә алга сөрелә. Мондый караш бу атнада президент В.Путин әйткәннәр белән дә аваздаш. Стратегик үсеш вә дәүләт проектлары буенча шура утырышында ул санкцияләр турында: «Понятно, что это огромный вызов для нашей страны, но мы не только не собираемся опускать руки, пребывать в какой-то растерянности или, как некоторые наши «доброжелатели» предрекают, отступать на десятилетия назад», - дип белдерде. Ул аларны колачлы кыенлыклар дип бәяләде һәм нәтиҗәле яңа карарлар, ысул-чаралар эзләргә вәгъдә итте.

Атнаның башка вакыйгаларына килгәндә, кадрлар алышынуы Украинада да булды. Анда президент В.Зеленский үз указы белән илнең генераль прокуроры И.Венедиктованы һәм Иминлек шурасы башлыгы И.Бакановны вазифаларыннан читләштергән. Моны ул алар җитәкләгән органнарда хыянәтчелеккә ишарә белән аңлаткан. Игътибарны АКШ президенты Джо Байденның Согыд Гарәбстанына сәфәре дә җәлеп итә. Ул анда варислы принц Мөхәммәд бин Сәлмән белән очрашкан, Фарсы култыгы илләре-АКШ саммитында катнашкан. Әр-Рияд исә, дөньяда Россия нефтен куллануны киметү өчен, нефть чыгаруны тәүлегенә 3 миллион баррельгә арттырып, 13 миллион баррельгә җиткезергә вәгъдә иткән.

Фоат УРАЗАЙ.

КАЙТЫР ЮЛЛАР

(Ахыры. Башы 26, 27 нче саннарда).

Бәхәс кузгатуның мәгънәсе юк иде. Шулай да кайбер шик-шөбһәләрне ачыкларга кирәк иде әле. Капитан «сорау алуын» дәвам иттерде, ә сәер планетаның вәкиле аңа тоткарлыксыз җавап биреп торды.

– Үзегезнең бу тормыш системасын сез ничек саклыйсыз?

– Әлеге дә баягы автоматика. Автоматлар безнең нормаль тереклек эшчәнлеген күзәтеп торалар: канга азык кертәләр, йөрәк тибешен, кан басымын, температураны, һаваның дымлылыгын, чисталыгын һәм башка шартларны даими бер дәрәҗәдә саклыйлар. Галәм киңлегеннән, ягъни читтән һөҗүм яки чит цивилизация үтеп керү куркынычы туганда, шул ук автоматлар планета тирәсендә киртәләүче калкан коралар, ят җисемнәрне – метеорларны һәм космик

корабльләрне үткәрмиләр. Дөрес, кайчагында куәтле техник чаралары булган үзсүзле кунаклар да килеп чыккалый. Менә сезнең кебекләр... Андыйларны автомат үткәрә, ләкин буш җирләргә генә төшәргә юл ача...

– Аннары?

– Аннары Үзәк автоматика йөз миллиард кеше арасыннан бер вәкил сайлап ала, аны сезненчә әйтсәк, уята, бөтен кирәкле мәгълүматлар белән коралландыра һәм илче итеп җибәрә.

– Йөз миллиард мәет! Автоматлаштырылган зират бу! – дип кычкырды пилот. – Каберстан!

– Бичаралар... – дип өстәде Алиса.

Илче күзләрен кыса төшеп, пилотка тагы сөзеп кенә карап алды. Аның күзләрендә ут шәүләсе чагыла иде. Хәер, бу кискен елтырау шул мизгелдә үк сүнеп карт акылның сабыйларча кызганып караве белән алмашынды.

– Ягулык һәм ризык алыгыз да – хушлашыйк, – диде илче саңгырау бер тавыш белән. – Кайтыр юлыгызны күрсәтермен.

– Тагын бер сорау бар.

– Тыңлыйм, капитан.

– Хәзер сез нишлисез инде? Без киткәч?

– Урынлы сорау. Мин, әлбәттә, яңадан элекке тормышка кайта алмыйм. Чөнки минем бөтен барлыгым – психогенотип системам үзгәрде. Мин үземне атомнарга таркатачакмын.

– Ә без буйсынмасак?

– Ул чагында мин көч кулланырга мәҗбүр булыр идем.

– Безне дә йоклатырсызмы?

– Юк, мин сезнең хәтердән монда булган хәлләрне психогенератор ярдәмендә юдырам да ракетагызны Галәмгә озатам. Сез, әйтик, моннан ун көн элекке хәлегезгә кайтырсыз. Калганы безне кызыксындырмый. Һәр җан иясен саклау мөмкин түгел.

* * *

Экранда күксел планетаның түгәрәк йөзе кечерәйгәннән-кечерәйде.

– Аллага шөкер, – диде пилот һәм арткы экранны сүндерде.

– Син нишләптер борынгы потлар исемен бик еш телгә аласың әле, – дип, авыр гына елмайды капитан.

– Алырсың да! – диде Грин теш аралаш. – Гравитация кадәр гравитация көчен йөгәнләгән җәмгыять дәвасыз бер чиргә сабышсын әле!

Капитан аның колагынарак иелде:

– Грин, Алиса кая?

– Аш кабинасында утыра. Елый, капитан. Мондагы бәхетсез затларны кызганып елый...

Капитанның текә маңгаена тирән җыерчыклар төште. Яңаклары салынып торгангамы, аның йөзе картаеп киткән кебек иде. Ул ниндидер каты төерне йотып җибәргәндәй итте дә тирән сулыш алды.

– Дустым... – дип пышылдады ул. – Алисага әйтмичә тор... Сез икәү генә калырсыз, ахры...

– Капитан! Ни сөйлисез?!

– Мин беләм, сизәм, Грин. Үлем ишек какканын һәр җан иясе сизәдер, күрәмсең...

Пилот куллары белән битен каплады.

– Ир бул, Грин. Хәл тагы да житдирәк...

Овал ишектән Алиса килеп чыкты. Шешенгән күз кабакларына ул пудра яккан һәм нигәдер, космик комбинезонын салып, җәйге күлмәк кигән иде. Үлемгә хөкем ителгән тоткыннар камерасына хыялый күк күбәләк очып кергәндәй булды. Астронавтлар кызның нәфис гәүдәсенә, зәңгәр муенсасына карап тордылар. Пилот (ул мескен, күптән гашыйк иде) башын иеп күзләрен яшерде.

– Эчке телефоннарны аерырга оныткансыз, – диде кыз, – Мин бөтенесен ишетеп тордым.

Капитан, маңгаен учлап тоткан килеш, ияген какты.

– Кире кайтыйк та, бу дөньяны дер селкетик, капитан! Уятыйк аларны!

– Алиса.. – Минемчә, алар мондый ихтималны алдан күргәннәрдер.

Алиса куркынып китте.

– Андый-мондый хәлне кисәтү өчен алар безгә гипнограмма биргән булырга тиеш.

– Гипнограмма? Ничек? Без дә йоклыйбыз димәкче буласызмы әллә?

– Әлегә юк. Хәзергә без реаль тормышта, Алиса. Ләкин күпмедер вакыттан...

– Димәк, дошман безнең үзебездә?

– Үз эчебездә дию дөресрәк булыр. Безнең баш мие күзәнәкләренә хәтәр программа язганнар дип шикләнәм мин. Күпмедер вакыттан соң без шул ят программа буенча яши башларбыздыр...

– Без шулкадәр көчсезмени? Берәр чара табарга кирәк, капитан!

Пилот Грин белән борт-радист Алиса, күзләрен мөлдерәтеп, капитанга текәлделәр. Яшьлек тагы өлкәннәрдән киңәш көтә иде.

Ләкин акылга җиңеләйгән бөтен бер җәмгыятькә каршы өч бөртек кеше ни эшли ала? Аны бер сугуда җиңә торган корал бармы соң? Әйе, бу якта кайнар йөрәкләр, теге якта – Бөек Божрадан качып яткан боз тавы. Туры караган бер кояш нуры да айсбергларны йөзтүбән капландыра бит!

– Чара күрергә кирәк, – диде капитан һәм көмештәй чәчләрен артка сыпырып җибәрде.

– Капитан! Без, йоклап киткәнче, баштан кичергән хәлләрне магнитофон тасмасына язып калдырыйк. Айныгач, искә төшерә алырбыз, – дип тәкъдим итте Алиса.

– Кәгазьгә дә языйк, – дип өстәде пилот. – Ышанычлырак булыр.

– Болар файдасыз. Гипнограммада безнең мондый адымыбыз да алдан күрелгәндер. Ягъни без үзебезнең язмаларыбызны белешмәстән юк итәрбез.

– Нишләргә соң?

– Хәзер үк анабиоз халәтенә күчәргә! Шулай итсәк, без гипнопрограмманы кичектереп торабыз. Ә автоматлар, Җиргә якынайгач, бөтенесен аңлатып космограмма сугарлар. Җир безне каршылар һәм гипнопрограмманы нейтральләштерү юлын табар.

– Без бу йокы патшалыгын аякка бастырырга дип әйләнеп кайтырбыз, Грин. Аны якасыннан тотып җилтерәтергә кирәк.

– Үсеш-тәрәккыятнең болай үле ноктада туктап калуына мин ышанмыйм. Цивилизация үз-үзен чагып үтерә торган елан түгел...

...Капитан пилот белән борт-радистны анабиоз ванналарына урнаштырды, тереклекне тәэмин итү системаларын, суыткычларны, вакыт релесен һәм уяткыч җайланманы көйләп куйды, пыяла капкачларны япты.

Йоклап киткәндә Алисаның керфек очларында ләйсәндәй күз яше ялтырый иде. Суыткыч эшли башлагач, ул тамчы сафтан-саф энҗе бөртегенә әйләнде.

Анабиоз: биомолекуляр хәрәкәт һәм тереклек процесслары тукталды, баш мие гомерлек тәҗрибә һәм хатирәләр язылган граммофон тәлинкәсе белән бер хәзер. Вакыты килер һәм ул әзелеп калган нотадан башлап тагы тормыш симфониясен уйнар...

Капитан кинәт тез буыннарында эшәке бер хәлсезлек тойды, аның чигәләре сызлап, фикере чуала башлады. Бу нәрсә картлык галәмәтеме, әллә инде дошман программаның эшкә керешүе идеме – анысын ул аңлап өлгермәде.

Галәм бушлыгында ялгыз ракетоплан оча иде.

Адлер ТИМЕРГАЛИН

Сталин ярany

«Казанда иң югары партия постларын биләгән өч дистәгә якын шәхес арасында Семен Игнатьев аерым бер урын тота. Аңа кадәр дә, аннан соң да 90 нчы елларга кадәр дәүләттә шулкадәр атаклы һәм йогынтылы пост биләгән кешенең республикабыз башында торганы булмады», – дип язды профессор Булат Солтанбәков бер мәкаләсендә.

Казанда өч кенә ел эшләсә дә С.Игнатьев җәмәгатьчелек хәтерендә сизелерлек эз калдыра. Күренекле татар әдибе Гомәр Бәширов Игнатьевның искиткеч гадел кеше булуы, безнең мәдәниятнең, бигрәк тә әдәбиятның мактаулы шәхесләрен чынбарлыктагыча күз алдына китерүен сөйләгән. Игнатьев татар әдәбияты өчен партиянең теләсә кайсы эшлеклеләренә караганда да күбрәк файда китерде дип саный ул. Нәҗип Җиһанов та шундый фикердә була.

С.Д.Игнатьевның тәрҗемәи хәле бик гыйбрәтле. Туган урыны Украинаның Карловка авылы саналса да, аның шәхесе Урта Азиядә калыпланган. Ул ун яшьлек малай чагында Термез шәһәрендә мамык чистарту заводында нефть ташучы булып эшли. Аның үзбәк телен белүе дә, көнчыгышның үзенчәлекле төбәк икәнен аңлавы да шуннан килә. Бу исә аның карьерасын билгеләүдә шактый зур урын тоткан.

Уналты яшендә Семен – Бохара гаскәрләре төркемендә сәяси бүлекнең мәгариф секторы башлыгы урынбасары, ә бераздан Казан шәһәре милициясе башлыгы ярдәмчесе. Аннары Бохараның гадәттән тыш комиссиясендә эшли. Кыскасы, чекист хезмәте серләрен унҗиде яшендә үзләштерә. Аннан соңгы ун ел дәвамында Игнатьевны комсомол һәм профсоюз линиясе буенча күтәрәләр, республика күләмендәге хезмәткәргә кадәр үстерәләр. 1926 елны аны партиягә алалар. 1931 елда Үзбәкстан Компартиясе үзәк комитеты юлламасы белән С.Игнатьев яңа тип инженер һәм партия – совет кадрлары учагы булган Бөтенсоюз сәнәгать академиясенә алына. Аның белән бер үк вакытта тиздән предприятиеләрне, җитештерү тармакларын, партия һәм дәүләт учреждениеләрен житәкләячәк бик күп кадрлар укый. Соңрак аларның байтагы репрессияләр корбаны була. 1935 елда Игнатьев академиядә тулы курсны тәмамлый һәм ул чагында шактый сирәк очрый торган белгечлек – самолет төзү инженер-технологы дипломын ала. Практиканы Туполев заводында, игъни киләчәктә Горбунов исемен йөртәчәк 22 нче заводта уза.

1937 елның җәендә репрессияләр дулкыны җирле партия оешмаларын каплап ала. Бик күпләр кулга алына. Маленков тәкъдиме белән Улан-Удэда партиянең Бурят – Монголия өлкә комитетының беренче секретаре итеп билгеләнгәндә, Игнатьевка да шундый куркыныч яный. 1951 елга кадәр аның язмышы милли республикаларда партия комитетларына һәм башка югары хакимият структураларына җитәкчелек белән бәйле була.

1951 елның башында ВКП(б) Үзәк комитетының союздаш республикадагы бик азларга гына таныш булган вәкиле Игнатьев Үзәк комитетның партия, комсомол һәм профсоюз оешмалары бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Бу – дәүләтнең бөтен сәяси элитасын билгеләү эшенә идарә итүче бүлек, ә аның мөдире барлык партия комитетларында беренче затка гына буйсына.

11 июльдә Сталин белән очрашу вакытында Семен Игнатьевка четерекле Иминлек министрлыгын җитәкләргә һәм бер үк вакытта Үзәк комитетның бүлек мөдире вазифаларын үтәүне дәвам иттерергә тиешлеге әйтелә. Шулай итеп, Игнатьев һәм курку, һәм соклану тудыра торган министрлыкта эшли башлый.

«Табибләр эше», Иминлек министрлыгында абакумовчыларны тар-мар итү һәм кулга алу, Политбюро әгъзасының секретариатта чит илгә информация бирә торган каналын ачу Игнатьевны Сталинның сөяр сөягенә әйләндергән. Партиянең XIX съездында Семен Игнатьев Үзәк комитет әгъзасы итеп сайланган һәм киңәйтелгән Президиумга кертелгән. Аның абруе шулкадәр үскән ки, юлбашчы даирәсенең иң якын кешеләрен – 30 нчы еллардан бирле даими ярдәмчесе һәм шәхси секретаре А.Поскребышевны, шәхси сак башлыгы генерал Власикны, генерал С.Кузьмичевны кулга алу нәкъ менә аңа тапшырылган. С.Игнатьевка шәхси сак башлыгы вазифалары да йөкләнгән. Аңа кадәр махсус хезмәтләр җитәкчеләреннән берәү дә андый дәрәҗәгә ия булмаган.

Сталин үлгәннән соң, 1953 елның декабрендә С.Д.Игнатьевның Мәскәү дәвере тәгәлләнә. Хрущев һәм Аристов тәкъдиме белән аны Башкортстанга җибәрәләр. 1946 елда Мәскәүгә китерелгән вакыттагы постына – партия өлкә комитетының беренче секретаре итеп. Әмма аның язмышында янә яңа борылыш була. Аны Казан көтә.

КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре постында Муратовны алыштыру сәбәпләре турындагы мәгълүматлар архивларда сакланмаган. Күрәсең, Мәскәүдә аның белән ризасызлык акрынлап җыела баргандыр. Бер фараз шундый: ул кукуруз кампаниясенең роленә бәя биреп җиткермәгән, хәтта шуның өчен кисәтү дә алган.

1957 елның июнендә Казанда өлкә комитеты Пленумында яңа беренче секретарь постына Үзәк комитет вәкиле С.Д.Игнатьевны тәкъдим итә. Ул гадәт буенча бертавыштан раслана.

Тәҗрибәле инженер-оештыручы буларак Игнатьев республика икътисадында бик мөһим ике тармакны – нефть һәм химия тармакларын үстерүгә зур игътибар бирә. 1959 елда илдә беренче буларак тәүлеклек нефть чыгару 100 мең тоннага җиткерелә. Казан органик синтез заводын төзү инициативасын да нәкъ менә Игнатьев күтәреп чыга. Бу завод хәзер дә республика бюджеты өчен таяныч булып тора. Беренче секретарь, беренче чиратта авиацияне үстерүне дә игътибар үзәгендә тота. Ул чорда Казан Ту-22 бомбардировщигын күпләп житештерә башлауга ирешә.

Дөрес, Игнатьев бик сак кеше була. Ит һәм сөт тапшыру буенча ике-өч план үтәү кебек, Рязань секретаре Ларионовның гомеренә торган авантюраларга бирелми. Моның өчен РСФСР буенча үзәк комитет секретаре Аверкий Аристовтан кисәтү дә ала. Шулай да Игнатьевның Үзәк комитет белән мөнәсәбәтләре яхшы була. Шуңа күрә Татарстанга сәнәгатьне һәм халык кулланы тармагын финанслау, фондлар алу шактый ук җиңел гамәлгә ашырыла.

Игнатьев килгәч, кадрлар белән эшләүдә яңа, таләпчән стиль урнаша. Министрлар Советы рәисе постына Сәет Шәрәфиев кире кайтарыла. Ул легендар шәхес булып, республика тарихында беренче буларак әлеге постны ике тапкыр били. Ходай бирмеш финансист була, авыл хуҗалыгын да шәп белә.

Игнатьев башка кадрларны да алыштыра. Ул өлкә комитетына һәм башка хакимият структураларына яшьләрне җәлеп итә. Игнатьевның интеллигенциягә һәм гомумән мәдәнияткә мөнәсәбәте – үзенә бер аерым тема. Ул язучыларны, галимнәрне теләп кабул итә. Күпләргә торак проблемасын хәл итәргә булыша. Ә ул вакытларда әле бу мәсьәлә бик кискен тора.

1958 елның 21 май пленумында «Татарстан белем мәктәпләре эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары» мәсьәләсе каралды. Бу мөһим мәсьәлә буенча Г.Бәширов, Й.Туишев, Н.Җиһанов, Г.Рябков, Ә.Вәлиуллина, В.Дербинов, С.Игнатьев һәм башкалар чыгыш ясый. Аның карарында әйтелгәнчә, соңгы елларда туган телдә укучы татар балаларының саны 95 проценттан 70 процентка, ә Казанда 16 процентка калган. Татар мәктәпләренең матди хәле начарлануны, аларның саны кимүне һәм кадрлар сыйфаты түбәнәюне раслаучы күпсанлы фактлар китерелә. Татар балаларының күбесе рус мәктәпләрендә укый, татар телен һәм әдәбиятын өйрәнми. Карарда кимчелекләрне бетерү буенча киң колачлы программа бирелә. Анда махсус уку йортларында татар төркемнәре оештыру, өлгергәнлек аттестатында татар әдәбияты буенча билгене торгызу һәм башка бик күп чаралар каралган.

Өлкә комитетының үз җитәкчелегендә дә кискен каршылыклар бәреп чыга. Камил Фәсиев, мәсәлән, милли мәсьәләләрне үстерү өчен тырышып йөри. Ә менә идеологик карьераның барлык баскычларын үткән Салих Батыев Игнатьев тырышлыгын хупламый.

Ризасыз татарлардан Игнатьевны милләтчелеккә юл куюда гаепләп Мәскәүгә хатлар ява. Үзәк комитет белән мөнәсәбәтләр нык катлаулана. Күп тә үтми республика җитәкчесенә Монголиядә илче булырга тәкъдим итәлә, әмма ул тәкъдимнән баш тарта. Сәламәтлеге какшауны сәбәп итеп китерә. Шул рәвешле эштән туктап пенсиягә китеп бара. Бу вакытта әле аңа 56 гына яшь була.

Кешеләр күңеленә Семен Денисович күбрәк яхшы яклары белән кереп калгандыр. Бер үрнәк. Казанга килгәннең беренче көннәрендә, әле аны бирердә йөзгә танып белмәгән вакытта, Игнатьев кичен кибеткә керә һәм бер кило токмач үлчәп бирүләрен үтенә. Сатучы пакет өчен кәгазь юклыгын әйтә. «Продуктны кая салыйм соң?» – дигән сорауга: «Әнә, эшләпәгезгә салыгыз», – дип җавап бирә. Сатып алучы сүзсез генә баш киемен куя... Бер сәгатьтән өлкә комитетында сәүдә министры һәм башка түрәләр үрә катып эшләпәне һәм аның эчендәгене тамаша кыла.

Шәхес культы турында күп сөйлиләр. Бу хакта Константин Симонов бик шәп әйткән: «Культ булды, ләкин шәхесләр дә бар иде!» 1957-1960 елларда Казанда эшләгән С.Д.Игнатьев шундыйларның берсе була. Мәскәүгә киткәннән соң ул 23 ел яши. Отставкага чыккан түрәләр еш кына активлык күрсәтә, кешеләр арасында күбрәк булырга тырыша. Семен Денисович салмак кына тормыш иткән, үз бәясен үзе белеп яшәгән. Шуңа күрә бүген дә аны хөрмәт белән искә алалар.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

●Вәлидинең әтисе Әхмәтша, әнисе Өммелхәят һәм энесе Габделрәуф. 1904 ел.

● Көзән авылында Әхмәтша хәзрәтнең йортын кабатлап тергезелгән музей.

ЗӘКИ ВӘЛИДИ

Зыялы катлам арасында Әхмәтзәки Вәлиди исемен ишетмәгән һәм аның гаять каршылыклы тормыш юлы белән өстән-өстән генә булса да танышмаган асыл ирләр аздыр. Аның тәрҗемәи хәлен искә алганчы ук, ул кылган фәкать бер гамәлне мисал рәвешендә китерү дә җитә. 28 яшьлек Зәки Вәлиди элеккеге Россия империясе, булачак Советлар Союзы мәйданында иң беренче булып, 1919 елның февраль аенда ук мөстәкыйль Кече Башкортстан республикасын Ленин-Сталин хөкүмәте тарафыннан танытуга ирешә.

Ә үзләрен аерым республика дип игълан иткән Украина, Кырым, Алаш Урда, Үзәк Каспийдагы Мусаватлар хөкүмәте һәм Идел-Урал штатын – һәммәсен дә большевикларның күн тужуркалы һәм маузер таккан комиссарлары пыран-заран китереп бетерә. Гражданнар сугышы кайнап, миллионлаган кешеләрнең гомере кыелган коточкыч мәхшәр чорында, халкы корыч богауларга утыртылган империя үзәгендә Зәки Вәлидинең мөстәкыйль республика төзеп куюы – үзе үк зур могҗиза! Ә ул моңа нинди юл белән ирешкән, кемнәргә хыянәт иткән дә нинди баш югалтырдай хәйләләр юлына баскан – монысы инде үпкә-рәнҗеш аша якадан алып бәхәсләшә торган, бөтенләй башка тема...

Дөрес, асыл татар ир-егете буларак, мин дә Вәлидинең Идел-Урал штатына хыянәт итеп, зур дәүләт урынына 40 волостьтан гына хасил Кече Башкортстанны төзеп куюын гафу итә алмыйм. Ләкин аның заманында Россиядә хәзерге бүленеш юк, бүген Татарстан атын йөрткән республиканың да Әгерҗедән Әлмәткә һәм Азнакайдан Чаллы каласына кадәр сузылган зур өлеше, Минзәлә өязе булып, Уфа губернасы составында саналган бит. Бәлки, нәкъ шуңадыр бүгенге Актанышның Такталачык авылыннан чыккан Илдархан Мутин, Зәй районының Чыбыклы авылында үскән Фатыйх Төхбәтуллин, Азнакайның Чалпы авылыннан морзалар вәкиле Ногайбәков – барысы да диңгездәй зур Идел-Урал штаты урынына, кечкенәрәк булса да, үз Ватанын төзү идеясен яклап чыккан һәм Уфа-Стәрлетамаклардагы, алар күршесе булган татар авылларындагы йөзәрләгән ирләр Зәки Вәлиди күтәргән Кече Башкортстан әләме астына барып баскан. Бүгенге фән биеклегеннән торып гаеп ташлау җиңел, әмма беребез дә туган-туганын һәм күрше-күршесен суйган куркыныч һәм афәтле чорга әйләнеп кайтырга һич тә теләми бит. Зәки Вәлиди – әнә шул канлы һәм мәкерле чор юлбашчысы. Җәллад комиссарлар белән бәрелешләрдә ул берүзе генә әүлиядәй гөнаһсыз вә мәкерсез булып кала алмый. Олы бер өязне җыештырып чыкканчы, үз урамыңда тәртип салу – ансат һәм отышлырак. Вәлиди дә, әнә, үз теләгенә ирешкән – Кече Башкортстанны булдырган. Җиңүчегә еллар узгач йодрык болгамыйлар. Иң хәерлесе – ул туып-үскән җирләрне урап, ул сулаган һаваны һәм ул эчкән суларны татып кайтыйк әле...

Без менә шушы теләк белән Стәрлетамак каласына кадәр килеп җиттек. Вәлиди туган Көзән авылы Ишембай районында исәпләнсә дә, аңа Стәрлетамак аша бару уңайлырак. Ишәй, Әхмәр, Питрау авыллары яныннан Көзәнгә юл тоттык. Сул тарафта атаклы Йөрәктау (1707 елда аның янында Күчем морза белән Алдар тархан Петр патшаның подполковник Хохлов кул астындагы карательләр корпусын тар-мар иткән) белән әле ике ел элек кенә бөтен Рәсәйне яңгыратып башкорт яшьләре яклап калган Куштау таулары сокландырып утыра. Тимәш авылы янында борылыш ясауга ук, астагы үзәнлектә Көзән панорамасы ачыла. Әллә ничә урам булып тау итәкләре уртасына җәелгән зур авыл. Истәлекләр буенча, аны 1550-1560 елларда ук татар качаклары – типтәрләр килеп нигезләгән, диләр. Юллары асфальт, еракта – мәчет манаралары, урамнарында һәм тирә-юньдәге тау итәкләрендә чыршы, карагай, нарат.

● Хәрби киемдәге Вәлиди. 1919 ел.

●Урта Азиядәге милли азатлык хәрәкәте юлбашчылары Төркиядә. Алда (сулдан беренче) – М.Чокаев, уңда – З.Вәлиди. Истанбул, 1925 ел.

Зәки Вәлиди музеен ул туып-үскән хуҗалык урынында 1993 елда төзеп куйганнар, урамның икенче ягында – мәчет. Бу урындагы 2 нче җәмигъ мәчеттә Зәкинең әтисе Әхмәтша хәзрәт имам булып торган. Аңа ирешкәнче Бохара якларында белем эстәп кайткан, аннары Стәрлетамак мәдрәсәсендә белем алган. Үтәк авылындагы дин һәм мәдрәсә әһеле Мөхәмматкафинең кызы Өммелхәяткә өйләнгән. Өммелхәят аеруча фарсы телен, ә Әхмәтша гарәпчәне һәм рус телен шәп белгән. Әхмәтша үз мәчете каршында мәдрәсә ачып җибәргәч, Өммелхәят шунда кызларга белем биргән. 1890 елда туган үз уллары Әхмәтзәки белән аның энесе Гәбделрәүфне дә шул ук мәдрәсәдә гарәп-фарсы теленә өйрәткәннәр, русчасын хатасыз белсен дип, күршедәге Макар авылы мәктәбеннән рус теле укытучысын да махсус чакырганнар. Шул мөгаллим Зәкине Стәрлетамактагы рус мәктәбенә бирергә кыстап караса да, кадими позициядә торган Әхмәтша хәзрәт моңа каршы төшкән. Мәгәр өйдә «төн сандугачы» Өммелхәят тә бар бит, шул Зәкине Үтәк авылында үзенең абыйсы Хәбибназар Сатлыков җитәкләгән җәдид мәдрәсәгә илтеп бирдерүгә ирешә. Хәбибназар исә – Казанның Мәрҗани мәдрәсәсен тәмамлап, остазы белән бергә сәяхәтләргә йөреп кайткан мөгаллим. Әхмәтша хәзрәт тә төшеп калганнардан түгел анысы, ул «Сәфәр әл-Хиджаз», «Ибн Сатлык хәяте» атлы әсәрләр дә язган. Ә Хәбибназар менә хәтта физика һәм метафизика фәннәре, остазы Мәрҗанинең «Мөстәфадел әл-әхбәр» китабы буенча аңлатмалар, «Тарих ачкычлары» кебек китаплар яза, «Нәвадир» китабын әле төрки телләргә дә тәрҗемә итә. Шушы ук мөгаллим кечкенә Зәкигә астрономия, математика буенча да лекцияләр

● Музей мөдире М.Вәлиева белән без Вәлиди сыны янында.

● Вәлиди беренче хатыны Нәфисә белән. 1920 ел.

ИЛЕНДӘ

● Темәс авылында тәүге башкорт хөкүмәте урнашкан йорт.

● Вәлиди белән Ф.Сөләйман төрекмән киемендә, Ашхабадтан Ирандагы Мәшһед каласына китү алдыннан. 1923 ел, гыйнвар.

● Вәлидинең кызы Исәнбикә белән оныгы Сара Көзән авылындагы һәйкәл янында. 2000 ел.

укый. Мәдрәсәдән тыш, Зәки Үтәк авылында әле Шәфыйк ахун белән дә танышып өлгерә, тегесе исә Мәрҗанинең үзе белән хат алышып гомер сөргән икән. Хәбибназар белем биргән шәкертләр дә күренекле. Әнә, Габдрахман хәзрәт Гомәри атлысы Әстерхан каласында «Идел» газетасы да чыгара. Димәк, Зәкигә дә күп укырга һәм зур калаларга юл алырга кирәк...

1908 елда Вәлиди Казанга килеп, Касыймия мәдрәсәсендә укый башлый. Аның тирән белем туплап килүен бик тиз чамалыйлар, икенче елда ук Зәки шәкертләргә төрки халыклар тарихы һәм әдәбият буенча белем бирә, бер үк вакытта «Төркиләр тарихы» атлы китап яза башлый. Зәки бер өлешен язып тәмамлаган кульязма нинди юл беләндер Галимҗан Ибраһимов кулына килеп эләгә. Әдип китапны йә «Татар тарихы», йә «Төрки-татар тарихы» дип атарга тәкъдим итә. Язып тәмамлагач, чынлап та, Вәлиди аны «Төрки вә татар тарихы» дип атый һәм 1912 елда «Милләт» типографиясендә бастырып та чыгара (1915, 1917 елларда аны кабатлап та бастыралар әле). Аны камилләштерү уе белән янган Вәлиди нияте буенча әлеге тарихи хезмәт ике том хасил итәргә тиеш була. Беренчесе борынгы төркиләр заманыннан алып Чыңгызхан, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларын үз эченә алса, икенче том Болгар дәүләтеннән башлап Казан, Себер һәм Кырым ханлыклары яулап алыну, рус империясенең кансыз хакимлеге, аңа каршы кузгалган Алдар тархан, Күчем морза һәм аның улы Акай батыр, Батырша, Салават-Кинҗә фетнәләрен яктыртуга багышланырга тиеш була, ягъни Вәлиди үзе дә белмичә, чит илгә качкан Морат Рәмзи язган китапны, шул ук тарихи вакыйгаларны параллель рәвештә кабатлап чыгуны планлаштыра. Шуны гына башкарып чыкса да, Вәлиди барча төрки һәм мөселман дөньясында танылган галим булып китәр иде. Ләкин мәгыйшәтнең һич тә көтелмәгән җирдә абындыра һәм шуның өчен тал чыбыгы белән сабак укыта торган сәгатьләре дә була икән шул әле.

Аңлашыла булыр, 22 яшьлек егет көе төрки-татар тарихына багышланган җитди хезмәт язгач, уртачадан да тәбәнәгрәк буйлы Вәлиди үзен иңенә канатлар үскәндәй хис итә башлый, мин-минлеге шеш шикелле күпереп чыкмый калмый. 1913 елның гыйнварында, Романовлар династиясенең 300 еллыгын файдаланып калу ниятеннән, Казандагы татар җәмәгатьчелеге зур җыелышка тупланып, анда патшадан кызлар гимназиясе ачуга рөхсәт алу турында сүз башлагач, Зәки Вәлиди тын гына утырып кала алмый. Сикереп тора да әлеге гимназияне, бигрәк тә аның каршында приют ачуга каршы чыга, Казанда гимназияне җитәкләрлек шәхес тә, анда укырга бирердәй лаек кызлар да юк, дип белдерә. Әлбәттә, аның чыгышын шундук өзәләр, мөнбәрдән үк куып төшерәләр. Вәлиди кызган баш белән шундук Оренбургта нәшер ителә торган «Вакыт» газетасына «Казанга хат» дип аталган язма юллый, нәширләр мәкаләнең асылына кереп азапланмый, аны 10 февраль санында бастырып та чыгара. «Таш-мөхәммәт» дигән тәхәллүс куеп, аны «Кояш» газетасында Фатыйх Әмирхан пыран-заран китерә. «Вакыт» газетасы Вәлидине яклаган Муса Бигиев һәм Шакир Мөхәммәдьяров мәкаләсенә урын биргәч, Әмирхан-Ташмөхәммәт инде Вәлидинең генә түгел, Бигиев белән Мөхәммәдьяровның да тетмәсен тетеп сала. Җитмәсә, әлеге талашны куптарган Вәлидине Казан жандармериясе исәпкә теркәп куя, аның артыннан күзәтү оештыру турындагы фәрман Уфа һәм Пермьдәге жандарм идарәләренә дә җибәрелә. Казандагы татар зыялылары алдында лидер таҗын кияргә җыенган Вәлиди он урлап тотылган күсе шикелле тын гына утырырга мәҗбүр була.

Әмма бу вакытта Вәлидинең «Төрки вә татар тарихы» хезмәтенә атаклы тарихчы Е.Катанов та игътибар итеп өлгерә. 1913 елның март аенда Казан университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыяте утырышында ул Зәки Вәлидине җәмгыятькә тулы хокуклы әгъза итеп алу тәкъдиме белән чыга. Шул елның 23 маенда Вәлидине кабул итеп тә куялар. Октябрь аенда уздырылган җыелышта Вәлиди үзен тарихи эзләнүләр өчен Фирганә өлкәсенә командировкага җибәрүләрен үтенеп мөрәҗәгать итә. 1914 елның мартына кадәр сузылган сәяхәт барышында Вәлиди Коканд, Әндиҗан, Ташкент, Сәмәрканд, Бохара һ.б. калаларда була, Йосыф Баласагуни, Әмин Бохари һ.б. әдип-галимнәрнең 23 кульязмасын табып кайта. Җәмгыять каршында хисап тотканнан соң Вәлиди Петербургка юнәлә һәм атаклы шәрекче В.Радлов өендә доклад ясый, аны бирегә кунак булып килгән галим В.Бартольд та тыңлый. Шул Бартольд тәкъдиме буенча, Император фәннәр академиясе Вәлидине янә 1914 елның июнендә Төркестанга командировкага юллый. Вәлиди күп шәһәрләр кичә, ә Каршы каласы базарында дарулар сатучы бер сәүдәгәрнең тауарны борынгы кульязма битләренә төреп җибәрүен шәйләп ала. Вәлиди кульязманы тулысынча кайтарып биргәч, академик Бартольд аны Коръәннең XI гасырда күчереп язылган бер нөсхәсе дип нәтиҗәгә килә.

(Дәвамы 14 нче биттә).

Зәки Вәлиди илендә

(Ахыры. Башы 12 нче биттә).

Уңыш тантанасын татырга насыйп булмый, сугыш башланды, дип Вәлидине медицина тикшерүе үтәргә чакырталар, ул Стәрлетамакка кайтып китәргә мәҗбүр була. Вәлидинең Бохара өлкәсенә сәяхәте турындагы хисап 1915 елда «Императорның рус археологлары җәмгыяте» ведомостьларында, ә «Төркестаннан хатлар» әсәре Г.Исхакыйның «Ил» газетасында 8 сан буе басыла...

Давыллы һәм хәвефле 1917 ел кергәч, Зәки Вәлидине 1 майда Мәскәүдә башланган I корылтайда Бөтенроссия мөселманнар советының Башкарма комитет әгъзасы булачак, Милләт Мәҗлесе депутаты итеп тә сайлыйлар, ул эсерлар партиясенә дә керә. Ләкин Казанда лидер таҗын кию бәхете насыйп булмаган Вәлиди инде җәй уртасында Шәриф Манатов белән бергә татарлардан башка хәрәкәт итү юлын сайлый. 22 июльдә Казанда башланган II мөселманнар корылтаена бармыйча, Вәлиди белән Манатов Оренбургта башкорт халкының I, август аенда Уфада II корылтаен җыя һәм башкортларның Үзәк шурасын сайлата. 1917 елның 15 ноябрендә шул шура Оренбург каласында Россия составындагы Кече Башкортстан милли-территория автономиясен игълан итә. Татар халкының 22 ноябрьдә Уфа каласында җыелган Милләт Мәҗлесе Галимҗан Ибраһимовны Идел-Урал штатына кушылырга чакыру өчен юллап караса да, яңа гына сайланган Башкорт корылтае һәм башкорт гаскәрләренең юлбашчысы итеп билгеләнгән Вәлиди максатыннан чигенми...

1918 елның февралендә большевиклар З.Вәлидине һәм аның 8 иптәшен кулга алып, Оренбург төрмәсенә ташлый. Ләкин апрель аенда аларны Оренбургка бәреп кергән Дутов казаклары һәм башкорт полклары азат итә. Вәлиди шундук башкорт полклары командующиена әверелә һәм чех-словак корпусы башлаган фетнәгә кушыла. Дутов аңа – корал, ә Самарада тупланган Комуч җитәкчеләре хәрби кием, азык-төлек һәм акча белән ярдәм итә. Вәлидигә халык армиясенең полковнигы дәрәҗәсе бирелә. Үзе үк игълан иткән Кече Башкортстан волостьларына отрядлар җибәреп, Вәлиди үз армиясенә һаман гаскәр туплый. Татар һәм башкортлар арасыннан Ш.Ходайбирдин, Муса Мортазин, Сөләйман Морзабулатов, Гали һәм Госман Терегуловлар, Габдерәшит Бикбауов, Габдулла Әдһәмов, Шәйхзадә Бабич, Илдархан Мутин, Галимҗан Таган, Харис Җомагулов кебек ярдәмчеләр һәм полк командирлары үсеп чыга. Башкорт полклары адмирал Колчак байрагы астында Кызыл Армиягә каршы сугышларга керә, ләкин Колчак тарафыннан «Бернинди Башкортстан республикасын да танымыйм, Россия – бердәм һәм

● Нәҗмия, Сүбедәй, Исәнбикә, Зәки Вәлидиләр. 1950 еллар башы.

● Әхмәтша хәзрәтнең ихатасы 1931 елда.

бүленмәс», дигән карагруһчыл сүзләрне ишетүгә үк, Вәлиди астыртын рәвештә генә кызыл командирлар белән сөйләшүләр башлый, әмма бердәнбер таләп үзгәрешсез кала – «Башкортстанга аерым республика булып яшәргә ирек бирегез!» Айлар буе яшертен сөйләшүләрдән соң совет властеның үзәк органнары белән Башкорт республикасы җитәкчеләре арасында килешүгә кул куела. 1919 елның 19 февралендә Зәки Вәлиди үз полкларына кызыллар ягына чыгып кушылырга фәрман бирә. 21 февральдә Баймак волостеның Темәс авылында узган офицерлар җыелышында Вәлидине хәрби эшләр буенча халык комиссары һәм вакытлыча хәрби-революцион комитетның рәис урынбасары итеп сайлыйлар. 1919 елның мартында Башкортстан совет республикасы төзелү турында хөкүмәт указы игълан ителә. Вәлиди инде тулы хокуклы совет республикасын төзү өчен көрәшкә ташлана. Иң гаҗәбе шул: Вәлиди башкорт хөкүмәте составында чит илләр белән бәйләнеш министры һәм хәрби эшләр министры постларын да булдыра һәм, Мәскәү хөкүмәтенең ярсып өрүенә дә карамастан, ул постларны юкка чыгармый (бүген Татарстанда оборона министры һәм тышкы эшләр министрлыгы эшләүне күз алдыгызга китерегез әле).

1919 елда Вәлидине Советларның Мәскәүдә узган VIII, чираттан тыш корылтаена чакыралар. Анда Татар-башкорт совет республикасын төзү планы тикшерелә. Вәлиди моңа кискен каршы чыга һәм хәзер инде үзе Кыргыз-башкорт (дөресе казах-башкорт) республикасы төзү проектын тәкъдим итә. Вәлиди Сталинның бик тә тиздән «республикаларның чит илләр белән чиктәш булсалар гына аерылып чыгарга хокукы бар», дигән шарт уйлап табачагын алдан сизгән, ахры.

Вәлидинең баш бирмичә, хан булып маташуы да, аның Төркестандагы Алаш Урда җитәкчеләреннән Мостафа Чокаев белән яшерен сөйләшүләр алып баруы да туйдырган, күрәсең, 1920 елның җәендә Әхмәтзәкине Кремльдәге келәмгә чакырталар. Үзен нинди әҗәл көтүен дөрес чамалагандыр, Вәлиди Урта Азиягә, советларга каршы көрәшүче милли-азатлык тарафдарлары янына качарга карар кыла. Әле кыш көне генә өйләнешкән хатыны Нәфисәне калдырып, Вәлиди әүвәл Бакуга, ә аннан Төркестанга чыга. Анда басмачылар хәрәкәтенә кушыла, дини дошманлык юлында булган көрәшчеләрне милли-азатлык рухы белән сугарылырга чакыра һәм бик тиздән Төркестан бердәм милли советының рәисе булып сайлана. Шунда яшәгән чакта Вәлиди Ленинга, Сталин, Троцкий һәм Рыковка адресланган хатлар юллый һәм аларны бөек рус карагруһчылыгын җәелдерүдә һәм вак милләтләрне юк итүдә гаепли. Вәлидинең башкорт яшьләренә адресланган хаты да сакланган, аннан ике генә җөмлә: «Аларның моннан соң үткәреләчәк сәясәтенең программасы – Рәсәйнең үзендә генә түгел, Европадагы һәм Азиядәге күрше өлкәләрдә дә рус теленең һәм мәдәниятенең хакимлеген тәэмин итү... Котылгысыз күренгән, террорга корылган хакимлек...»

1923 елда З.Вәлиди Фәтхелкадыйр Сөләйман (Төркиягә күчкәч алыштырган исеме – Әбделкадир Инан) белән Иранга чыгып кача. Һәм шундагы Мәшһед каласы китапханәсендә Ибн Фадланның кабатланмас «Бөек Болгарга сәяхәт» атлы әсәренең кульъязмасын таба. Бу хәзинә инде Вәлидине бар дөньяга билгеле галим итеп таныта (Бүген «татар теле белән абзар артына да чыгып булмый», дип бугаз яручы милләтсатарларның яңагына сугардай җавап та бу!). Без ике ай элек кенә Болгарда ислам дине кабул ителүнең 1100 еллык юбилеен билгеләп үттек, анда Ибн Фадлан кульъязмасы да зурланды, әлеге вакыйганы тасвирлаган картиналар һәм кинолар туды, ә асылда шушы бөек тантананы бүләк иткән Әхмәтзәки Вәлиди исеме генә телгә алынмады! Әюгыйсә бу дөньякүләм вакыйга өчен Ә.Вәлиди каршында бүгенгәчә, бетмәс бурычлы без!..

1924 елда Вәлиди Берлин каласына килеп, студентлар алдында чыгышлар ясый башлый, Гаяз Исхакый белән күп мәртәбә низагларга керә. 1925 елда Төркия хөкүмәте Вәлидигә гражданлык бирә. Анда килгәч, ул Төркия мәгариф министрының киңәшчесенә әверелә, бер үк вакытта Истанбул университетында профессор булып эшли, «Төркестан» газетасын чыгара, үзе кебек үк качып килгән М.Чокаев белән «Яңа Төркестан» сәяси оешмасын төзи һәм Төркия тирәсендә берләшергә чакыра. 1932-1935 елларда Вена университетында белем алганнан соң, Вәлиди шунда ук «Ибн Фадлан язмалары» темасына докторлык диссертациясе яклый. Шул елда Германиянең Бонн университетында укыта башлый, ә 1939 елның 1 сентябрендә Гитлер Польшага бәреп керүгә үк, Германияне ташлап, Төркиягә кайта.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Советлар илендә Вәлидине «Гитлер ялчысы, аның хезмәтчесе», дип гаепләп чыгалар. Шул ук Россия басмасы астында Төркия хөкүмәте Вәлидигә «туранчы» дигән ярлык та тагып куя. 1944 елның маенда аны кулга алалар һәм төрмәгә ыргыталар, ләкин 17 айдан соң ул иреккә чыгарыла. 1948 елда янә Истанбул университеты профессоры булып эшли башлый, 1951 елда Халыкара шәрыкчеләр җәмгыятен, ике елдан соң Ислам тикшеренүләр институтын оештыра һәм аның директоры булып билгеләнә. Аңа АКШ, Иран, Пакыстан, Һиндстан, Австрия, Финляндия университетларында лекцияләр уку бәхете эләгә. Үз гомерендә 11 телдә язылган 400 дән артык фәнни хезмәт бастыра. Әхмәтзәки Вәлиди 1970 елда Төркиядә вафат була, җәсәде Истанбулның Карача-Әхмәт зиратында җирләнә... «Әгәр туган илемә әйләнеп кайта алсам, мин авылым мәктәбендә балалар укытыр идем», дип хыялланган Вәлиди туган җирен кабат күрә алмый шул. «Тик бәхетле кошлар гына иленә кайтып үлә», дигән гыйбарәдә мең хаклык бар...

Рәсәй богавында калган гаиләсенә әйләнеп кайтсак, аның этисе Әхмәтша белән энесе Габделрәуфне 1938 елда большевиклар атып үтерә. Рәсәйдәге хатыны Нәфисә белән кушылу турында хыяллана алмый һәм 1940 елда Румыниянең Добруджа вилаятеннән Төркиягә укырга килгән ногай кызы Нәҗмия белән Вәлиди яңа гаилә кора. Аларның Исәнбикә белән Сүбедәй атлы балалары соңыннан фән докторларына әверелә. Алар 1990 елда – Вәлиди тууның 100 еллыгын үткәргән чакта Уфа каласында, этиләренең туган авылы Көзәндә дә кунак булып китә...

Музейда Вәлидинең истәлекләре бик күп. Музей мөдире Миңнира Вәлиева безне аларның һәммәсе белән дә, бер дә иренмичә таныштырып чыкты. Аннары авыл уртасында Зәки Вәлиди истәлегенә салынган сквер һәм аның уртасына куелган стела-һәйкәл янына килеп саубуллаштык...

Гафури районына барышлый Янурус, Табын, Яугилде, Зирек, Бурлы, Үзбәк, Яңа Зирек, Игенчеләр, Үтәк, Торай, Юлык авыллары аша уздык, берничәсендә туктап, халкы белән аралашып алдык. Яшереп торучы юк – һәммәсе дә татар авыллары. Күңелгә җылы йөгергәндәй тоела, әмма баш миен туктаусыз ут талый.

Безнең милләттә дә бар дөньяга мәгълүм Садри Максуди, Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый шикелле көрәшчеләр бар бит. Әмма нишләп башкорт халкы татар улы булган Вәлидине үз каһарманнары итеп күккә күтәрә дә, ни сәбәпле безнең җитәкчелек бөек Исхакый туган Яуширмәне «илтотмыш» агалар нигезләгән Звенигово ит комбинатына сатып җибәрә соң? Мондый капма-каршы сәясәтнең җимешләре барыбер өлгерә бит. Әнә, башкорт егетләре ОМОНнардан, гади халык киеменә төренгән яллы җанкыярлар отрядыннан курыкмыйча, газиз җирләренең бер энҗесе булган Куштау биеклеген саклап калды. Әгәр форсат туса, алар газиз җөмһүриятләрен саклау, Салават һәм Вәлиди рухын яклау өчен дә яуга керәчәкләр. Ә муенына камыт кидерелгән татар халкы нишләр?..

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

Мөхтәрәм тарихчы

(Равил Фәхретдиновның тууына 85 ел)

Куаныч ки, соңгы ярты гасырдан артык вакыт эчендә халкыбызга фидакарьләрчә хезмәт иткән галим-әдипләребез, мәдәният һәм мәгърифәт әһелләребез, җәмәгать эшлеклеләребез шактый. Шундыйларның иң күренеклеләреннән берсе – Равил Габдрахман углы Фәхретдинов (1937-2014).

Бу мөхтәрәм шәхесебезнең 1973 елда (5 мең данәдә) дөнья күргән «Җырчы» исемле китабы бар. Анда үтемле, мавыктыргыч итеп бөек моңчыбыз Илһам Шакиров хакында сүз бара. Галимнең кайбер башка иҗат әһелләре турында да язмалары бар. Аның җыр-музыка, гомумән, сәнгать төрләре белән кызыксынуы һич тә очраклы хәл түгел. Чын татар төбәгендә – Балтач якларында туып-үскән бу затның күңелендә җыр-моңга, мәдәниятккә мәхәббәт ята. Ул мәктәптә укыган елларында да төрле концерт-кичәләрдә катнаша. Казан педагогика институтының тарих-филология факультетында аның белән бер чорда белем алган студентлар Равил әфәнденең ансамбль-хор, агитбригадалар оештыруын, төрле урыннарда, хәтта Мәскәүдә дә концертлар куеп йөрүен искә ала.

Балтач-Кариле егете матур әдәбияттан – сүз сәнгатеннән дә бик тә хәбәрдар иде. Әдипләр белән еш аралашып торды. Ул матур, образлы телстиль белән язылган, тарихыбызның мөһим сәхифәләрен, аерым күренекле шәхесләрен яктырткан берничә фәнни-популяр китап авторы да. Аның «Ташлар моңы» (1978), «Мондадыр безнең бабайлар» (1992), «Татар углы, татармын» (1993), «Кичке азан» (1997) кебек зур тиражлар белән басылган, халкыбызны милли рухта тәрбияләүгә зур өлеш керткән кайбер башка китаплары киң катлам укучыларга яхшы таныш. Юкка гына ул Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булып тормый! Бездә үзләре дә әдәби иҗат белән шөгыльләнгән Ризаэддин Хәзрәт, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Габдрахман Сәгъди кебек тарихчы галимнәр бар. Равил әфәнде дә, чордашлары Миркасыйм Госманов, Әзһәр Мөхәммәдиев, Равил Әмирхан белән берлектә, үз элгәреләренең традицияләрен дәвам иттерә: татарча чыганакларны да камил белә, үз туган телендә дә оста итеп яза.

Равил Фәхретдинов – барыннан да элек тарихчы галим. Аның бөтен фәнни эшчәнлеге диярлек Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты белән бәйле: әүвәл – аспирант, аннан – гыйльми хезмәткәр. Мәгълүм ки, бу фәнни оешманың тарих тармагы 1997 елда Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты рәвешендә мөстәкыйль рәвештә яши башлый. Галимебез алдагы эшчәнлеген шул оешма кысаларында дәвам иттерә. Болгар дәүләтенең археологик ядкярләрен өйрәнеп, 1968 елда Мәскәү дәүләт университетында кандидатлык диссертациясе яклый. 1990 елда тарих фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була.

Р.Фәхретдинов – Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы мәмләкәтләрен, чорларын археологик яктан ныклап һәм озаклап өйрәнгән олуг белгеч. Аның тикшеренү-казыну нәтиҗәләрен туплаган күпләгән мәкалә-хезмәтләре, монографияләре рус, татар, инглиз һ.б. телләрдә дә нәшер ителгән, гыйльми җәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Галимнең фәнни табышлары тарих фәненә зур өлеш кертте. Ул тапкан экспонатядкярләр күп кенә музей-тыюлыкларын бизәп тора.

Равил әфәнде, археологик тикшеренүләр белән тыгыз бәйләнештә, халкыбызның этник, дәүләтчелек тарихын өйрәнүдә дә бик тә нәтиҗәле эшләде. Ул татар-төркинең тарихын борынгы чорлардан алып соңгы дәвергәчә яктырта, халкыбызның үткән юлын процесс рәвешендә карый, андагы күп кенә вакыйга-хәлләрне, проблемаларны шактый дәлилле, үтемле итеп анализлый. Әүвәл Болгар белән бераз мавыгыбрак алган галимебез бераздан Алтын Урда тематикасына ныклап күчте, бу мәмләкәтнең этник, дәүләтчелек тарихыбызда гаять мөһим роль уйнавын күрсәтте. Мәгълүм ки, 1992-1993 елларда Алтын Урданың төзелүенә 750 ел тулу киң билгеләп үтелде: төрле конференцияләр, гыйльми-мәдәни чаралар үткәрелде, шактый гына хезмәтләр дөнья күрде. Аларны башлап, оештырып йөрүчеләрнең берсе Равил Фәхретдинов иде.

Мәгълүм ки, совет чорында татар тарихын объектив, гыйльми нигезләрдә өйрәнү һич тә канәгатьләнерлек булмады. Евразиянең, Идел-Уралның зур мәйданнарында яшәгән халкыбызның тарихын тар Болгар, Татарстан кысаларында гына карау рәсми яктан хупланды, Алтын Урдага һәм аның җирлегендә корылган татар ханлыкларына, нигездә, тискәре караш өстенлек итте. Бу, әлбәттә, безнең шактый гына зыялыларыбызда ризасызлык тудырды. Үзгәртеп кору елларында, аеруча Советлар Берлеге таркалгач, милли тарихыбызны язу бик тә мөһим проблема булып алга басты. Шул ихтыяҗны, зарурияттне канәгатьләндерү йөзеннән күпләгән хезмәтләр язылды, игелекле гамәлләр кылынды. Бу хәрәкәтнең дә алгы сафларында Равил әфәнде торды: чыгышлар ясады, мәкалә-хезмәтләр бастырды. Җиде томлык «Татар тарихы» язылуга да үзеннән сизелерлек өлеш кертте.

Халкыбызның милли үзаңы түбән булуда иң төп сәбәпләрнең берсе – мәктәпләрдә, уку йортларында татар тарихы өйрәнелмәү иде. Узган гасырның 90 нчы елларында бу мәсьәлә бөтен кискенлеге белән көн тәртибенә куелды, аны хәл итү юнәлешендә мөһим генә чаралар үткәрелде. Педагогик ихтыяҗны күздә тотып, дәреслек-әсбаплар языла башлады. Бу эштә дә чын татарпәрвәр Равил әфәнде өлгерлек күрсәтте: татар һәм рус телләрендә «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» буенча дәреслек-әсбаплар язды. Алар гаҗәеп зур тиражлар белән кат-кат нәшер ителде. Ни үкенеч, инде дистә елдан артык бу курсны мәктәпләрдә аерым предмет буларак өйрәнү туктатылды.

Хезмәттәшләре, аны белгән кешеләр Р.Фәхретдиновның куйган максатына омтылучы, яхшы мәгънәсендә үҗәт зат булуын искәртә. Ул, мәсәлән, «Татарская археология» журналын (1997-2006) үзе йөреп, үзе оештыра, аның баш мөхәррире дә була. Аның бу юлда күпме йөргәннәрен, күпме түрәләрдә булуын мәзәк рәвешендә хәзер дә сөйлиләр. Гадәттә, туры сүзле, тәвәккәл кешеләргә яшәү, эшләү җиңел булмый. Равил әфәнде дә төрле кыенлыкларны күп кичерә. Шуңа да карамастан, ул күп төрле бүләкләргә, рәсми дәрәҗәләргә ия була: «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе», «Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты» һ. б. Аның Г.Камал театрындагы 60 яшьлек юбилей кичәсе зур бер вакыйга рәвешендә узды. Шыгрым тулы залда галимне ничек зурлауларына без - аның фикердәшләре куанып утырдык. Миңа 2007 елның ноябрендә Равил әфәнде белән Мәскәүдә Кызыл мәйдан янындагы Тарих музее бинасында үткән дөнья археологларының Халыкара конгрессында булырга, аның пленар утырышында Алтын Урда әдәбияты хакында доклад ясарга туры килгән иде. Анда катнашучыларның, шул исәптән М.Крамаровский, В.Егоров кебек мәшһүр тарихчыларның безнең галимебезгә бик тә ихтирами мөнәсәбәтен күреп, тоеп тордым.

Күренекле тарихчыбызның хезмәтләре, гыйльми-иҗтимагый-мәдәни эшчәнлеге хакында шактый гына язмалар, рецензияләр, шул исәптән безнең дә «Хәтер утын сүндермик» дигән мәкаләсе бар. Тынгысыз галимебезнең шәхесе, эшчәнлеге хәтта әдәби әсәрләрдә дә гәүдәләнеш тапты. Мәсәлән, Марат Әмирхановның «Тояк эзе» романындагы (2001) төп геройларның берсе булган Кәшшаф Хәмитов образында Балтач егетен абайлау кыен түгел.

Р.Фәхретдинов – күпләгән тарихчыларның остазы, гыйльми җитәкчесе. Мәсәлән, Ш.Мәрҗани исемендәге институттагы Алтын Урда бүлеге җитәкчесе Илнур Миргалиев – аның элеккеге аспиранты.

Равил әфәнде – гаиләви яктан бәхетле кеше. Итагатьле, ачык йөзле җәмәгате Әлфия ханым озак еллар Мәгариф министрлыгында эшләде. Галимнең милли җанлы, телебезне, әдәбиятыбызны, сәнгатебезне яхшы белгән уллары, оныклары бар.

Хәзерге гыйльми-мәдәни, мәгърифәти тормышта актив катнашучы, радио-телевидениеләрдә еш кына чыгышлар ясаучы, төрле җаваплы урыннарда хезмәт итүче, Раил Фәхретдинов – күпләргә таныш. Ул тарих фәннәре докторы, профессор, КФУда кафедра мөдире. Бу абруйлы зат этисенең нәселен генә түгел, фәнни эшләрен дә дәвам иттерә. Күп санлы хезмәтләре бар. Әле 2021 елда этисенең һәм үзенең язганнарын бергә туплаган гаять саллы монография дөнья күрде.

«История татарского народа» дип исемләнгән бу китап (415 с. – 33,5 т.) искиткеч бай эчтәлекле, файдалы басма. Анда халкыбызның борынгыдан алып хәзергәчә тарихы эзлекле рәвештә бәян ителә. Бу хезмәттә мөһим чыганаклар, документлар, иллюстратив материаллар теркәлгән, татар тарихына, Татарстанга мөнәсәбәтле төрле телләрдәге 479 исемдәге библиографик исемлек тә бирелгән...

Быел март аенда Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында Равил Габдрахман углының тууына 85 ел тулуга багышланган махсус чара – искә алу кичәсе булды. Анда күпләгән җәмәгатьчелек һәм хакимият вәкилләре, әдипләр, галимнәр, якташлары катнашты, Равил әфәнденең күпкырлы эшчәнлегенә югары бәя бирелде, хезмәтләренең бүгенге һәм киләчәк тормышыбыз өчен дә актуаль, файдалы булуы искәртелде.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы.

Татарстанның халык артистлары, ирле-хатынлы Сәкинә һәм Рамил Минхановлар беренче карашка бик төрле кебек. Шомырт кара күзле, кара чәчле Сәкинә ханым кайнар испан хатыннарын хәтерләтә. Тамырлары Татарстанның Чирмешән районына барып тоташса да, Иркутскида туып үскәнгәдер, мөгаен, Рамил әфәндедә бераз рус кавеменең чалымнары бар. Сәкинә Минханова, татар хатын-кызының бөтен күркәм сыйфатларын үзендә туплаган, ул тыныч табигатьле, итагатьле, күркәм холыклы. Ире Рамил Гаяз улы шаян-шук, тере, хәрәкәтчән. Әмма язмыш аларны бер-берсенә шундый итеп беркеткән ки, бүген Минхановларны аерым күз алдына китерүе кыен.

Сәхнә, сөю һәм сәгадәт

Бу тарих күп еллар элек, Сәкинә Балык Бистәсенең Яңа Арыш авылыннан килеп, Казан театр училищесын тәмамлаганнан соң, Әлмәт театрына артист булып кайткач башлана. Әмма язмыш китабында ул әллә кайчан билгеләнеп куйган була инде. Юкса филармония өчен конферансье буларак әзерләнгән кызның Әлмәттә актриса булып китүен башкача ничек аңлатырга? Нәкъ шул вакытта Әлмәт театры режиссеры Рөстәм Абдуллаевның, Мохтар Ауэзовның «Каракүз» спектаклендә Каракүз ролен башкарыр өчен актриса эзләп, Казанга килүен күр әле. Казан кадәр Казанда Каракүз ролен башкарырлык актрисалар беткәнме, дип аптырарга мөмкин кемдер. Ләкин бу спектакле өчен гадәти булмаган, казах кызларына охшаган кыз табу мөһим икәнен онытмыйк. Сәкинәләрнең авылы Яңа Арыш турында, башкортлар яшәгән авыл, дигән сүз күптәннән йөри. Кыз фамилиясе дә Ишмөхәммәтова. Казах далаларында кояшта каралгандай кара тәнле, кап-кара чәчле, кара күзле кыз режиссер Р.Абдуллаевның игътибарын җәлеп итүе гаҗәп булмаса да, конферансье булырга укыган кызның драма театрына, туган ягыннан шактый ерак урнашкан Әлмәткә барырга батырчылык итүе гадәти генә хәл түгел. Сәкинә, курыккандыр да, бәлки. Әмма сәхнә теле мөгаллиме, күренекле театр артисты Асия Хәйруллина теләсә кемгә, син актриса булырга тиеш, дип хәер-фатихасын бирер идемени? Үз көченә ышанып бетмәсә дә, Сәкинә якын күргән укытучысына ышанмыйча булдыра алмый. Казанда да бик әйбәт урнашачак иде ул, әлбәттә. Тугыз кешелек төркемнән бары тик аны һәм Илфат Габдрахмановны филармониягә эшкә алып, күренекле җырчы Римма Ибраһимованың концерт бригадасына билгелиләр. Бер якта Асия апа драма театрына баруын тели, икенче якта филармониянең директоры Илгиз Мәҗитев нәкъ Казан үзәгендә Татарстан урамында бер бүлмәле фатир ачкычын зыңгылдатып басып тора. Яңа гына училище бусагасын атлап чыккан кыз өчен нинди зур мәртәбә! Әмма язмышыңа язылса, ачкыч зыңгылдавын түгел, колак төбендә барабан кагып торсалар да, ишетмәячәксең. Шулай итеп, кыз Әлмәт театрында иҗат итә башлый. Әлмәт театрының актеры, аннары режиссер вазифасын өстенә алган, шуннан соң озак та тормыйча, Әлмәттән китеп, Оренбургта татар театрын оештырган киң карашлы, сизгер, зирәк күңелле Рөстәм Абдуллаев татар театр сәнгатенә Сәкинә исемле йолдыз бүләк итә. Ә соңрак алар икәүләшеп татар сәхнәсендә Рамил Минхановны «кабыза».

Сәкинә кечкенәдән театр сәхнәсенә кызыгып үссә, Рамилнең сәнгать дөньясына килеп керүе бөтенләй көтелмәгәнчә килеп чыга. Әтисе Гаяз абый хәрби оешмада эшләгәнлектән, аларга гаилә белән ерак җирләргә яшәргә күчәргә туры килә, Иркутскидан соң Монголиядә яшәп алалар. Аннары Әлмәткә кайтып төпләнәләр. Рамил нефтьчеләр шәһәрендә урта мәктәпне тәмамлый һәм Әлмәт театрына машина йөртүче булып урнаша. Чибәр, гитарада уйнап матур итеп җырлаучы Рамил һәм көләч йөзле, сылу Сәкинә театрда очраша. Башта яшерен генә бер-берсен яратып йөргән булсалар, бергә гастрольгә чыккач, ерак юллар романтикасы мәхәббәт хисен тагын да көчәйтеп җибәрә һәм бер ел дә үтмәс борын, Минхановлар гаиләсе барлыкка килә. Әмма кинәт мәхәббәт күгендә болытлар куера башлый. Рамилнең әнисе сәүдә өлкәсендә эшли, улын да укытып, шушы тармакка кертәсе килә. Сәкинә исә, миңа да театрдан китәргә туры килмәгәе дип, чын-чынлап куркуга төшә. Сәхнә төмен татый гына башлаган кызның театрдан китәсе килми. Һәм бервакыт «Мин дүрт ел укып, китәр өчен, театрга эшкә килмәдем», - дип кайнанасына әйтеп салганын сизми дә кала. Чыннан да, испан хатыннарының горурлыгы бардыр бу ханымда! Рамил шул вакыт «Сәкинәм театрдан китми икән, алайса мин артистлыкка укыйм», – дип әйтеп куймасынмы! Бу хәбәр аяз көнне яшен суккан кебек яңгырагандыр. Әмма Рамил ике сөйләшә торганнардан түгел. Әйттеме – бетте! Кыю, чын ирләр генә мәхәббәт хакына таулар әйләндерергә әзер. Рамил Минханов – әнә шулар туфрагыннан.

Менә алар Казан каласында. Рамил театр училищесының курчак театры артистлары бүлегендә укый. Сәкинә балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Ир кая, хатын шунда. Сәкинә кебек тугры хатыннар өчен тузга язылмаган закон бу. Олы уллары Айвар артыннан, озак та тормыйча, бәләкәчләре Айрат дөньяга аваз сала. Ниһаять, шатлыклы көн килеп җитә. Рамилнең кулында – театр училищесы дипломы. Бер күзе - рус яшь тамашачы театрына, икенчесе «Әкият» курчак театрына караган. Кая барса да, сәхнә өчен яратылган тере егетне биш куллап эшкә алачаклар иде. Әмма күңел балачак, яшьлек үткән шәһәр Әлмәткә, эти-әни, туганнар янына тарта. Рус мәктәбендә, рус бүлегендә укыдың, бер авыз татар сүзе белмисең, дип карышса да акыл, табигать һәм мәхәббәт каршында адәм баласы чарасыз бер йомычка кебек кенә. «Ө», «ү», «ә», «ң», «һ», «җ» авазларын әйтергә өйрәнү Җир шарының иң биек Эверест тавына менүгә караганда да авыррак икәнен Рамил эшли башлагач кына аңлаячак. Җөмләдә басымны дөрес җирдә куярга гадәтләнү дөньядагы иң зур Амазонка елгасын йөзеп чыгу кебек кыен, дигән фикер спектакльдән спектакльгә көчәя генә барачак. Роль ятлап чыккан йокысыз төннәр дә, булмый, китәм, дип төшенкелеккә бирелгән мизгелләре дә шактый җыелыр. Авыр вакытларда аны әлеге дә баягы режиссер Рөстәм Абдуллаев канатландырыр. Сәхнә өчен туган Рамилне тыныч күңел белән ничек эштән җибәрсен, ничек әрәм итсен ул? Китап арты китап укытып, рус мохитендә үскән егетнең телен шомартыр, сөйләмен көйләр. Театрда Абдуллаев тырышса, өйдә Сәкинә уяу тора. Рамилгә бер рус сүзе әйттерми. Бу тәмле телле актрисаны Аллаһ тикмәгә генә талантлы шагыйрьләребез Роберт Әхмәтҗан, Кадыйр Сибгатуллин, Равил Фәйзуллин, яраткан театр актерларыбыз Равил Шәрәфи, Хәлим Җәләй, Рауза Хәйретдинова белән бер туфрактан яралтмаган. Телең юк, дип Рамилнең өмет канатларын кисмәгән, өйрәнергә, шомарырга мөмкинлек биргән өлкән буын артистлар Камил Вәлиев, Дамирә Кузаева, Луиза Солтанова, Роза Салихова, Вәзилә Исламова, Фоат Зарипов, Венера Шәрипова, Люция Абдуллаева, Идрис Мәсгутов, Зөһрә һәм Рәис Шәйхетдиновларны да олы хөрмәт белән телгә аласы килә. Төрле спектакльләрдә партнер булган яшьтәшләре Раушания Фәйзуллина, Рафик Таһиров, Дилбәр Әбүнәгыймова, Фәймә Бикморатова, Асия Харисованы ничек онытасың? Бүген ирле-хатынлы Сәкинә һәм Рамил Минхановлар Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исемгә ирешкән икән, үзләренең тырышлыклары һәм талантлары өстенә Әлмәт театрының йөзек кашы булган шушы шәхесләрнең дә өлеше бар, әлбәттә.

Артистның бәхете режиссердан. Минхановларга төрледән-төрле утызлап режиссер белән иҗат итү бәхете елмая. Абдуллаевтан соң килгән Чулпан Әхмәтвәлиева, Ташкенттан чакыртылган Гали Хөсәенов, Зәкия Туешева, Уфадан килгән Байрас Ибраһимов, Фаил

Ибраһимов, Гафур Каюмов һ.б. Казаннар Фәрит Бикчәнтәев, Ренат Әюпов, Илдар Хәйруллин да Әлмәттә матур спектакльләр куя. Алар – һәрберсе шәхес, Әлмәт артистларының башка режиссерлар күрми калган якларын ача. Шуңа күрә Минхановларның иҗат биографиясе бик бай. Сәкинә Минханованың Туфан Миңнуллин әсәре буенча Илдар Хәйруллин куйган «Гөнаһсыз гөнаһлылар»да сөяркә Әнисә роле, һичшиксез, Әлмәт театры тарихында калачак. Камал театрында Әнисә ролен башкарган күренекле артистка Фирдәвес Хәйруллинаның Әлмәткә барып уйнавы, Сәкинә ханымның исә Камал театры сәхнәсендә шушы роль белән имтихан тотуы – үзе тарих. Илгиз Зәйниевнең әсәре буенча Нәфисә Исмәгыйлева куйган «Балакаем» спектаклендә Ана образы, И.Абдуллин әсәре буенча Камил Вәлиев сәхнәләштергән «Айсылуның айлы кичләре» спектаклендә Марфа роле шулай ук актрисаның иҗат бакчасында иң затлы чәчкәләр сыман, еллар үткәч тә матурлыгы онытылмый. Әле кайчан гына бер авыз татар сүзе белмәгән Рамил Минханов татар классиклары Мостай Кәрим, Мирхәйдәр Фәйзи, Заһир Исмәгыйлев, Аяз Гыйләҗев әсәрләре буенча куелган «Ай тотылган төндә», «Ак калфак», «Кодача», «Оҗмах капкасы» спектакльләрендә Дивана, Бакый, Яппар, Җиһангир рольләрен онытылмаслык итеп башкара. Режиссерлар Р.Хаҗиәхмәтов, Ф.Бикчәнтәев, Б.Ибраһимов, Р.Әюпов Р.Минхановның сәхнә сөйкемлелеген, рольдән рольгә үзгәрү осталыгын югары бәяләгән, димәк.

Минхановларның бер үк спектакльләрдә катнашуын күрмичә мөмкин түгел. Бу гадәт башлангыч чор иҗатларында ук урнаша. Әлмәт театры 1989 елда гына биналы була, аңа кадәр исә труппага ел әйләнәсенә гастрольдә йөрергә туры килә. Рамилгә роль бирсәләр, Сәкинә уйныймы, дип сорый. Сәкинәне берәр рольгә билгеләсәләр, Рамил катнашамы, дип кызыксына икән. Аерым уйнарга ризалашмыйлар. Өч көнлек гомерне берсе – өйдә, икенчесе гастрольдә уздырасылары килми аларның. Театр төпләнеп иҗат итә башлагач та бу гадәт дәвам итә. Килгән режиссерлар да аңа күнергә мәҗбүр була. Моннан берничә ел элек Германиягә Сабан туена барырга тәкъдим алгач та, Рамил баш тарта, Сәкинәм булмагач, ялгыз башым анда нишләп йөрим, ди...

Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, дигән сыман, бер-берсе хакына рольләрдән баш тартсалар да, соңрак мәхәббәт Минхановларга дөнья ишекләрен киң итеп ача. Режиссер Искәндәр Сакаев килеп М.Ю.Лермонтов әсәре буенча «Гашыйк Кәриб» спектаклен сәхнәләштергәч була бу хәл. Бу спектакль белән кайларда гына катнашып, нинди генә бәйгеләрдә җиңү яуламыйлар. Санкт-Петербургта «Арлекин» Бөтенроссия балалар театрлары фестивалендә, Балаковода кече шәһәрләр фестивалендә, Пензада Лермонтов хөрмәтенә уздырылган зур чарада, Бурятиянең башкаласы Улан-Удэда, Төркиянең Мармарис шәһәрендә, Дагыстанда Татарстан һәм Кавказны берләштергән риваятьләр фестивалендә дисеңме. Үзебезнең «Тантана» премиясен алуын әйтеп торуы да артык. Аннары Македониядән К.Гоцциның «Болан-патша» әкиятен сәхнәләштерергә режиссер Звездана Ангеловска килә. Ул спектакль дә Лысьвада кече шәһәрләр фестивалендә бүләкләнә. Шекспир әсәре буенча режиссер Искәндәр Сакаев әзерләгән, Рамил Минханов катнашкан «Ромео һәм Джульетта» спектакленең Коломнада кече шәһәрләр бәйгесендә гран-при алуын да онытмыйк. Шул ук Сакаевның Брехт әсәре буенча куелган «Туй» спектакле дә бик бәхетле язмышлы булып, Самарада Идел буе шәһәрләре театрлары фестивалендә җиңү яулый. «Туй» спектаклендә кәләш һәм Шекспир буенча куелган тамашада Джульетта ролен Әлмәт театрының яшь актрисасы, Минхановларның киленнәре Эльмира Яһудина башкара. Ә аның ире, Сәкинә ханым һәм Рамил Минхановларның олы уллары Айвар шул ук театрда ут көйләүче рәссам булып иҗат итә. Әмма бу – үзенә аерым мәхәббәт тарихы...

Минхановларның мәхәббәте һәм иҗаты турында бу язманы шушы урында тәмамларга да мөмкин булыр иде. Әмма алар моннан ике ел элек Әлмәт театрыннан Казанның К.Тинчурин театрына эшкә күчеп, татар сәнгать дөньясын тагын бер кат шаккатыра. Әлмәттә – кырык еллык иҗат, яраткан тамашачы, ярты сүздән аңлаучы коллегалар, онытылмас рольләр, даншөһрәт, Казанда исә аларны нәрсә көтә? Һәр театрның еллар буе калыплашкан үз коллективы бар. Анда Минхановларга урын табылырмы? Әмма ирле-хатынлы бу ике артистны бернәрсә дә куркытмый, чөнки Рамилнең – Сәкинәсе, Сәкинәнең Рамиле бар. Электән җиңел сөякле булдылар. Әлмәттән Казанга премьераларга, артистларның юбилей кичәләренә җилтерәтеп килеп җитәләр иде. Балалар үскән. Машинага утыралар да, юлга чыгалар, сөйләшеп, юлның озынлыгы сизелми дә кала. Җәйләрен исә һәр ел саен диярлек машина белән диңгез буена йөрделәр. Һәр шәһәрдә бишәр-алтышар көнгә тукталып, Кара диңгез буйларын аркылыга-буйга айкап чыгалар иде. Тамашачы исә кайда да бер. Тинчурин коллективы да артистларны җылы каршы алды. Рамил ике көндә - «Хыялый» спектакленә, дүрт көндә «Мәхәббәт баскычы»на кереп китте. Элек рольләрне айлар буе ятласа, хәзер әнә шулай берничә көн дә җитә. Күренекле актерлар Илгизәр Хәсәнов, Зөфәр Харисов, Нуретдин Нәҗмиевлар да бик булышты. Яңа ел уңаеннан сәхнәләштерелгән «Асылкош җыры» музыкаль спектаклендә Р.Минханов башкарган Дию әле дә күз алдында. Казанга күчкәч, күршеләрендә янгын чыгып, Минхановларның милкенә дә зыян килгән, шул вакыт Тинчурин коллективы Әлмәт артистларына бик ярдәм иткән. Сәкинә һәм Рамил Минхановлар театр директоры Фәнис Наил улы Мөсәгыйтовка һәм артистларга бик рәхмәтле.

Тормышны яңабаштан башлау мөмкин булса, актер һөнәрен сайлар идегезме, дим. Сәкинәм булса, һичшиксез, сайлар идем, дип җавап бирә Гаяз улы Рамил. Актриса иренә яратып бер күз сирпеп ала. Минхановларның мәхәббәт тарихы үзе сәхнәгә спектакль итеп куярлык түгелмени?!

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Айга карама кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

23 июль (шимбә). ***Зөлхиҗҗә аеның 24 нче көне. 24 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 23.24 сәгатьтә калка, 17.27 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.34 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Хлорның да файдасы бар

Хлорлы махсус матдәләр организмдагы артык майларны тарката. Хлор ашказаны согының төп өлеше булган тоз кислотасы ясалуда катнаша, су-тоз алмашын җайга сала, сөяк тукымасы барлыкка килүгә һәм аның үсүенә булыша. Бөерләрнең бәвелчә бүлеп чыгаруын контрольдә тота, җенес һәм үзәк нерв системаларының эшен җайга сала. Өлкән кеше организмына көненә 7 грамм хлор кирәк. Ул баклажан, чөгендер, редис, салат, помидор, яшел борчак, сыер һәм тавык ите, диңгез балыгы, сөт, кефир, сыр, солы һәм дөге ярмасы, хөрмә, йөзем, йомырка, тоз, икмәктә күп.

24 июль (якшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 25 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,23.49 сәгатьтә калка, 18.34 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.32 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күгән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы. Ай Игезәкләрдә чакта кан тамырларын чистарту яхшы нәтиҗә бирә. Соңгы фәнни тикшеренүләр күрсәткәнчә, баш авыртуы баш мие зарарланудан түгел, ә 90 процент очракта кан тамырлары авыруы аркасында килеп чыга. Йөрәк чирләренең сәбәбе исә – канда холестерин арту. Аның микъдарын киметү өчен, зәйтүн мае, кузгалак, яшелчә һәм җиләк-җимешне күбрәк кулланырга кирәк. Авырлык нормадан артмасын. Көн саен бер генә бүлем булса да сарымсак ашау инфаркттан да, яман шештән дә саклый.

25 июль (дүшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 26 нчы көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 19.02 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.28 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

26 июль (сишәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 27 нче көне.27 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 0.26 сәгатьтә калка, 19.28 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.24 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Бал иммунитетны ныгыта

Балда кеше каныдагы 24 элементның 22 се бар, шунлыктан ул организм өчен

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карап

иң файдалы ризыклардан берсе санала. Андагы фолий кислотасы һәм B, E,C,K,A витаминнары иммунитетны ныгыта, әмма флавоноидларның файдасы тагын да күбрәк – алар кергән вирусларны җиңә һәм, иммун системага ярдәм итеп, сихәтләнүне тизләтә. Салкын тиюдән саклану өчен, көненә берничә тапкыр бал кабып чәй эчү җитә. Иммунитетны әкренләп ныгыту өчен, баллы су эчәргә киңәш итәләр. 1 стакан салкынча чиста суга 1 чәй кашыгы бал салып болгатырга һәм иртәнге ашка чирек сәгать кала эчәргә кирәк. 30 процентлы бал эремәсе барлыкка килә, аның составы кан плазмасына бик охшаганга, файдалы компонентлары тизрәк һәм яхшырак үзләштерелә. Балга дарчин кушып ашау да иммунитетны ныгыта.

27 июль (чәршәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 28 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,1.17 сәгатьтә калка, 20.07 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.21 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

28 июль (пәнҗешәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 29 нчы көне. 29 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Арыслан йолдызлыгында, 2.22 сәгатьтә калка, 20.33 сәгатьтә бата. 20 сәгать 54 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 16.18 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый. Ай Арысланда чакта йөрәк-кан тамырлары системасы әгъзаларын саклау мөһим, аякны, нерв системасын дәвалау уңай нәтиҗә бирә, йөрәккә операция ясатырга ярамый. Парда пешерелгән ит һәм балык, яшелчә ашау файдалы.

29 июль (җомга). ***Зөлхиҗҗә аеның 30 нчы көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 3.36 сәгатьтә калка, 20.52 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.14 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

Кыяр маринадлау

Стерильләштерелгән банкаларга укроп чатыры, сарымсак салалар, юылган кыярларны тутыралар да, шаулап торган кайнар су коялар. 15 минуттан соң ул суны түгәләр, кыяр янына хуш исле борыч, канәфер һәм башка тәмләткечләр салалар да, 4 л суга 1 стакан шикәр, ярты стакан тоз, 1 стакан 9 процентлы серкә исәбеннән ясалган кайнар тозлык агызалар, тимер капкач белән ябып, банкаларның астынөскә әйләндереп куялар.

Җәмәгатьчелеккә, республика җитәкчеләренә дә аның исеме күптән таныш инде. Республиканың Аксакаллар шурасы рәисе Рәүф ага Ибраһимов үзенең 80 яшьлеген билгеләп үтте.

80 яшьлек аксакал

Аның тормыш юлы мавыктыргыч кыйссалар язарлык бай да түгел сыман. Ул 1942 елда Буа районының Тинчәле авылында, әнисе Рабиганың килендәше Галимәнең сәмәннән салынган өендә, салам түшәлгән идәндә дөньяга килә. Әтисе инде сугышка китеп барган, илдә ачлык кына түгел, күпләрне чир котырган, ә медицина ярдәме бөтенләе белән коргаксыган заман. Алты баладан өчесе генә исән-имин үсә. Җидееллык мәктәпне гел «бишле» билгеләренә генә тәмамласа да, район үзәгенә барып укырдай терәкләре булмый, Рәүфкә абыйсы Равил янына китеп, Караганда шахталарының берсендә хезмәт юлын башларга туры килә. Ләкин татарларда нәселдән нык күчкән – белемгә омтылыш атлы күркәм зәхмәт бар бит, Рәүф тә кичләрен тау техникумындагы курсларга йөри. Армия хезмәтенә чакырылгач та, шул «кеше булырга омтылыш» һаман тынгы бирми, кич буе кызыл почмакларда утырып китап актара-актара, Рәүф урта белем турында аттестат алып кайта. Әүвәл армиядән соң янә шахтага әйләнеп кайтса да, «энә белән кою казу» дигәннәре Рәүфне Казан университетының механика-математика факультетына китерә. Диплом алганнан соң Казанда калып, фәнни оешмаларда хезмәт куя башлый. Инде 38 яшенә җиткәндә язмыш аны Минтимер Шәймиев белән очраштыра, Рәүф ага Мелиорация министрлыгының автобазасында баш инженер булып эшли башлый. Шушында 40 яшьлек гаилә башлыгы, ниһаять, аерым фатирга да ия булуга ирешә.

Аннары «Тасма» ширкәтенең 2 номерлы цехында хезмәт кую. Ил белән бергә татар милләте дә уяна башлаган заман. Әле тегендә, әле монда җан тетрәткеч җыелышлар, митинглар уза, Татар иҗтимагый үзәге оеша. Җанында милли аң һәм азатлык чишмәсе булган һәрбер адәм баласына үз кыйблаңны сиздермичә һәм газиз халкың сафына кушылмыйча булмый. Рәүф әфәнде дә «Тасма» ширкәтендә республикага мөстәкыйльлек даулап, ике меңнән артык эшчедән имза җыя. «Балтыйк буендагы республикалар союздаш, ә Татарстан аларга караганда өч мәртәбә күбрәк продукция җитештерә, тик халкы гына Балтыйкнкыкыларга караганда өч мәртәбә хәерчерәк яши, без дә алар сафына басарга хокуклы!» – дигән шигарьләр дә язып, Мәскәүгә җибәрәләр.

1989 елның 15 октябрендә татар халкы Сөембикә манарасы янында тәүге тапкыр Хәтер көне уздыруга ирешә. 90 нчы елда, күренекле шәхесләребез башкаланың Ирек мәйданында ачлык игълан итеп утыра башлагач, кич саен халык җыелган митингларда Рәүф әфәнде микрофон тотып йөри. 1997 елда Казан Кремле янында табылган ханнарыбыз җәсәдләрен күчереп җирләү мәрәсимен оештыралар. Милләт җанлы ил агасы шулай чыныгу уза, шулай алгы сафка баса. 2002 елда ул инде Мөбәрәкҗан Мусин белән бергә республикада Аксакаллар шурасын оештыра башлый, аны Юстиция министрлыгында теркәтүгә ирешә, бераздан Рәүф аганы оешманың рәисе итеп сайлыйлар. 2005-2006 елларда Миргазиян хәзрәт белән бергә Казанның Декабристлар урамындагы җимерек котельный бинасы урынына яңа мәчет калкытып куялар. 2012 елда мәркәзнең «Архиерей дачасы»нда Алтык Бөртек истәлегенә 1297 елда куелган ике метрлы кабер ташын табып, аны Сөембикә манарасы янына китереп бастыралар. Искә алынган «Кабан шәһәрчеге»н кабат татар халкына кайтарып бирү, анда күмелгән күренекле татар шәхесләренең исемнәрен ачыклау, бакчаны тулысынча яңарту мәсьәләренә багышланган дистәләгән түгәрәк өстәл һәм конференцияләр үткәрүгә ирешәләр. Кабул ителгән карарларны искә алып, Президент аппаратыннан, Мәдәният министрлыгыннан бер кочак рәсми вәгъдә ява, тик... бармакны-бармакка сугып, берни эшләнми шул... Рәүф әфәнде әлеге хәлләр турында рус һәм татар газеталарына җан әрнеткеч дистәләгән мәкаләләр, хәттә «Казан ханнарының җәсәдләрен җирләү», «Ихласи Миргазиян», «Кабан шәһәрчеге» кебек сигез китап язарга да мәҗбүр була...

Әлбәттә, Рәүф әфәнденең медальләре дә, аңа бирелгән Рәхмәт хатлары да хәтсез. Ләкин аның өчен иң мөһиме – халык хакы, татар мәнфәгате.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.

Кроссворд



Сулдан уңга:

5. Йорт диварында яктылык керсен өчен пыяла куелган ачыклык, уем. 6. Чапкын ат. 8. Акча берәмлеге. 9. Йорт хайваны. 11. Әкиятләрдәге зур гәүдәле, көчле батыр образы. 12. Башкорт хатын-кызлары биюе. 15. “Ясин” 16. Дагыстанда яшәүче төрки халык. 17. Йон тукыма. 19. Күз кабаклары читендәге төкләр. 20. Әкрен генә ява торган (яңгыр).

Өстән аска:

1. Уку йорты. 2. Текст кисәге. 3. Дүртпочмаклап эшләнгән бүрәнә корылма. 4. Җылы баш киеме. 7. Нидерландия. 10. Татар халык бию такмагы. 11. Иске, тузган. 13. Шкафның аерым бүлекчәсе. 14. Чагыштырмача әкрен. 17. Сумның йөздән бер өлеше. 18. Улының яки кызының баласы.

Нияз БИШБАЛТА төзеде.

ЖАВАПЛАР

Сулдан уңга:

5. Тәрәзә 6. Тулпар 8. Крона 9. Кәҗә 11. Алып 12. “Бишбармак” 15. Сура 16. Авар 17. Трико 19. Керфек 20. Пыскак.

Өстән аска:

1. Мактап 2. Өзек 3. Бура 4. Башлык 7. Голландия 10. “Әпипә” 11. Алама 13. Шүрлек 14. Салмак 17. Тиен 18. Онык.

Гагаринны татарлар каршылаган

(Ахыры. Башы 27 нче санда).

1965 елның гыйнвар аенда, ниһаять, саратовлылар беренче космонавт белән очрашкан. 1945 елда ачылган Саратов индустриаль техникумының 20 еллык юбилее уңаеннан Юрий Алексеевич Саратовка килгән (1951-1955 елларда ул шушы техникумда белем алган). Шушы килүендә Ю.Гагарин истәлекле урыннарны тагын бер мәртәбә күреп кайтырга вакыт тапкан. Әнихәят һәм Ибраһим улына да Юрий Гагарин белән тагын бер тапкыр күрешергә насыйп булган.

● Румия Нурсканова ире һәм онысы белән.

Румия ханымның ире Амангали Кайрадин улы бу вакыйганы миңа болай бәян кылды: «Җитәкчеләр Әнихәят апага очрашу алдыннан чәй әзерләргә кушкан, табынга куярга дип, бар ризыкларны да алдан китергәннәр. Юрий Гагарин, Әнихәят Аким кызы һәм Ибраһим Ибраһим улы өстәл артына утырып, беразсөйләшеп тә алган. Аннары Гагарин Ибраһим абыйны якын итеп кочаклаган һәм аңа, Бөек Ватан сугышы ветеранына, рәхмәтләрен әйткән. Ибраһим абый каһарман кеше иде. Харьков, Ростов янындагы сугышларда катнашкан, өч тапкыр яраланган, әмма хәле бераз яхшыруга ук, янындагы табибләрнең дәвалауны дәвам итәргә кирәк дигән сүзләрен дә тыңламыйча, янә фронтка, алгы сызыкка киткән. Ә яралары җитди иде. Муенында, терсәгендә һәм уң тезендәге өч кыйпылчыкны үлгәнчегә хәтле йөртте».

– Амангали Кайрадинович, Ю.Гагарин Әнихәят ханымга да, Румиягә дә бүләкләр алып килгән бит...

– Әйе. Ул Әнихәят апага алсу төстәге мамык кофта бүләк иткән. Әмма мин ул кофтаны күрмәдем, киеп туздыргандыр. Ә миңа Румиягә Гагарин тарафыннан бүләк ителгән портфельне күрдем. Шундый ачык-кызгылт-көрән төстә, буеннан-буена замогы да бар иде. Румия аны 14 нче мәктәпкә бүләк итте. Бу яссы портфель укучы балага түгел, күбрәк укытучы өчен ятышлырак иде.

– Беренче космонавт Әнихәят ханымга, Румиягә атап барлыгы дүрт хат та язган икән...

– Әйе. Румия Ю.Гагаринның аларга үз кулы белән язган шул дүрт хатны, кайбер сувенирларны, автографлы китапларны, Гагарин бүләк иткән шул портфельне... һәммәсен 14 нче мәктәпкә васыять итеп бирде.

– Амангали Кайрадинович, әбит шул килүендә Гагаринның Румияне дә бик күрәсе килгән...

– Нәкъ шулай. Аны алырга мәктәпкә машина да җибәрелгән. Тик укытучы Румиягә очрашуга барырга рөхсәт итмәгән. Румиянең Гагаринны тагын бер күрәсе килгән, әлбәттә. Гагарин белән күрешә алмагач, Румия нык елаган...

Румия ханым хатирәләреннән беленгәнчә, әбисе бу вакыйгалардан соң озак гомер итмәгән: «Әбием 1968 елны дөнья куйды. Бу хакта әнием Юрий Гагаринга хәбәр итәргә теләде, аңа телеграмма сукты. Юрий Алексеевич әлеге телеграммага да җавап бирде. Үзенең очышка әзерләнүе, шул сәбәпле генә әбиемне җирләүдә катнаша алмавы, ләкин очыштан соң, мөмкинлек булу белән үк, һичшиксез, безгә кайтачагы турында язды. Ни кызганыч, шуннан соң күп тә үтмәде, шулкадәр авырлыклар аша әзерлек чорын үтеп, 27 яшендә космостан исән-сау әйләнеп кайта алган батыр нибары 34 яшендә үзе дә һәлак булды. Бу авыр хәбәрне кинәт ишеттем һәм бик кайгырдым, бик озак еладым. 1968 елны миңа 11 яшь иде инде. Ул чакта аны кызганып, бар халык елады. Илдә траур игълан иттеләр. Гагаринны хәзер дә искә алалар һәм сагынып елыйлар...»

Румия Әбдрәшит кызы ел саен Саратовка барып, анда җыелган халык алдында да чыгышлар ясаган. Ул Ю.Гагаринның космоска очуына 50 ел тулу уңаеннан медаль белән дә бүләкләнгән.

«Гагаринны кешелек тарихында иң истә калачак каһарман дип саныйм. Аның каһарманлыгы турындагы тарих гасырлардан гасырларга күчә барачак! – дигән Румия ханым үз хатирәләрендә. – Кечкенә чакта миңа үсеп җитеп, гаиләле булам да, ир бала табам һәм аңа Юра дип исем кушам дип хыялландым. Беренче балабыз, кыз бала тугач, аңа Оксана дип исем куштык. Әмма үз-үземә сүз бирдем: ир бала туганчы табачакмын һәм улыбызга Юра дип исем кушачакмын. Улыбыз тугач, аңа Юрий дигән исем кушарга теләдем. Тик шулай килеп чыкты ки, без улыбызга Виталий дип исем куштык.

Кызымның улы – беренче оныгым тугач та, аңа Юра дип исем бирерләр дип өметләндем. Кызым белән киявем улыбыз Рәсим исемле була диде».

Амангали Кайрадинович бу нисбәттән болай ди: «Улыбызга Юрий исеме кушкан да булыр идек. Тик нигәдер берара космос темасы ерактарак калды. Улыбызга батырларча һәлак булган Гражданнар сугышы каһарманы Виталий Бонивур хөрмәтенә Виталий исемен куштык. Ә оныгыбыз «көчле» дигән мәгънәгә ия булган мөселманча Рәсим исемле булды!»

«Һәр язны, Космонавтика көненә багышлап, гаиләбез белән бергәләп җиргә бәрәңге утыртабыз. 1961 елны ук әнием: «12 апрель көне – олуг бәйрәм!» – дигән иде. Ә әбием Әнихәят: «Мин һәр ел саен 12 апрель көнне, хәтта кар яуса да, бәрәңге утыртачакмын. Хатирәләребез хакына», – дип белдерде. Бу – гаиләбездәге бер күркәм традициябез. 12 апрель көнне без бәрәңге утыртабыз, аннары күккә карап алабыз. Бәрәңге утыртып бетергәч, бәйрәм өстәле янына җыелабыз. Мин бер елны, әтием үлгән елны гына Космонавтика көнен бәйрәм итмәдем, – дигән үз әңгәмәләрендә Румия Әбдрәшит кызы. – 2018 елны гаиләбез бик ишәйде. Якын туганым үлгәч, ирем белән аның берсеннән-берсе кечкенә алты баласын тәрбиягә алдык. Лаеклы ялда идек инде, тик бу карарны бер дә авырсынмыйча кабул иттек. Аларның иң олысына – унбер, ә иң кечесенә нибары ике яшь ярым иде.

....Билгеле, Коръән сүрәаятьләре язылган язмалар – иң түрдә! Диварда шулай ук Гагарин портреты да эленеп тора. Гомумән, космонавтның башка портретлары да бар безнең диварларда. Гагарин портретларын, аңа багышланган әйберләрне гомерем буе җыям. Беренче портретын мәктәптә укыган чакта ук алган идем. Мин балаларымны да, оныкларымны да Ю.Гагарин хакында еш сөйләп, аның якты мисалында тәрбияләп үстердем. Оныгыбыз Рәсим дә кечкенәдән үк Ю.Гагарин хакында яхшы итеп чыгышлар ясады. Уллыкка, кызлыкка алган балаларыбыз да Гагарин турында яхшы беләә, сөйләгәннәремне дә кат-кат тыңлыйлар».

2021 елның җәендә миңа Әстерхандагы милләттәшебез Хәсән Кутлалиев белән дә сөйләшеп алырга мөмкин булды. Хәсән Туктар улы – озак еллар үткәч, Румия ханымны беренче булып эзләп тапкан шәхес.

Шушы көннәрдә генә хөрмәтле Амангали Кайрадин улы белән янә хәбәрләшеп, интернет киңлекләрендә тапкан фотосурәт тарихы хакында сорадым. Бу фотода Румия ханым онысы Рәсим белән япон журналистлары янәшәсендә төшкән. Амангали ага бу нисбәттән болай диде: «Әлеге фотосурәт 2015 елны төшерелгән булырга тиеш, чөнки Рәсим әлеге көнне бик яхшы хәтерли. Япониярләр үз телевидениеләре өчен Халыкара Космонавтика көненә багышланган документаль фильм төшерергә килгән булган һәм Ю.Гагарин Җиргә әйләнеп төшкән урыннарны күреп, шуннан китеп барышлый, Румия һәм оныгыбыз Рәсим белән бергәләп истәлек өчен фотосурәткә дә төшкәннәр.

Румиянең әтисе Әбдрәшит Мәхмүд улы «Водрем 400» тимер юл оешмасында поездларны су белән тәэмин итү буенча слесарь булып эшләде. (Саратовтагы Идел буе тимер юллары идарәсе каршындагы фонтан аның куллары белән эшләнгән). Әнисе Агильшира да шул ук оешманың инструментлар һәм материаллар складына мөдире иде.

Румия яштән югары кан басымы белән авырды, бу чир аларның нәселендә бар. Дәвалану өчен Әстерхан хастаханәсенә дә бардык, ләкин савыга гына алмады, барыбер шушы авырудан китеп барды... Без 1973 елны гаилә кордык. Мин Энгельс индустриаль-педагогика техникумында белем алдым, укуымны армиядән соң тәмамладым. 1971 елны Румия безнең студентлар ашханәсендә аш-су остасына укыды, берара Энгельс телефон станциясендә телефонист булып та эшләп алды. Әти-әнием Харабали шәһәрендә гомер итә иде, без дә шунда яшәдек. Мин андагы һөнәри техник училищесында производствога өйрәтү мастеры булып хезмәт куйдым, ә Румия – почтада. Бер кыз, бер ул үстердек. Улыбыз инде күптән вафат. Мин КПСС эшенә күчеп, Саратовта, Югары партия мәктәбендә укыдым. Румия исә микробиолог курсларын тәмамлады, сөт-май житештерү заводында сөт ризыклары сыйфаты буенча лаборант булып эшләде. Ә инде авыл хуҗалыгы тармагы мөшкелләнгәч, сәүдә өлкәсен сайлады... Космонавтика көне уңаеннан аны гел төрле чараларга чакыралар, ә ул бер дә авырсынмыйча бара, чыгышлар ясый иде.

Без хәзер дә Румиянең бертуган сеңлесе Нуриянең дүрт кызын һәм ике улын үстерәбез. Аларның берсе – Ваня, Румия тырышлыгы белән, Әстерхан өлкәсенең атаман И.Бирюков исемендәге кадет корпусының 5 нче взводында укый. Ваня янына барып, аның хәлен белеп торам. Кызым һәм оныгым – минем янда. Оныгыбыз Рәсим химик булачак, ул Әстерхан дәүләт университетының I курсын тәмамлады. Билгеле, Румияне барыбыз да сагынабыз».

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

● Румия Нурсканова японнар белән.

Яшьтән белеп була

Голландия тикшеренүчеләре Альцгеймер авыруы башлану ихтималын яшь чактан ук белеп була, дигән фикергә килгән. Ә алданрак беләсең икән, әлеге мәкерле чиргә каршы тору чараларын да мөмкин кадәр иртәрәк кулланып була. Альцгеймер авыруы бүген деменциянең (картлар акыл зәгыйфьлегенең) иң киң таралган формасы санала. Россиядә 65 яшьтән өлкәнрәкләр арасында 2,4 миллион кеше әлеге чирдән интегә. Вәзгыять елдан-ел начарлана бара, ул хәттә алга киткән илләрнең сәламәтлек саклау системалары өчен дә куркыныч тудыра. Әйтик, АКШ та бу төзәлмәс чиргә турыдан-туры кагылышлы чыгымнар елына 203 миллиард доллар тәшкил итә, 2050 елга исә триллион доллардан артачак, дип фаразлана. Бердәнбер өмет – галимнәрдә, алар якын киләчәктә нәтиҗәле дару уйлап табып, акыл зәгыйфьлегенең ничек тә соңрак башлануына ирешсә генә. Әмма мондый чара табылмый әле. Ә менә аны диагностикалауда алга китеш бар. Нидерландның Лейден шәһәрендә галимнәр махсус биомаркер ачкан, аның буенча 20-30 яшьлек кешеләрдә киләчәктә Альцгеймер авыруы башлану ихтималын ачыклап була. Лейдендагы Janssen иммунология бүлекчәсе башлыгы Сесиль Спиртс әйтүенчә, бүген медицина эшләнмәләренең күбесе авыруны дәвалауга түгел, бәлки аны кисәтүгә юнәлтелә. Шунлыктан биомаркерларның роле бик мөһим. Голландиядә ачылган биомаркер Альцгеймер авыруын күзнең челтәр катламындагы үзгәрешләр буенча ачыклау мөмкинлеге бирә. Әлегә бу методика сынаулар үтә. Картлык деменциясе һәр өченче кешегә яный. Тик кайберәүләрдә ул 60 яшьтә үк, ә кайберәүләрдә – күпкә соңрак башланачак. Канада галимнәре дә авыруның башлану вакытын чигерү юлларын эзли. Моннан 10 ел элек башланган тикшеренүдә 3 меңләп кеше катнаша, аларның баш миен төрлечә сыныйлар. Кайбер илләрдә, картларның хәтере начарлануны кисәтү максатларында, аларга чит тел өйрәтү курслары оештырыла. Акыл эшчәнлеге белән шөгыльләнүчеләр һәм хәтта кроссворд чишәргә яратучылар да когнитив тайпылышлардан сирәгрәк интегә. Күп хәрәкәтләнергә яратучыларның хәтере исә бигрәк тә яхшы – көненә 3 чакрымнан артыграк йөрүчеләрдә деменция 500 метр гына йөрүчеләр белән чагыштырганда ике тапкырга сирәгрәк күзәтелә.

(“Daily Mail”).

Кәстәнә белән миләш

Халыкара табигатьне саклау фонды төрле чирләрдән һәм корткычлардан зыян күргән кәстәнә (каштан) һәм миләшне Европаның бөтенләй юкка чыгу куркынычы янаган агачлары исемлегенә керткән. Әлеге Кызыл исемлектә хәзер 400ләп үсемлек исәпләнә. Фондның кураторы Крейг Хилтон-Тейлор вәзгыятьне бик аянычка саный, чөнки Җирдә агачлар булмаса, тормыш та тукталачак. Агачлар фаунаның күп төрләре өчен азык чыганагы һәм яшәү урыны булып тора бит. Халыкара табигатьне саклау фондының соңгы хисабыннан күренгәнчә, Европада барлыгы 454 төр агач үсә, шулардан 42 проценты-на, ә бары тик биредә генә үсә торган агачларның 58 процентына юкка чыгу куркынычы яный. Куаклыкларның да яртысы якын арада үлеп бетәргә мөмкин, шунлыктан кичекмәстән яшел дусларны коткару чараларын күрү мәҗбүри.

(“BBC”).

Файдалы кофеин

Америка галимнәре, тикшеренү үткәргәннән соң, кофеин кеше гомерен озынайта, дигән нәтиҗәгә килгән. Леланд Стэнфорд исемендәге университет галимнәре каһвә һәм чәйнең сәламәтлеккә файдасын дәлилләгән. Әлеге эчемлекләрдә кешенең гомер озынлыгына йогынты ясый торган матдәләр бар икән. Моннан тыш, шоколад та шундый үзлеккә ия, чөнки аның составында теобромин дигән файдалы алкалоид бар. Экспертлар аңлатуынча, тормыш һәм сәламәтлек сыйфатына кандагы зарарлы химик элементлар микъдары йогынты ясый. Кофеин исә нәкъ менә шуларның санын һәм активлыгын киметә. Ул кан тамырларында тромблар барлыкка килүдән дә саклый. Белгечләр әйтүенчә, каһвә яратучыларда тромб барлыкка килү ихтималы бу эчемлекне бөтенләй эчмәүчеләр белән чагыштырганда күпкә азрак. Нәтиҗәнең очраклы булмавын дәлилләү өчен, галимнәр әлеге өлкәдә тикшеренүләрен дәвам итәчәк.

(“The New York Times”).

● Wilkinson Sword компаниясе җитәкчелеге Букингем сараена тапшырганчы кылычны карый.

Сталинград кылычы

Совет халкының Сталинград сугышындагы җиңүе хөрмәтенә Бөекбритания короле Георг VI фәрманы буенча коелган кылычны Черчилль Сталинга бүләк иткән. 200 тәүлеккә сузылган Сталинград сугышында Германия 32 дивизиясен һәм 3 бригадасын югалта, Идел буе далаларында барлыгы 1,5 миллионга якын фашист, 650 мең совет солдаты һәм офицеры һәлак була. “Сталинград кыюлык һәм ныклык үрнәгенә, шул ук вакытта искиткеч фаҗига символына әйләнде, әлеге символ гасырлар буе сакланачак”, – ди Британия премьер-министры Уинстон Черчилль. Король гаиләсе дә шундый ук соклану хисләре кичерә. Королева Елизавета 1943 елда калаты торгызуда катнашу өчен акча җыя башлый. Англиядән Сталинградка алты госпиталь, азык-төлек, җылы кием-салым китерелә, королева җыйган акчага тулы бер хастаханә җиһазландырыла һәм дарулар белән тәэмин ителә. Әмма король Георг VI хатыны һәм кызлары белән шәһәр халкына шәхсән үзләреннән бүләк ясарга карар кыла, зиннәтле кылыч идеясен олы кызлары, ул чакта принцесса (хәзерге королева Елизавета II) тәкъдим итә. Алтын, көмеш, рубин һәм данлыклы Шеффилд корычыннан озынлыгы 122 сантиметрлы затлы кылычны атаклы Wilkinson Sword корал компаниясендә өч ай буе коялар, эш барышын тугыз эксперт күзәтеп тора. Аның йөзенә инглиз һәм рус телләрендә : “Корыч кебек нык Сталинград халкына Англия короле Георг VI һәм британиялеләрдән ихтирам билгесе”, - дип языла. Әлеге кылыч хәзерге заман корал сәнгате җәүһәрләреннән берсе санала. Бүләк тапшыру мәрасиме 1943 елның 29 ноябрендә Тәһранда Гитлерга каршы коалиция илләре җитәкчеләре - “зур өчлек” очрашуында тантаналы шартларда була. Кылычны тапшыргач, Черчилль, Сталин һәм Рузвельт, террасага чыгып, бергәләп бөтен дөньяга мәгълүм тарихи фотога төшә. Әлеге кыйммәтле экспонат хәзер Сталинград сугышы музей-панорамасында саклана.

(“Livejournal.com”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

25 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 12+
10.00, 23.20 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.30 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Ком сәгате». 12+
14.00 «Ландшафтный дизайн - это просто». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Реальная экономика». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 Спектакль «Артист». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Ихсан күңел». Илсөяр Иксанова турында телеочерк. 6+
15.30 «Ватандашлар». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.20, 21.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Трудовой фронт Великой Отечественной». 12+
16.15 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.20 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.35, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ОТЧИМ». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20, 23.40 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
22.40 «Мариуполь». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Кавказ для русской короны».
7.30 «Истории в фарфоре».
8.00 Легенды мирового кино.
8.25 «СЛОМАННЫЕ ПОБЕГИ, ИЛИ КИТАЕЦ И ДЕВУШКА».
10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Гавриил Барановский. Здание Русского географического общества.
10.45 Academia. Сергей Иванов. «Юродство с точки зрения истории культуры».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 Линия жизни. Ирина Мирошниченко.
13.10 «НЕ СОШЛИСЬ ХАРАКТЕРАМИ».
14.30, 22.40 «Франция. Замок Шенонсо».
15.05 Ансамбли. Дуэт. Мария Гулегина и А.Гиндин.
16.00 «Черный квадрат. Поиски Малевича».
16.45 Спектакли-легенды. Ю.Яковлев, Н.Гриценко, Л.Максакова, А.Казанская в постановке А.Ремизовой «На всякого мудреца довольно простоты».
19.45 Письма из провинции.
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 «Библейский сюжет».
21.00 «ПЛОХОЙ ХОРОШИЙ ЧЕЛОВЕК».
23.30 «Энрико Карузо. Запретные воспоминания».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ВОКАЛЬНО-КРИМИНАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ». 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Сишәмбе

26 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 12+
10.00, 23.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Без химии». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Илтани Илялова турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Трудовой фронт Великой Отечественной». 12+
16.15 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.20 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.35, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ОТЧИМ». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «СОФИЯ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Некоронованный император».
7.30 «Истории в фарфоре».
8.00 Легенды мирового кино.
8.30 «ИНТЕРМЕЦЦО».
10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Аполлон Щедрин. Здание Двенадцати коллегий.
10.45 Academia. Сергей Иванов. «Юродство с точки зрения истории культуры».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 «Энрико Карузо. Запретные воспоминания».
13.15 «ПЛОХОЙ ХОРОШИЙ ЧЕЛОВЕК».
14.50 Цвет времени. Жан Этьен Лиотар. «Прекрасная шоколадница».
15.05 Ансамбли. Дуэт. Никита Борисоглебский и Борис Березовский.
16.35 «Климт и Шиле. Слишком много таланта».
17.20 Спектакли-легенды. И.Кваша, В.Гафт, О.Табаков, А.Мягков, А.Вокач в постановке Г.Товстоногова «Балалайкин и Ко».
19.45 Письма из провинции.
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 «Н.Парфенов. Его знали только в лицо...»
21.15 «МЫ, НИЖЕПОДПИСАВШИЕСЯ».
22.25 «Черный квадрат. Поиски Малевича».
23.30 «Неразрешимые противоречия Марио Ланца».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ВОКАЛЬНО-КРИМИНАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ». 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+
0.00 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

27 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 12+
10.00, 23.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Жизненно важно». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Без химии». 12+
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Клара Хәйретдинова турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Трудовой фронт Великой Отечественной». 12+
16.30 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.20 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.35, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ОТЧИМ». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «СОФИЯ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Последняя Великая княгиня».
7.30 «Истории в фарфоре».
8.00 Легенды мирового кино.
8.25 «БОЛЬШИЕ ДЕРЕВЬЯ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Карл Росси. Сенат и Синод.
10.45 Academia. Сигурд Шмидт. «История государства Российского» Н.М. Карамзина».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 «Неразрешимые противоречия Марио Ланца».
13.15, 21.15 «МЫ, НИЖЕПОДПИСАВШИЕСЯ».
14.30 «Тунис. Дворец Эссаада».
15.05 Ансамбли. Трио. Вадим Репин, А.Князев и А.Коробейников.
16.00 «Эффект Айвазовского».
16.40 Дороги старых мастеров. «Вологодские мотивы».
16.50 Спектакли-легенды. Б.Фрейндлих, Ю.Толубеев, Н.Максимова в постановке А.Музиля «Сказки старого Арбата».
19.45 Письма из провинции.
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 Острова. Леонид Куравлев.
22.30 «Климт и Шиле. Слишком много таланта».
23.30 «Скучная жизнь Марио Дель Монако».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ВОКАЛЬНО-КРИМИНАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ». 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Пәнҗешәмбе

28 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 12+
10.00, 23.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.00, 0.40 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Мин кайтырмын сезгә яңадан». Фәнис Яруллин турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+

10.30, 21.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Трудовой фронт Великой Отечественной». 12+
16.15 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.20 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.35, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ОТЧИМ». 16+
23.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «СОФИЯ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Праздник на краю пропасти».
7.30 «Истории в фарфоре».
8.00 Легенды мирового кино.
8.25 «ДОРОГА НА БАЛИ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий А.Резанов. Владимирский дворец.
10.45 Academia. Сигурд Шмидт. «История государства Российского» Н.М. Карамзина».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 «Скучная жизнь Марио Дель Монако».
13.15 «МЫ, НИЖЕПОДПИСАВШИЕСЯ».
14.30 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
15.05 Ансамбли. Квартет имени Давида Ойстраха.
15.55 200 лет со дня рождения Аполлона Григорьева. Театральный архив.
16.30 Спектакли-легенды. Е.Карельских, Л.Максакова, А.Казанская, М.Вертинская, В.Шалевич в постановке А.Ремизовой «Идиот».
19.45 Письма из провинции.
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 85 лет со дня рождения Виктора Мережко. Линия жизни.
21.25 «ЗДРАВСТВУЙ И ПРОЩАЙ».
23.00 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».
23.30 «Зураб Соткилава. Божьей милостью певец».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ВОКАЛЬНО-КРИМИНАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ». 16+
21.45 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Җомга

29 июль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классная работа». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00 «Без химии». 12+
21.00 «Юлчы». 6+
23.00 «НЕАДЕКВАТНЫЕ ЛЮДИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Роберт Миңнуллин турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05 «Нечкә билле Зиләйлүкнең җырлары». Зилә Сөнгатуллина турында телеочерк. 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «САМЫЙ ЛУЧШИЙ». 16+
14.45 «Наша марка 2». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Трудовой фронт Великой Отечественной». 12+
16.15 «Три кота».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
21.00 «ВЕРЬ МНЕ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.20 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.35, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Большой юбилейный концерт Григория Лепса. 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЛЕГЕНДА №17». 6+
23.50 «ТРЕНЕР». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Портрет на аверсе».
7.30 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
8.00 Легенды мирового кино.
8.25, 23.50 «ДАВИД И ГОЛИАФ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Жан-Франсуа Тома де Томон. Дом Лаваля.
10.45 Academia. А.Ужанков. «Герой нашего времени».
11.35 Искусственный отбор.
12.15 «Забытое ремесло».
12.30 «Зураб Соткилава. Божьей милостью певец».
13.25 «ЗДРАВСТВУЙ И ПРОЩАЙ».
15.05 Ансамбли. Квинтет. Элисо Вирсаладзе и Квартет имени Давида Ойстраха.
15.40 «Главные слова Бориса Эйфмана».
17.05 Спектакли-легенды. Н.Архипова, Т.Пельтцер, Г.Менглет в постановке М.Захарова и А.Ширвиндта «Проснись и пой!»
18.45 XXX Музыкальный фестиваль «Звезды белых ночей».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 «Молодинская битва. Забытый подвиг».
21.00 «КВАРТЕТ ГВАРНЕРИ».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «ВОКАЛЬНО-КРИМИНАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ». 16+
21.45 «ПРИГОВОРЕННЫЙ». 12+
23.20 «Чайф 35+». Юбилейный концерт. 6+

Шимбә

30 июль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Кул Шариф. Возрождение». 6+
14.30 «Союзники ОДКБ - 30 лет на страже коллективной безопасности». 12+
15.40 Творческий вечер композитора Эльмира Низамова. 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Соотечественники». 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Ватандашлар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «СЛОН И БАБОЧКА». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Шагыйрьләрдән дә шагыйрьрәк». Айрат Арсланов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Спектакль «Шулай булды шул». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Ватандашлар». 6+
20.30 «Халкыбыз мирасы - Народное наследие». Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. 6+
22.45 Спектакль «Урланган бәхет». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30 «Вместе по России». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Спасите, я не умею готовить!» 12+
8.45 «ПОХИЩЕНИЕ ЕВЫ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЕСЛИ БЫ ДА КАБЫ…». 12+
14.45 «Наша марка 2». 12+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «ВЕЧНЫЙ ОТПУСК». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «СПИТАК». 16+
22.45 «СВЕТ И ТЕНЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 «Высоцкий. «Где-то в чужой незнакомой ночи...» 16+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
14.05, 15.15 «Крещение Руси». 12+
18.20 Ко дню рождения Эдиты Пьехи. «Я отпустила свое счастье». 12+
19.20 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «НЕ ЖДАЛИ». 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «ЧЁРНОЕ МОРЕ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «РЫЖИК». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.10 «СЧАСТЛИВЫЙ РЕЙС».
9.25 «Обыкновенный концерт».
9.50 «Передвижники. Архип Куинджи».
10.20 «КВАРТЕТ ГВАРНЕРИ».
12.45 Черные дыры. Белые пятна.
13.30 Диалоги о животных.
14.15 «Марис Лиепа... Я хочу танцевать сто лет».
14.55 Легендарные спектакли Большого. М.Лиепа, В.Васильев, Е.Максимова в балете «Спартак».
17.15 «Энциклопедия загадок».
17.45 «Песня не прощается... 1978 год».
19.05 Искатели. «Клады озера Кабан».
19.50 К 100-летию российского джаза. Линия жизни. Давид Голощекин.
20.45 «СЕРДЦЕ НЕ КАМЕНЬ».
23.00 Спектакль «Вертинский. Русский Пьеро».
23.55 «К ЧЕРНОМУ МОРЮ».

«НТВ»

4.50 «ДЕЛЬТА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.30 «ВОКАЛЬНО-КРИМИНАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ». 16+
22.15 «Маска». 12+

Якшәмбе

31 июль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 Илсөя Бәдретдинова концерты. 6+
8.10 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина җырлый. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Элэктегезме?» «Мунча ташы» спектакле. 12+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Батырлар». 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «СКРЮЧЕННЫЙ ДОМИШКО». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Харис Нигъмәтҗанов турында телеочерк. 6+
7.00 «Олы юл әйтте...» циклыннан «Борчылма...» Айдар Фәйзрахманов җырларыннан концерт. 6+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Роберт Миңнуллин турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Мәхәббәтле күзләрем». Роберт Миңнуллинның юбилей кичәсе. 12+
15.25 Спектакль «Ташкын». 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 Эльмира Кәлимуллина концерты. 6+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30 «Вместе по России». 12+
6.30 «Не факт». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Инвиво». 12+
8.30 «ВЕЧНЫЙ ОТПУСК». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «Спитак». 16+
14.45 «Наша марка 2». 12+
15.00 «Удиви меня». 12+
15.45 «ПОХИЩЕНИЕ ЕВЫ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЕСЛИ БЫ ДА КАБЫ…». 12+
23.00 «САМЫЙ ЖЕСТОКИЙ ГОД». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.10, 6.10 «КОМАНДИР СЧАСТЛИВОЙ «ЩУКИ». 12+
6.00, 10.00, 12.15, 15.00, 18.00 Новости.
7.00, 10.10 «День Военно-морского флота РФ».
11.00 Торжественный парад ко Дню Военно-морского флота РФ.
12.30 «Цари океанов. Путь в Арктику». 12+
13.35, 15.15, 18.20 «АНДРЕЕВСКИЙ ФЛАГ». 16+
21.00 «Время».
22.35 «ТОРПЕДОНОСЦЫ». 12+

«РОССИЯ»

5.35 «ОЖЕРЕЛЬЕ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
9.10 «Сто к одному».
10.00, 12.15, 17.00, 20.00 Вести.
11.00 Торжественный парад ко Дню Военно-морского флота РФ.
12.45 «ЧЁРНОЕ МОРЕ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Энциклопедия загадок».
7.00 Мультфильмы.
7.50 «СЕРДЦЕ НЕ КАМЕНЬ».
10.10 «Обыкновенный концерт».
10.40 «К ЧЕРНОМУ МОРЮ».
11.50 Острова. Анатолий Кузнецов.
12.35 Диалоги о животных.
13.15 «Коллекция».
13.45 «Весёлые ребята». Мы будем петь и смеяться, как дети!»
14.25 «ВЕСЕЛЫЕ РЕБЯТА».
15.55 «Поет Эдита Пьеха».
17.10 «Космические спасатели».
17.50 «Пешком...»
18.20 «Русские в океане. Адмирал Лазарев».
19.05 «Романтика романса».
20.00 «БЕЛОРУССКИЙ ВОКЗАЛ».
21.40 Большая опера- 2016.
23.25 «ДОРОГА НА БАЛИ».

«НТВ»

4.50 «ДЕЛЬТА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.45 «ВОКАЛЬНО-КРИМИНАЛЬНЫЙ АНСАМБЛЬ». 16+
22.25 «Маска». 12+

Ашыгыч ярдәм хезмәтенә Мөслим районы үзәгенең Гагарин һәм Октябрь урамнары чатында яшь егет ятуы турында хәбәр салкын 27 февраль төнендә килә. Табибләр сәгать 2 тулганда килеп җитәләр дә шунда ук эчке эшләр бүлегенә шалтыраталар. Чөнки карлы-бозлы юл читендә яткан кешенең җансыз икәне шик уятмый, өстенә капланган куртканы алгач, күкрәкнең сул ягындагы җәрәхәт, тирә-юньдә кан таплары күренә. Димәк, санаулы минутлар эчендә килеп җиткән җинаятьчеләрне эзләү бүлеге җитәкчесе Б.Җамалиевка адәм баласының чәнчеп үтерелүе көн кебек ачык була. Кесәсендәге документлар буенча мәрхүмнең Рус Шуганы авылыннан 1996 елгы Андрей Фролов икәне беленә.

Хәмер йөгәнсезли хисләрне

Үтерүчене табып богаулау өчен, оперативникларга ярты сәгать вакыт җитә. Алар Октябрь урамы буйлап хәвефле урынга кадәр килеп кире киткән көпчәк эзләрен шәйлиләр. Машина тәгәрмәче түгел, ә тар арба эзләре була бу. Озаклап Мөслим урамнарын буйлап йөрергә туры килми, эзләр шул тирәдәге капка төбенә алып килә, ишегалдында чүп-чар ташый торган арба күренә, урта яшьләрдәге ир-ат формалы кешеләргә үзе үк каршы чыга, шунда ук көнләшү сәбәпле Фроловны үтерүен дә әйтеп бирә. 1980 елгы Веталий Сәлимов эчке эшләр бүлегенә озатыла.

Хәзерге заманда моның ише вәхшилекләрне, башлыча, тормыш төбендәге өметсез затлар кыла. Бу яктан әлеге очрак үзенчәлекле, чөнки В.Сәлимов моңа кадәр хөкемгә һәм административ тәртиптә җавапка тартылган кеше түгел, участок инспекторы һәм җирле хакимият тарафыннан уңай бәяләнә, наркология һәм психиатрия табибләрендә исәпкә дә тормый. Мәктәптә 9 нчы сыйныфны тәмамлаганнан соң райондагы көллияттә укып тракторчы-машинист һөнәре алган, соңгы елларда җирле сөт комбинатында эшләгән ир-атны язылышмыйча гына тугыз ел бергә яшәгән Рәзинә дә (исеме үзгәртелә) яманламый, шулай да әлеге хәлләрдән соң биргән күрсәтмәсендә башка оешмага урнашу нияте белән эшеннән киткәч күп эчә башлавын, ягъни шул зәхмәткә хирыслыгын яшерми.

Хатын-кыз үзе бер ширкәттә менеджер булып хезмәт итә. Шунда ук йөк төяүче Андрей Фролов та эшләгән. Егет әтиәнисе, абыйсы белән яшәгән, Рус Шуганына кайтып-килеп йөргән, әнисенең әйтүенчә, сирәк-мирәк Мөслимдә кунып калган чаклары да булган. 26 февральдә такси яллап эшкә китә, көндез әнисенә шалтыратып, мунча ягып куярга кушкан, ләкин өенә кайтмый ул, кичке сәгать 9 лар тирәсендә әтисе шалтыраткач та, эштә «фура» бушатам дип алдаган. Иртән иртүк Мөслимдә яшәүче туганнардан хәвефле хәбәр алына. Бичара ата-ана барып җиткәндә дә, уллары урам чатында яткан була әле.

Әлбәттә, алар үз балалары турында начар сөйләми, аның хөкемгә тартылганы булуын да әйтмиләр, ләкин эчәргә яратуын телгә алалар. Салмыш вакытларында әти-әнисе әрләмәсен өчен, аларда кунарга калуын Рәзинә белән Веталий да әйтеп тора. 26 февральдә дә ирле-хатынлыларның рөхсәтен алып, кичке сәгать 8 нчедә килеп керә ул. Кунак килгәч хәмерсез генә булмый, әйтүләренчә, ирләр аракы, хатын-кыз сыра эчә. Кичке сәгать 11 ләрдә хуҗабикә йокы бүлмәсенә кереп, телефонына төртелеп утыра, күп тә үтми, иренең: «Походу я его убил», - дип кычкырганын ишетеп атылып чыга, кулына зур гына агач саплы пычак тоткан Веталийны, йокы бүлмәсе бусагасы төбендә чалкан яткан кунакны күрә. Егетнең хәле ул вакытта ук өметсез була, чынлыкта, бер мизгел эчендә җан бирә ул, соңрак мәгълүм булганча, пычак йөрәк һәм үпкәгә эләгә.

Бу хәл өйдәгеләрне тетрәндерә, әлбәттә. Ни эшләргә белмичә ике сәгать чамасы мәет янында була алар, күрәсең, куркудан тиешле хезмәтләргә дә хәбәр салмыйлар. Ниһаять, ир кеше сарайдагы бакча арбасын алып килә, икәүләп мәетне шуңа салгач, Веталий урамга чыга һәм сырхауханә ягына китә. Гаҗәп, ләкин күрсәтмәләрендә үлгән кешене «ашыгыч ярдәм»гә илтергә теләдем, исерек булганга хәлсезләндем һәм ташлап калдырып кире кайттым да, Рәзинә өйне жыештыргач, йокларга яттык, ди ул.

В.Сәлимов шул көнне үк «явка с повинной» дигән тәүбәле беркетмә яза, барысын да җентекләп сөйләп, озын-озын күрсәтмәләр бирә, җинаять урынында статист Б.Җамалиев ярдәмендә телдән әйткәннәрне раслап күрсәтеп тә йөри. Кыскача гына әйткәндә, кухняда икесе генә калып сыйланып утырганда, Андрей холыксызланып дорфа кылана башлый, кунак икәнен искәртеп тәртипкә чакыргач, син үзең дә кунак кына дип, хуҗаның ошбу өйдә пропискада түгел икәненә ишарәли, нәтиҗәдә, коридорга чыгып этешә-төртешергә керешкәч, Сәлимов кухнядан пычак алып чыгып Андрейның йөрәгенә чәнчеп ала. Кунак хатыным бүлмәсенә керергә җыена дип уйладым, ачуланышкан чакта, Рәзинәнең Фролов белән тора башлыйм дип куркытулары исемә төште, дип төп сәбәпне көнләшүгә кайтарып калдыра ул. Нәкъ бер айдан соң Андрей хатыным белән «йоклап» йөрүен әйтте дип күрсәтмәләренә өстәмә дә кертә. Моның кебек акланулар күргән-белгәннәр арасында имеш-мимеш, гайбәт чыгарудан башкага ярамый, ягъни гаепләнүченең гаебен һәм җәзаны йомшартучы шарт булып хезмәт итә алмый, гадәттә.

Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Данияр Мөхәммәдиев көнче үтерүчегә аңлы рәвештә кешегә үлем китерү дигән гаепләү белдерә һәм июнь ае башында җинаять эше Мөслим район суды каравына тапшырылды. В.Сәлимов күрше Минзәләдәге тикшерү изоляторында утыра.

Шул ук районда яшәүче 40 яшьлек Ренат Габдуллинның да хәлләре мөшкел. Җенси рәвештәге ике җинаять эшләүдә гаепләнә ул. Теманың четереклелеген искә алып, бу якларда һәркемгә мәгълүм булса да, оятлы вакыйга хакында кайбер исемнәрне үзгәртеп, авылны атамыйча сөйләргә булдык.

Мондый очракларга дучар булып та, кеше сүзе, гайбәттән куркып шаукым чыгарырга базмаган хатын-кызлар бар. 60 яшендәге ялгызак Фәнзилә ханым да дүрт көн буе үз-үзенә бикләнеп утыра. Көн саен хәбәрләшеп торган кешенең телефоны җавап бирмәгәч, Чаллыда яшәүче туганнары да борчыла. Ниһаять, 9 февральдә авылга апасының кызы килеп төшә. Зөлфия өйгә керешли үк Фәнзиләнең йөз-битендәге җәрәхәтләргә, аның авырлык белән хәрәкәтләнүенә, гомумән, кәефсез булуына игътибар итә һәм сораулар яудыра башлый, авыл апасы әйтмешли, «оятлы һәм җирәнгеч хәлләр», ягъни аның Габдуллин тарафыннан кыйналуы, көчләнүе хакында ишетә. Һәм инде сәгать кичке 10 нчы булса да район эчке эшләр бүлегенә барып керә. Бу исә дүрт көннән соң без капчыкны тиште дигәнне белдерә.

Җинаятьчеләрне эзләү бүлеге башлыгы Булат Җамалиев шунда ук авылга китә. Фәнзилә ханымның искитмәле бәянен тыңлап аңлатма алгач та, теге явызның өенә ашыга. Ул төндә өендә булмаганга, Ренатны икенче көнне генә тотып Мөслимгә алып кайта. Бу инде, чынлыкта, аның бик озакка иреге белән хушлашуын белдерә. Тикшерүче Вилсур Мөхәммәдиев шул көнне үк аннан, Фәнзиләдән күрсәтмәләр ала, икесе ике төрле сөйләгәч, аларны кара-каршы утыртып «очная ставка» дигән тикшерү чарасы үткәрә, моның да файдасы тими, ягъни Р.Габдуллин гаебен кире кага. 5 февральдә авылдаш дусты өенә килеп кереп, җенси якынлыкны үз күзләре белән күргән Гөлүсәгә дә мәшәкать чыга, аннан да сорау алына. 10 февральдә көчләү очрагы буенча җинаять эше кузгатыла, икенче көнне суд Габдуллинны сак астына ябарга карар кыла, димәк, зарар күрүче күрсәтмәләренә өстенлек бирелә.

Ошбу бәяннәрнең эчтәлегенә тукталганчы, Ренат – Фәнзиләнең 20 яшькә яшьрәк кайнесе, ягъни ярты ел чамасы элек вафат булган иренең энесе икәнен әйтеп үтик. Мәрхүм абыйсыннан башка тагын өч бертуганы була, ягъни биш балалы гаиләдә туып-үсә ул. Ләкин 7 нче сыйныфта укыганда әтисе, бер елдан әнисе үлеп киткәч, туганнары тәрбиясендә кала, мәктәптән соң беркайда да укымый, армиядә хезмәт итеп кайткач, ике ел КамАЗда эшләп ала, аннан соң вакытлы эшләргә йөри башлый. Авылында юньсез, котырынкы эчкече дип бәялиләр аны. Машина куу, үтерү белән янау, урлашу, рөхсәтсез чит кеше торагына керү кебек җинаятьләре өчен биш тапкыр хөкемгә тартылган, шартлы рәвештә ирегеннән мәхрүм ителгән, мәҗбүри эшләр бирелгән, штраф салынган, ләкин колониядә утырмаган. Беркайчан да өйләнмәгән 40 яшьлек буйдак ул.

Күрсәтмәләренә караганда, 5 февральдә көне буена аракы эчә, кич белән җиңгәсе өенә барып керә, әйтүенчә, кичә аңлашу вә үзара дуслык шартларында бара, ягъни хуҗабикә белән бер-ике чәркә көмешкә эчкәч, кухня идәнендә җенси якынлык кылырга килешәләр. Бар да ирекле булды, көчләмәдем, сукмадым, кыйнамадым, ди ул. Сүз уңаеннан, экспертизаның хатын-кызның йөз-бит, күкрәк, арка, кулбаш, аяк тирәсендә дистәдән артык җәрәхәт булуын күрсәтүен искәртеп үтик. Эксперт аларның 5 февральдә ясалу мөмкинлеге кире кагылмый дип белдерә.

Зарар күрүче сөйләгәннәр тамырдан аерыла, килеп кергәч тәлаякыл исерек бәндә чәй, ашарга сорап лыгырдый, тәкъдим иткәч, баш тарта, аннан соң мин сине үтерергә кердем дип бәйләнергә керешә, кәстрүл капкачы белән җиңгәсенең башына суга, коты алынган ханым түр бүлмәгә йөгереп кереп, тышка сикерү ниятеннән тәрәзәне ача башлый, ләкин сәрхуш аны өстерәп кухняга алып чыга һәм идәнгә егып тәкатьсезлеген канәгатьләндерергә тотына, табигый якынлык кына түгел, бозыклык та кыла, хатын-кыз каршылыгын сугып-кыйнап, көч кулланып җиңә ул. Шулай да теләгән ахырына кадәр җиткерү насыйп булмый явызга, идәндә мәш килгән мәлдә ишек ачыла, Гөлүсә һәм аның «сожителе» Хәмис пәйда була, ярым ялангач ханым залга кереп китә, теге бәндә кухняда киенә.

Ул чакта төп шаһитлар тизрәк чыгып китү җаен карый, тиздән Р.Габдуллин да юк була. Хәмис шул арада да күрше хатыны маңгаендагы кан һәм кызарган урынны күрдем, кухня идәнендәге келәм җыерылган иде дип анда карышу-тарткалашу булуына ишарәли, шулай ук ике-өч көннән хәл белергә кергәч, Фәнзилә Р.Габдуллин галәмәтләрен сөйләп бирде дип белдерә.

Җинаять эшендә гаепләнүченең дә икеләнүле күрсәтмәсе бар. 10 февральдә барысын да кире кагып сөйләгәннән соң, икенче көнне үк күрсәтмәләренә үзгәреш кертергә тели һәм кыскача гына әйткәндә, белмим, хәтерләмим, ләкин Фәнзиләне көчләү, кыйнау гамәлләре булу мөмкинлеген кире какмыйм дип белдерә ул. Әмма көчләү һәм җенси рәвештәге көчләү гамәлләре дигән ике җинаять эшләүдә рәсми гаепләү белдергәч, ошбу күрсәтмәләрен кире кага һәм гаебемне тулысынча танымыйм, дип күрсәтә.

Наил ВАХИТОВ.

Нәфис бизәкле ШӘМАИЛЛӘР

Дания Әгъзамова 1988 елда Үзбәкстанда туган. Әмма дүрт яшь чагында ук Даниягә инде җылы яклар белән хушлашырга туры килгән. Чөнки аларның гаиләсе, сәяси буталышлар башлангач та, Россиягә күчеп, Башкортстанның Фёдоровка районы Фёдоровка авылына кайтып төпләнгән. Дания мәктәптә укыганда ук рәсемнәрне күп ясаса да, сәнгать мәктәбе булмагач, сурәт ясау нигезләренә үзлегеннән генә төшенгән. Башкортстанның М.Акмулла исемендәге дәүләт педагогика университетында читтән торып укыганда, шул ук университет кафедрасында эшләгән.

Рәссам-каллиграф ханым ул чорны болай дип искә алды: «Университетның III курсында укыганда мин үзем кебек мөселман кызлар, курсташларым белән бергә пыяла өслекләргә шәмаил ясарга өйрәнә башладым. Сынлы сәнгать-графика факультеты деканы, укытучыбыз, рәссам һәм декоратив-гамәли сәнгать остасы Тәлгать Хәсән улы Мәсәлимов безне шушы техниканың бар нечкәлекләренә төшендерде. III курсның уку программасы буенча без ялангач утырып торучы модельләрне ясарга тиеш идек. Әмма намаз укучыларны Тәлгать әфәнде андый дәресләрдән азат итте. Без андый дәресләр урынына шәмаил эскизлары ясадык. Мондый карары өчен деканыбызга әлегәчә рәхмәтлебез! Мин бит хәзер дә каллиграфияле сәнгать юнәлеше белән барам. Университеттагы диплом эшем дә «Ашыгыз тәмле булсын!» дигән гарәпчә язмалы пыяла өслекле, бизәкле өстәл булды.

Уфада бертуган апам Гөлнара һәм якын дустым Розалия белән «Ихлас» мәчетендәге ислам курсларына йөрдем. Мөгаллимәбез Фатыйма Фәтхуллина мине намаз укучы татар егете, булачак хәләл җефетем Рөстәм белән таныштырды. Бер атна узуга гаилә кордык. Ирем Яр Чаллыда үскән.

Унсигез яшемдә динебез кануннарын тагы да тирәнрәк өйрәнә башладым, моңа бер вакыйга тәэсир итте. Без утырган очкыч күккә күтәрелде һәм аның бер двигателе яна башлады. Бу вакыйга күңелемне тетрәндерде. Мин үземнең үлемгә әзер булмавымны аңладым. Әлхәмдүлиллаһ, ул чакта бар да яхшы тәмамланды», – ди әңгәмәдәшем.

2010 елда уллары Фатих, 2013 елда Ридван туа, балаларны үстерү мәшәкатьләрендә булса да, Дания яраткан иҗатыннан һич тә читләшми. Ул Уфа шәһәренең иң сәләтле мөселман стилисты һәм визаж белгече булып санала. «Шәрык визажындагы уңышка да бары тик практика аша гына ирешеп була дип саныйм. Мондый макияж да сәнгать төре инде ул... Мин инде хәтта матурлык салоны ачармын дип тә уйлана башлаган идем, бер көнне программист ирем Рөстәм Мәскәүгә күченәчәгебез хакында әйтте. Уфада клиентларым күп иде, башкала тормышыннан бераз куркып та калдым. Аннары андагы яшәү рәвешенә дә күнектем, әлбәттә. Мәскәүдә матурлык академияләре курсларын үтеп, белемнәремне тагы да ныгыттым. Һәм татар кәләшләребезнең үтенечләре буенча аларга шәрык макияжын ясый, туй күлмәкләрен сайлаша, башларына бәйрәмчә итеп яулык бәйли башладым».

Башкалада яшәгән дәверендә Дания үз фикердәшләре белән бергәләп өч ел рәттән никах фестивальләре оештыра. Татар яшьләрен үз милли традицияләребезгә актив өнди. Яшь милләттәшләребез өчен күп мәгълүмат тупланган «NIKAH day» журналын нәшер итүдә катнашып, редактор вазифаларын башкара. Рәссам-дизайнер буларак, Мәскәүнең татар ризыклары рестораны диварларын бизәргә дә өлгерә.

«Каллиграфик әсәрләргә килгәндә, аларны баштарак пыяла өслекләргә генә ясарга уйлаган идем, әмма бу юнәлеш аеруча да сабыр булуны таләп итә. Ялгышлык килеп чыкса, йә буяулар дөрес кулланылмаса яки пыяла чатнап китсә, барысын да яңадан башларга кирәк. Шуңа күрә картиналарымны киндерләргә майлы буяулар белән ясыйм. Каллиграфик язмаларны үзем язмыйм. Гарәп каллиграфиясенә өйрәнү максатын куеп, Ираннан килгән каллиграфтан берничә дәрес тә алган идем, әмма каллиграфлыкка аерым уку һәм рәссамлыкка аерым уку нәтиҗәлерәк булуына төшендем. Әйе, кайбер иҗатчы үзе үк каллиграф һәм үзе үк рәссам булып китә ала. Тик мондый очраклар бик сирәк... Мин үзем әзер каллиграфик язмаларны киндерләргә күчерәм дә, аларның читләре өчен төсләр, бизәкләр сайлыйм. Күңелемә хуш килгән татар, төрек, фарсы орнаментларын ясау миңа аеруча илһам бирә.

Төрки халык орнаментлары – катлаулы, бизәмнәрдәге бихисап кечкенә детальләрне ясау өчен күп вакыт таләп итеЛә, әмма нечкә линияләр, нәфис бизәмнәр читен кабат сызып чыгу, фактура булдыру, сусаль алтын куллану һ.б. миңа бик ошый. Кытайда штамповка ысулы белән генә ясалган, бертөсле пластик өслектәге шәмаилләр урынына, рәссамның кул җылысы кергәненә күпләр өстенлек бирә.

Беренче шәхси күргәзмәм 2016 елны Мәскәүнең Крокус-Сити Холлында үтте. Анда җиде мең кеше җыелган иде!» – диде Дания Фәнил кызы.

Хәзерге көндә рәссам-дизайнер гаиләсе белән Төркиянең Анталья каласында яши. Чит дәүләттәге яшәеше хакында ул болай диде: «Хәзер гаиләбез: мин, ирем Рөстәм, улларыбыз Фатих, Ридван, 2021 елда дөньяга килгән игезәкләребез Җәмил һәм Вилдан белән төрек дәүләтендәбез. Мәскәү кышлары кечкенә балалар белән саф һавада йөрү өчен мәшәкатьле дип, биредә кояшлы көннәргә омтылдык. Фатих белән Ридван Россия уку программалары буенча оештырылган онлайн-мәктәптә укый, һәр хатын-кызга билгеле өй эшләрем җитәрлек... Шуңа күрә үз иҗатым әлегә паузада тора. Кечкенә улларыбыз балалар бакчасына йөри башлауга, мин дә янә иҗат шатлыкларына әйләнеп кайтырмын дип өметләнәм, иншаллаһ!» «Дания, башка рәссамнарга киңәш бирергә туры килсә, ни әйтер идең?» «Без үзгәргән мәлдә матурлыкны күрү сәләтебез дә үзгәрә. Иҗат иткәндә тырышлык та әһәмиятле! Әмма иң мөһиме – динебез догаларында, намазда булып, Аллаһы Тәгалә насыйп иткән бар булганга шөкер итеп, Ул бар иткән дөнья матурлыгын сурәтләү!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ –
«ТАТМЕДИА»
АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
директоры – баш мөхәррир

**Вахит Шәих улы
ИМАМОВ**

Җаваплы сәркатип
Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

**Реклама хезмәте телефоны:
(843)222-05-47 (1560)**

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

**НӘШЕР ИТҮЧЕ –
«ТАТМЕДИА» АҖ**

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан,
Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

**«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru**

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

**Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның
чыгу көне 22.07.2022**

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2762

16+